ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№6 (318) – ИЮНЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Футбол планетасындагы бәйрәм

Алмыштан соңгы әмирләр

Хикмәтле Иске Чаллы авылы

ГЁКДЕНИЗ КАРАДЕНИЗ: «КАЗАН ҺӘРВАКЫТ МИНЕМ ЙОРТЫМ БУЛАЧАК»

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фаридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Катерина Котова, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: Футболчы Гекдениз Карадениз.
Фото «Рубин» ФК рәсми сайтыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«ЗУР ФУТБОЛ ӨЧЕН» ҖАН АТУ ВИРУСЫ

...Җанатарлар белән тулы бу шәһәрдә җан атмый да булмый шул, малай! Тоташ бер чиргә әверелде бу җан ату, вирустай таралды. Сизәсезме? Футбол моңарчы синең җаныңдагы бер генә кылны кузгатмаса да, чемпионат дәвамында, ә инде тәмамланганда бигрәк тә, тоташтан аның сөреннәре генә яңгырап тора башлаячак. Җитмәсә, безнең журналыбызның офисы да Җанатарлар фан-зонасы янәшәсендә үк урнашкан. Без андагы куәтле яңгырашны, журнал әзерли-әзерли, көн дәвамында тыңлыйбыз да кичкә инде тәмам фанатка әйләнәбез.

Ә хәзер чын җанатарларга хас булган төп симптомнарны санап үтик.

Симптом №1. Сөреннәр. Газиз командаңны куәтләү, аларга дәрт өстәү ысулы гына түгел бу, уйламагыз, сөрән җанатарның үзен дә олы бер ышаныч белән тутыра. Организмга гадәттә колаклар аша үтеп кергән сөрәнне «лор» атамасын йөрткән бер генә табиб та бернинди эскәк белән дә йолкып чыгара алмый. Чөнки сөреннәрнең бер үзенчәлеге бар – алар тиз хәрәкәт итүчән, елгыр һәм шуның белән куркыныч та.

Организмга үтеп кергәч, сөреннәр яшен тизлегендә бугазга ыргыла, һәм күп тә үтми, син үзеңнең башкалар шикелле үк кычкырганыңны абайлап аласың. Син дә – җанатарлар хорындагы бер аваз. Авыру тарихын кеше күзе танымас язуы тутырыр да, табиб сине коллегасына җибәрер, шәт – ортопедка, йә булмаса мануаль терапевтка. Чөнки колактан үтеп кергән сөрән вирусы инде ул арада югары очлыкларга барып җиткән булыр.

Симптом №2. Кул изәүләр. Җанатарларның куллары үзгә бер энергия-көчкә буйсына. Бу инде көн дәвамында компьютер тычканын тегендә-монда күчереп, көндәлек эшеңне башкарып утыру түгел! Кулларның хәрәкәт амплитудасы еш кына җанатарларның үзләрен дә гаҗәпләндерә, ди, имеш. Мануал, кул изәү симптомы үзен сиздергән очлыкларны караганнан соң, борчылмас, киресенчә, сөенер генә: буыннар менә дигән халәттә, алардан дәрт ташып тора. Пациент җитмәсә әле чабарга, сикерергә атлыгып тора! Юкса аның белән мондый үзгәрешләрнең инде 2017 елдагы Конфедерацияләр кубогыннан бирле күзәтелгәне юк иде...

Симптом №3. Туганлашу. Үзара тыгыз контактларга корылган бик тә хәтәр симптом. Телләрнең, милләтләрнең, яшәү урыннарының, тормыш рәвешенең, мавыгу-кызыксынуларның төрлелегенә карамастан, әлеге вирус эләккән кешеләр котылгысыз рәвештә туганлаша башлый – кочаклашалар, үбешәләр, бергәләп сөреннәр кычкыралар, кулларын изиләр, сикерешәләр. Һәм, аңлашыла инде, бу этабында вирус куркыныч төсмер ала – аны инде тыеп, кисәтеп калам, димә. Ул хәзер бер генә табиб дәвалый ала торган стадиядә дә түгел. Әнә бит, ишетәсездер... Безгә ишетелә: туганлашып алган «авырулар», үзара кочаклашып, «Россия өчен!», «Франция өчен!», «Австралия өчен!» дип кычкыра. Ә тора-бара бу аһәңне инде тагын да әһәмиятлерәгә күмеп китә: «Зур футбол өчен!»

СЕЗНЕҢ ВИРУСТАН КОТЫЛА АЛМАГАН РЕДАКЦИЯГЕЗ.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-1494
Басарга кул куелды: 22.06.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **900 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Иллюстрация: Альфрид Шәймәрданов «Сальвадор Дали Казанда»

ИЮНЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. **Ареналар, парклар, проспектлар һәм метро...** «Спорт бишьеллыгында» Казан ничек үзгәрде

12. **Киләчәк шәһәре.** Казан мэры Татарстан башкаласын ун елдан соң нинди итеп күзаллый

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18. **Чемпионатта катнашучылар.** Футбол бәйрәмен оештыручылар хакында

22. **Могҗиза күрәсе килә.** Чын җанатар ничек җан ата

24. **Чемпионнар ярдәмчесе.** Милли җыелма командалардагы үз кеше

26. **Олы футболның яшь туташлары.** Әгерҗе кызлары Россия җыелмасына ни рәвешле ярдәм итте

28. **Дөнья җыелма командасы. Безнең версия.** Галәм масштабындагы йолдызлар – алар янәшәдә

34. **61 нче номерлы легенда** Гёкдениз Караденизь «Рубин»ны җиңүләргә ничек рухландырган

36. **Редакция кухнясы.** Кунаклар өчен иттән деликатес

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

42. **Әлки төбәге серләре.** Дөньядагы иң матур урын

50. **Тарихи сәхифәләр.** Болгар әмирләре

54. **Җиде буын нәселеңне бел.** Тамырларыңны ничек өйрәнергә

58. **Безнең киштәдә.** Без – кемнең караламасы?

61. **Өлкән буын.** Дөнья йөген тарткан Әминә

84. **Татар авыллары.** Хикмәтле Иске Чаллы

Тулырак мәгълумат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

25.05

Владимир Путин, Россия Федерациясе Президенты, – Петербург халыкара икътисадый форумының пленар утырышында:

– Бүген төбәкләр арасында эшлекле мохитнең сыйфаты өчен, инвесторлар, яхшы кадрлар өчен көндәшлек үсә. Асылда, бу безнең даими үзгәрешләр механизмын сафка бастыра алуыбыз турында сөйли. Шул исәптән монда инвестиция климатының милли рейтингы гаять әһәмиятле роль уйнады. Традиция буенча, бу елдагы җиңүчеләрен котларга телим: болар – Төмән өлкәсе, Мәскәү, Татарстан Республикасы.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

30.05

Дмитрий Чернышенко, Континенталь хоккей лигасы идарәсе рәисе, – Казан Кремлендә «Ак Барс» хоккей клубын – Гагарин кубогы-2018 иясен котлаганда:

– Бу җиңү хоккей тарихында калачак. Сез беренче юбилей кубогын яулап алдыгыз, ә гомумән алганда, бу команданың өченче кубогы. Татарстан планканы югары күтәрә, һәм башкаларга да шушы югарылыкка омтылырга кирәк.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

24.05

Сергей Безруков, Россиянең халык артисты, – Буада «Буа: диалог киңлеге» фестивалендә «Нәни принц» спектакле күрсәтелгәннән соң:

– Өлкәннәр балачакларына кайта, һәм әлегә аларның күңелендә нәни принц яши икән, алар джунглилар турында да, йолдызлар турында да фикер йөртә ала. Алар романтик булып кала. Минемчә, иң мөһиме – күңелдәге романтиканы югалтмаска. Кешелек тарихын нәкъ менә романтиклар хәрәкәткә китерә, ә циниклар җимерә. Әмма иң нәни вакыттан ук үз планетаңны тәртипкә китерергә өйрәнергә кирәк. Шулай итеп, балаларныкы гына булып тоелган сораулар глобаль күләм ала. Һәм син әлегәчә «балалар» законнары белән яшисең икән, үзеңне дөрес яши дип исәпли аласың.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Спорт бишьеллыгында» Казан **НИЧЕК** яңарды

Казан мэры Татарстан башкаласын ун елдан соң **НИНДИ** итеп күзаллый

«Фестиваль» бульвары.

Фото: Александр Ефремов, Ната Смирнова

ЯҢАРТЫЛГАН КАЗАН

Зур-зур спорт бәйрәмнәренең һәркайсы Татарстан башкаласын үзгәртә, матурлый. Бүгенге сәяхәтебездә – соңгы елларда булдырылган, төзелгәннәрнең бик азы гына әле. Ләкин яраткан калабызны хәзер инде башкача күз алдына китереп тә булмый. Шулай итеп, менә алар «спорт бишьеллыгы»ның нәтиҗәләре – 2013 елгы Универсиададан футбол буенча 2018 елгы дөнья чемпионатына кадәр.

Татарстан Президенты «Фестиваль» бульварын кабул итә.

Язучы Гүзәл Яхина һәм җырчы Эльмира Кәлимуллина «Укый Казан! Укый Татарстан!» китап бәйрәмендә.

«ФЕСТИВАЛЬ» БУЛЬВАРЫ ҺӘМ ФАН-ЗОНА

Футбол буенча 2018 елгы дөнья чемпионаты уеннары стартына ачылган өр-яңа объектларның берсе – «Фестиваль» бульвары– «Кәҗә бистәсе» метро станциясеннән «Казан» гаилә үзәгенә юнәлгән гаҗәеп матур җәяүлеләр зонасы. Әлеге парк комплексы концепциясенең нигезенә туп очышы траекториясе салынган. Аны, әйтик, яшеллеккә күмелеп утырган зоналарда салынган җәяүле сукмакларының салмак борылышлары чагылдыра. Бульварда 200 агач, 3,5 мең куак утыртылган, күпсанлы чәчәк түтәлләре ясалган. Таганлы корылмаларны өлкәннәр дә, балалар да үз итеп өлгерде. Сибгат Хәким урамына таба бульварны чемпионатта катнашучы илләрнең исеме язылган 32 бетон шар – туплар бизи. Шулар янәшәсенә футбол уйнаучы малайлар рәвешендәге тагын бер сынлы композиция куелачак. «Тупларга ияреп барып», Казансу ярындагы Фан-зонага килеп чыгабыз. Һәм шунда озакка калабыз...

«Фестиваль» бульвары Россия көнендә ачылды. Ул көнне аны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Казан мэры Илсур Метшин кабул итте. «Татмедиа» бинасы янында кунакларны «Укый Казан! Укый Татарстан!» дип исемләнгән китап бәйрәме каршылады.

KAZAN ARENA


KAZAN ARENA
KAZAN ARENA
KAZAN ARENA
KAZAN ARENA
FIFA 2018

45 МЕҢ ТАМАШАНЫ СЫЙДЫРГАН «КАЗАН АРЕНА»

Стадион 2013 елда ачылды. Россиянең гамәлдәге стадионнары арасында иң күп тамашачы сыйдырышлыларыннан берсе. Аны «шәһәр эчендәге шәһәр» дип атарга була, трибуналар астында ресторан, фитнес-клуб, балалар өчен уку-укыту үзәкләре һ.б. урнашкан. «Казан Арена» трибуналарының дүрт ярусы түбә астына кертелгән, уен кыры – ачык һавада. Иркен вип-зона ябык 70 скай-бокстан гыйбарәт. Һәр секторның үз төсе бар: төньяктагысы – зәңгәр, көнчыгыштагысы – кызыл, көньяктагысы – сары, көнбатыштагысы – яшел. Стадионда беренче матч 2014 елның 17 августында узды. 14 июньнән 15 июльгә кадәр «Казан Арена» футбол буенча дөнья чемпионатының алты матчын кабул итәчәк.

УНИВЕРСИАДА АВЫЛЫ

2010 елда ачылган әлеге торак микрорайон 2013 елда XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадага килгән спортчыларны һәм чит ил делегацияләренең башка әгъзаларын яшәтү өчен төзелде. Россиядәге иң зур студентлар кампусын бүген Казан федераль университеты, Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе, КФУның ИТ-лицее файдалана. Хәзер Универсиада авылында 6000нән артык студент яши.

Рафис Борһанов, Татарстан Премьер-министры урынбасары – мәгариф һәм фән министры:

– Универсиада уздыруга гаризабыз җиңү яулаган мизгелдән соңгы ун елда вакыйгалар шулкадәр күп булды ки, башка шәһәргә болар бер гасырга җитәр иде. Бер нәрсәне әйтеп үтә алам: бу хезмәтнең мирасы 2015 елда Су спорт төрләре буенча чемпионатны уздыруга гариза биргәндә дә, футбол буенча 2018 елгы дөнья чемпионатын уздыруга теләк белдергәндә дә чагылыш тапты... һәрнәрсә иң югары дәрәҗәдә оештырылган. Красноярскида Кышкы универсиада безнең өлгедә әзерләнә. Үрнәк өчен планка югары күтәрелгән, берәүнең дә аны түбән төшерәсе килми. Казандагы яңа чараларга килгәндә исә, мин бу мәсьәләгә безнең инфраструктураны тагын ни белән тулыландырып була дигән ноктадан фикер йөртер идем. Мәсәлән, без 2019 елда кабул итәчәк Ворлдскиллс стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатыннан соң 130 мең квадрат метрлы, киң кулланышка яраклы мәйданнарыбыз калачак. Бу – төрле яңа чаралар уздыру өчен тагын бер сыйфатлы мәйданчык. Ә инде барлык хезмәтнең нәтиҗәләре турында сөйләгәндә, искә алмыйча мөмкин түгел: шулкадәр сандагы спорт федерацияләре белән элемтә тоткан төбәк, мөгаен, Татарстан гына булыр. Ләкин безнең төп мирасыбыз шунда: 10 ел элек Россия ярышларына бездән 2–3 спортчы гына сайлап алына иде. Ә бүген спорт министрының башына бөтән бәла төште: нормативларны үтәгән 40 кешене йөзү буенча Дөнья кубогына җибәрү өчен каян акча алырга... Мин бассейндагы сигез юлдан өчәр-дүртәр яшь спортчы йөзеп үткәнен күрәм икән, нәтиҗәләребез булачагына ышанам. Монда да, башка спорт төрләрендә дә...

СУ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ САРАЕ

Йөзү буенча теләсә нинди дәрәҗәдәге ярышларны кабул итү мөмкинлеге бирә торган инфраструктурага ия универсаль спорт сарае. 2013 елда ачылды. 2013 елгы Универсиаданың иң мөһим объектларыннан берсенә әйләнде: монда йөзү, синхрон йөзү, суга сикерү буенча ярышлар узды. 2015 елда Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын уздыру мәйданчыгы булып хезмәт итте. Берничә тиңдәшсез конструктив үзенчәлеккә ия. Әйтик, бина махсус эшкәртелгән агач белән капланган, суга сикерү һәм узышу бассейннарының төпләре аска-өскә күчерелә ала, бу исә аларның тирәнлеген төрле максатларда, мәсәлән, балалар өчен дәрес, су тубы уеннары, аквасайклинг оештырганда һ.б очракларда үзгәртергә мөмкинлек тудыра.



Фото: Александр Ефремов

ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛГӘН КАБАН КҮЛЕ ЯР БУЕ

Татарстан башкаласы халкы һәм аның кунаклары Меңьеллык паркыннан Иске Татар бистәсенең тарихи урыннарына, Кабан күленең яңартылган, төзекләндерелгән яр буеннан узып, җәяүле сәяхәт кыла ала. Бу тирәдә күләмле үзгәртеп кору эшләре 2017 елның язында башланды. Реконструкциянең иң яхшы проекты өчен халыкара конкурста «Turenscape + MAP architects» Россия–Кытай консорциумы җиңеп чыкты. Беренче этапта башкару планлаштырылган эшләр: субайлар белән ныгытып ясалган яр буе юлларын салу, амфитеатр, су үсемлекләреннән каскад, күзәтү мәйданчыгы төзү, велоюллар көйләнгән җәяүлеләр зонасын киңәйтү. Проектның максаты – табигый ландшафтны саклап калу һәм Кабан күлләре системасының яр буе территорияләрендә шәһәр халкы өчен яңа ял зонасы булдыру.

Владимир Леонов, Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры:

– Универсиада уздыруга тәүге тапкыр гариза тапшырганда, без, асылда, бу кампаниянең бөтен масштабын күзаллап та бетермәдек. Ләкин алга куелган максатларның барысы да үтәлде. Без үз көчебезне тоя алдык. Казанның исеме билгеле, безгә ышаналар, халыкара федерацияләр безгә зур хөрмәт белән карый. Һәм хәзер без тагын да зуррак эшләргә әзер. Татарстан башкаласының инфраструктурасы Олимпиада уздыру өчен файдаланыла ала, берничә объект кына җитешми. Ни кызганыч, илебез ызгыш-гаугалы хәлдә калды. Олимпия хәрәкәтендә безгә гариза бирү өчен юл ябылды, кайбер спорт чараларын кире кагу, тартып алу мәсьәләләре дә баш калкытты. Ләкин без барысы да җайланыр дип ышанабыз. Хәзерге көндә, алдыбызга зур мультиспорт чарасын уздыру максатын куеп, сөйләшүләр алып барабыз.



ЗАМАНЧА АЭРОПОРТ

«Казан» халыкара аэропортын яңарту һәм зурайту программасы Татарстан транспорт инфраструктурасы объектларын алга таба үстерү һәм 2013 елгы Бөтендөнья җәйге универсиадага әзерләнү максатында эшләнде һәм 2008 елда старт алды. Дүрт елдан елына 1,2 млн пассажирга хезмәт күрсәтергә сәләтле 1А терминалы сафка басты. 2013 елда яңа аэронавигация комплексы – диспетчерлык-контроль манарасы ачылды. 2014 елда багаж белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы кулланышка тапшырылып, ул багажларны эзләү һәм эшкәртү процедурасын җайлаштырды. 2015 елда аэропорт Казанда – Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты, ә 2017 елда ФИФА Конфедерацияләр кубогы кунакларын һәм анда катнашучыларны рәсми кабул итү урыны дип танылды.



ЯҢАРТЫЛГАН «КАЗАН – 2» ВОКЗАЛЫ

2012 елда Воровский урамында «Казан – 2» транспорт – күчереп утыру төененең көтеп тору заллары, кассалар, теркәү һәм мөстәкыйль хезмәт күрсәтү терминаллары, чыгу тоннеле һәм пассажирлар өчен платформалардан гыйбарәт яңа пассажир терминалы бинасы («Восстание-Пассажир» станциясе) ачылды. Терминал вокзалның иске бинасы урынында төзелде. 2013 елда Казанда метроның сигезенче, тугызынчы һәм унынчы – «Авиатөзелеш», «Төньяк вокзал» һәм «Яшьлек» станцияләре ачылды. «Төньяк вокзал» станциясе шәһәр яны электропоездларына, ерак араларга бара торган поездларга һәм шәһәр яны яки шәһәрара автобусларга күчеп утыру өчен «Казан– 2» вокзалына трансфер зонасына әйләнде.

Марат Бариев, РФ Дәүләт Думасы депутаты:

– Татарстан Казанның меңьеллыгын бәйрәм итәргә әзерләнгәндә, республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиев шәһәрдә киң колачлы бәйрәмнәр, ярышлар оештыру бурычын куйды. Акрынлап без Универсиада уздыру идеясенә килдек. Спорт инфраструктурасы бик ярлы иде: үзәк стадион, боз сарае, «Синтез» бассейны һәм күптән түгел төзелгән «Баскет-холл» гына. Зур спорт ярышларының соңгысын без 10 елдан артык элегрәк уздырганбыз икән... Минтимер Шәрипович Универсиада идеясен хуплагач, аңа әзерләнер өчен нәрсә эшләргә кирәклеге белән кызыксынды. Инфраструктура һәм спорт чараларын уздыру тәҗрибәсе кирәк, дип җавап бирдем. Без Мәскәүдәге спорт структуралары җитәкчеләре һәм белгечләре белән киңәшләшә башладык. Әүвәл безне хуплаучы бик аз иде, Казан кайда да, Универсиада кайда, янәсе... Ләкин без бик үҗәт булдык. Хәзер хәл киресенчә: Казанда төрле чаралар уздыру турында Россия генә түгел, чит ил проектларын гамәлгә ашыручылар да хыялланa. Монда сыналган, әзерлекле кадрлар, инфраструктура бар, кунакчыл, киң күңелле халык яши. Ә колачлы мультиспорт ярышлары бик күп. Без РУСАДАдан санкцияләр алынганын көтәбез һәм шул вакытта яңа ярышлар уздыру мәсьәләсен тулы көчтә кайгыртырга тотыначакбыз.

ИЛСУР МЕТШИН: «УНИВЕРСИАДАНЫҢ ТӨП НӘТИҖӘСЕ – ФУТБОЛ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ»

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

«Татарстан» журналына биргән эксклюзив интервьюсында Казан мэры дөньякүләм спорт форумнарының башкалабызны ничек үзгәртүе, ә үзенең исә аны ун елдан соң нинди итеп күрергә теләве хакында сөйләде.

– Илсур Рәисович, дөньякүләм дәрәҗәгә ия спорт чараларына бәйле рәвештә, 2013 елдан башлап, Казан ничә объектка баеды? Моның өчен никадәр көч сарыф ителде дә, күпме акча таләп ителде?

– Күптән түгел генә Казанның 2013 елда Универсиаданы үзендә уздыру өчен гариза кампаниясенә мөрәҗәгать итүенә дә 10 ел тулды. Бөтендөнья Студент уеннары шәһәребездә узган дөнья масштабындагы вакыйганың беренчесе булгандыр, нәкъ менә ул аннан соңгы киң колачлы глобаль чараларга старт бирүче булды да. Әмма аңарчы, сез инде яхшы беләсез, без җиңелү ачысын да татып өлгердек. Башта без 2011 елдагы Универсиаданы уздырырга дәгъва кылган идек. Һәм менә Туринда гариза кампаниянең нәтиҗәләре белән таныштырганда:

Фотолар Казан мэриясе матбугат хезмәтеннән алынды



“ – 10 ел гына узып китте – һәм менә Россиядә, шул исәптән Казанда да футбол буенча дөнья чемпионаты уздырыла. Без теге чакта бу турыда хыялланырга да җөрьәт итми идек. Бу миңа гаять символик күренеш булып тоела.

Автор:
Татьяна Вафина

«China, Shenzhen», – дигән игълан яңгырады да, безнең кәефләребез бөтенләй төште. Видеокадрларда бу күренә. Ул мизгелдә минем башыма башка беркайчан да моның белән шөгыльләнмәячәкбез, дигән уй керде, чөнки җиңелүне авыр кабул иттек. Әмма Минтимер Шәрипович, безне котлап, болай диде: «Сез чын молодецлар! Ярты ел эчендә башка илләрдәге алты гариза арасыннан икенче урынга чыгу – зур нәрсә». Чынлап та, җиңелүләрсез җиңүләр дә булмас иде, алдагы гариза кампаниясендә без инде җиңеп чыктык.

Объектларга килгәндә, Универсиадага дөнья масштабындагы 30 яңа спорт комплексы төзелде, шул исәптән – 45 мең тамашачыны кабул итәрлек «Казан Арена» стадионы, 11 юл чишелеше һәм шулкадәр үк яңа юллар, 39 җәяүлеләр кичүе, 13 реконструкцияләнгән урам, 122 ремонтланган юл! Казан урамнары 4 млн квадрат метрны тәшкил иткән яңа асфальт өслек белән капланды, метроның өч станциясе сафка бастырылды, заманча аэропорт калкып чыкты, интермодаль күчерүләр линиясе пәйда булды.

300дән артык тарихи бина торгызылды. Бөтендөнья Студент уеннарында катнашучылар өчен корылган Универсиада авылы Россиядәге иң яхшы студентлар кампусы булып танылды. Анда безнең университетта белем алучы алты меңнән артык студент яши.

Универсиадага 3150 тышкы яктырткыч терәк урнаштырылды, 25,5 км трамвай юлы салынды. 2500дән артык канализация коесы торгызылды, 400 км ны тәшкил иткән яңа инженер челтәрләре үткәрелде. Бу озынлыгы буенча Казаннан Чаллыга бару һәм кайту юлына тиң. Әлеге хезмәт бик катлаулы һәм кыйммәт, күп вакыт сарыф итүне таләп итә.

Мин хәзер генә барлык эшләнгән эшләрне шулай җиңел санап утырам. Хәтерегездә булса, без бит бу эшләрнең барысын да берьюлы диярлек башлап җибәрдек. Казанлылар бездән сорыйлар иде: нишләп бер чишелешне эшләп бетергәннән соң гына, икенчесенә тотынмаска? Әмма ул кадәр киң колачлы төзелешне бер-бер артлы алып барганда, өлгерү мөмкин түгел иде. Шәһәр халкына ул чактагы сабырлыклары өчен зур рәхмәт. Ә соңыннан, 6 июльдә, исегездәме икән, без сезнең белән бөтенләй икенче шәһәрдә уяндык.

Федераль үзәкнең көчле ярдәме белән без киләчәктәге спорт вакыйгалары өчен дә нигез салдык, алга таба инде күп нәрсәне үз көчебез белән башкара алдык – асылташның кырларын ялт итеп торырлык итеп эшкәрттек, дияргә дә була.

10 ел гына узып китте – һәм менә Россиядә, шул исәптән Казанда да футбол буенча дөнья чемпионаты уздырыла. Без теге чакта бу турыда хыялланырга да җөрьәт итми идек. Бу миңа гаять символик күренеш булып тоела. Казанда Универсиаданы уңышлы уздыру барлык дөнья халыкларына да безнең ни дәрәҗәдә ачык, киң күңелле һәм уникаль ил икәнлегебезне күрсәтте. FISU җитәкчеләре дә, спортчылар да, Универсиада кунаклары да Бөтендөнья Студент уеннары тарихында Казандагы уеннарның иң шәпләрдән берсе булуын таныды. Бу җәһәттән Универсиаданың нәтиҗәсе дә күренә: Россиядә, Сочида, Олимпия уеннары узды, һәм менә хәзер без үзебездә футбол буенча дөнья чемпионатын кабул итәбез.

Әлеге глобаль вакыйгага Казан, әлбәттә, җентекләп әзерләнде. Яңа объектларны санап тору күп вакытны алачак: бу Кабан күлендәге яңартылган яр буе да, Бондаренко, Чистай һәм Сибгат Хәким урамнарындагы яңартылган юллар да, Декабристлар урамы буйлап «Кәҗә бистәсе» метро станциясеннән Гаилә үзәгенә таба җәяүлеләр йөри торган зона булдыру да.

Соңгы ике ел эчендә бик тырышып юлларны тәртипкә китерәбез. Соңгы ел юлларны ремонтлау чагыштырып булмаслык күләмне тәшкил итте. Беренче тапкыр республика безгә бу максатлар өчен 6,1 млрд сум акча бүлеп бирде, бу гадәттәгедән ике тапкырга диярлек күбрәк. Без 175 урамны тәртипкә китердек. Агымдагы елда юл ремонты өчен бүленәчәк сумма шулай ук саллы – 5,5 млрд сум.

Өр-яңа, исәбе буенча унберенче, метро станциясе – «Дубравная» ачылачак. Безнең автотранспорт предприятиеләре дөнья чемпионатына алдан ук әзерләнергә керешә. Соңгы өч ел эчендә алар үз акчалары хисабына автобус паркын яртылаш яңартып чыкты (784тән 351 автобус алыштырылачак). Бездә хәзер Россиядәге иң яшь «автобус» паркы, җитмәсә, бюджеттан моның өчен бер тиен акча да сарыф ителмәде.

Хәер, әлеге үзгәрешләр мундиаль белән генә дә бәйле дип әйтеп булмый. Казан үзенең үсешендә планканы гаять югары күтәрде, ул хәзер даими төзекләндерелеп торган шәһәргә әверелде. Менә гап-гади

генә мисал. Мундиальгә без шәхси компанияләр белән бергә 7 млн данә чәчәк утыртуны күздә тоткан идек. Бер яктан караганда, бу Универсиада вакытында утыртылганнан да ике тапкырга күбрәк, ул чакта шәһәрне 3,5 млн данә чәчәк бизәде. Ә икенче яктан карасак, без бит соңгы елларда, халыкара чараларны сәбәп итмичә дә, шәһәр кешеләрен сөендерү өчен 5,5 млн данә чәчәк утыртканбыз икән. Соңгы биш ел эчендә паркларның саны да күзгә күренеп артты, өч тапкырга диярлек. Бүген Казанда 140 парк һәм сквер бар, аларның гомуми мәйданы 367 гектарны тәшкил итә. Шәһәр халкы белән бергәләп «Яшел рекорд» дигән проектны тормышка ашырдык – 180 мең агач белән 118 мең куак утырттык. Казан Россиянең миллион кеше яши торган 13 шәһәре арасында соңгы 10 ел эчендә төзелгән балалар бакчалары, мәктәпләр һәм хастаханәләр исәбе буенча да беренче урында тора. Яңа спорт объектлары, спорт мәйданнары һәм мәдәният сарайларына килгәндә, Казан шулай ук лидерлар исәбендә. Җанатарлар бер айдан соң таралышып бетәчәкләр, ә менә яңа асфальт җәелгән урамнар, ремонтланган хастаханәләр шәһәр кешеләре иркенә калачак. Аларны кесәгә салып алып китмәячәкләр ләбаса!

– Инфраструктура белән төзекләндерүдән тыш, Казанга спорт чаралары тагын нинди файда китерә?

– Өстәмә драйв, рух белән өретелмәгән бер генә өлкә дә калмады. Олы дулкын бит ул барлык көймәләрне дә күтәрергә сәләтле. Универсиададан соң без өч миллион туристны кабат бары тик 2030 елда гына кабул итә алачакбыз, дигән идек. Әмма туристлар агымы шундый кызу темплар белән үсә ки, өч миллион туристны без инде быелгы көздә үк кабул итәчәкбез. Казанны белделәр, таныдылар, ә без, үз чиратыбызда, аны туристларга тагын да кызыклырак итәр өчен барысын да эшлибез.

Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан соң безнең шәһәребез туристлар өчен Россиядәге иң кызыклы шәһәрләр исемлегендә өченче булып тора. Booking.com сайты Казанны шулай ук Россиянең иң кунакчыл шәһәре буларак та билгеләп үтте.

Кунакханә бизнесы үсеш кичерә. Кунакханәләр, хостеллар һәм кунак йортлары соңгы биш ел эчендә ике тапкырга артты, бу әле безнең Универсиадага да куәтләрне көчәйтүебезне исәптә тоткан хәлдә.

Универсиада узганчы, Казанда спорт белән нибары 28 % халык кына шөгыльләнә иде. Бүген без ул күрсәткечне 43 %ка җиткереп киләбез. Спорт казанлыларның тормыш рәвешенә әверелеп бара. Моның хакына гына булса да, үзебездә нинди дә булса ярышны кабул итү өчен көрәшергә була. Алдагы һәрбер процентка ирешү зур авырлыклар, көч белән бирелсә дә.

Әлбәттә, инфраструктура бик нык үзгәрде, әмма, иң мөһиме, кешеләр үзгәрде, безнең яшьләр. Казанда бар дөньядан кунакларны кабул иткәндә, казанлылар да эшли бит, иң шәп белгечләр белән аралашалар, алдынгы дөнья тәҗрибәләрен өйрәнәләр, димәк, һөнәри яктан үсәләр. Бүген безнекеләр Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, ә дөньяның теләсә кай-

– Булачак үсеш факторларын һәм гамәл юнәлешләрен сайлаганда өстенлекләрне, мөмкинлекләрне, һәм шулай ук шәһәргә янаган хәвеф һәм куркынычларны җентекләп анализлауга нигезләндек. Составында иске традицион тармаклар да, белемнәр икътисадына караган яңалары да булган диверсификацияләнгән икътисадка таянып, кеше капиталына нигезләнеп, Казан тиз үсеш өчен барлык мөмкинлекләргә дә ия.

сы почмагында эшли ала. Без үзебезнең казанлыларны кайда гына очратмадык – Яшүсмерләр Олимпия уеннарында да, Бразилиядә футбол буенча дөнья чемпионатында да, Сочидагы Олимпиадада да... Без провинциальлек ябынчасын салып ташладык. Бүген казанлылар дөнья белән бер бергә атлый. Без үзебезнең дөньядагы башка эре шәһәрләр белән бер дәрәҗәдә булуыбызны аңладык, һәм хәзер без яулый алмаслык үрләр юк диярлек.

– Казан сез мэр вазыйфасында эшләгән вакыт аралыгында ничек үзгәрде?

– Безнең нинди уңышларга ирешүебез турында мин үзем сөйләп утырсам, ул дөрес булмас иде. Җитмәсә, бу уңышлар – Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов җитәкчелегендәге олы бер команданың эшчәнлеге нәтиҗәсе. Билгеле, уңышлар, алга китеш бар, әмма шул ук вакытта агымдагы проблемалар да җитәрлек. Без аларны күрәбез, юкка чыгару буенча эш алып барабыз.

Беләсезме, бер очрашуда миннән нәрсә диеп сорадылар? Ни хакында хыялланасыз сез, диделәр. Мэр вазыйфасындагы кеше буларак, мин Казанны Россиядәге иң төзек, уңайлы һәм куркынычсыз шәһәр итеп күрергә хыялланам. Һәркемнең ихтыяҗларын канәгатьләндерердәй мәдәни эчтәлекле шәһәр дә булсын иде ул: опера, татар һәм рус яки, мәсәлән, чуваш театры, милли мәктәпләр һәм мәдәни объектлар булсын. Спортның да барлык төрләре кирәк, төрледән-төрле секцияләр, бал биюләре. Һәр биш континентка очып китүне һәм әйләнеп кайтуны оештырырдай аэропорт. Бу – максималь бурыч.

Ә бу хыялны чынга ашырыр өчен, без нәрсәгә алынсак та, булдырып чыгачакбыз, дип уйлыйм: Олимпия уеннары булсынмы ул, башка берәр төрле дөнья чемпионатымы – максатка ирешер өчен тырышырга гына кирәк. Драйверлар таләп итeлә, бозны вату һәм кузгатып җибәрү генә мөһим, ә федераль программалар булганда, без һичшиксез тупланабыз, кулыбызга тапшырылган, иңебезгә куелган йөкне күтәрерлек көч табабыз. Чөнки беләбез: бу шәһәребезгә тагын бер баскычка югары күтәрелергә мөмкинлек бирәчәк.

– Сез башка шәһәрләрдә, илләрдә еш буласыз, мөгаен, чагыштырасыздыр... Глобаль спорт чараларын кабул итә торган бүтән шәһәрләр дә Казаныбыз шикелле үзгәрәме? Кемнәр безгә үрнәк була ала?

– Иң күркәм үрнәкләрнең берсе – Барселона. Ул туристлар трафигы буенча бездән күпкә өстен тора, Олимпия уеннары узганнан соң, бу күрсәткечне күп тапкырларга арттырды. Уңай, үрнәк мисаллар шактый, укытучыларыбыз да күп...

– Соңгы арада шәһәр күзгә күренеп үзгәрә. Ул нинди булып җитешер? Чикне билгели торган берәр план бармы? Әйтик, 10 елдан соң Казаныбыз нинди булачак? Һәм сез аны ничек күрәсез?

– Бездә «Стратегия-2030» планы эшләнде, аның буенча безнең Казанны ничек күзаллавыбыз шунда ук күзгә ташлана. Төп стратегияле максат – республика стратегиясенә тәңгәл: башкалабыз Россиянең эре фәнни-мәгърифәт, инновацияләр һәм финанслар үзәгенә әверелергә тиеш, республиканың смарт-икътисадка таба хәрәкәтендә драйвер булуын күздә тотабыз аның. Казан – сәламәтлек территориясе, актив, җаваплы һәм креатив кешеләр яши торган уңайлы кала. Биредә хакимият – кешеләргә ачык, ә шәһәр мохите – хәвеф-хәтәрсез. Монда кешеләрнең әйләнеп кайтасылары килә, монда төрле буын вәкилләренә яшәргә уңайлы һәм кызыклы. Динамик шәһәр булуына карамастан, Казан икътисадый яктан тотрыклы шәһәр дә, ул киң мөмкинлекләрне күздә тота. «Идел–Кама» үсеш полюсының лидеры ул. Шәһәрнең яңа генераль планын төзеп, без хәзер аны актив рәвештә эшкәртәбез – бу үсешебезнең эшлекле бер коралы.

Билгеле, без аны күктән алмадык. Булачак үсеш факторларын һәм эш-гамәл юнәлешләрен сайлаганда өстенлекләрне, мөмкинлекләрне, һәм шулай ук шәһәргә янаган хәвеф һәм куркынычларны җентекләп анализлауга нигезләндек. Составында иске традицион тармаклар да, белемнәр икътисадына караган яңалары да булган диверсификацияләнгән икътисадка нигезләнеп, кеше капиталына таянып, Казан тиз үсеш өчен барлык мөмкинлекләргә дә ия.

Алдагы иң якын планнарны исәпкә алсак, 2019 елда WorldSkillsны беренче тапкыр бездә кабул итәргә җыенабыз. Казан аэропорты янында күргәзмә үзәген төзеп бетерергә җыенабыз, анда ярышлар узачак. Әлеге чемпионат – спорт чарасы гына түгел, ә биш континенттан килгән яшьләрнең виртуозларча эшләүләрен күзәтеп тору мөмкинлеге дә. Никколо Паганини скрипкасы белән ничек могҗизалар тудырган, болар да үз куллары белән шундыйны башкара бит. 50 ватык машинаны күз алдына китерегез – «фордлар» иде шикелле ул – яшь егет-кызлар шуларны тамашачы күз алдында ремонтлап, сафка бастырды. Һәм кем беренчерәк, шунысы да мөһим бит! Яисә флористлар, пешекчеләр, официантлар, чәчтарашлар, дизайнерлар – аларның осталыгы... Болар барысы да эшче һөнәрләргә кызыксыну гына уятып калмый, ә аларга булган ихтирамны да көчәйтә! Без бик җитди әзерлек эше алып барабыз, Татарстанның Россия Федерациясе командасындагы составын тиешле дәрәҗәдә хәзерлибез. Чара узганнан соң, күргәзмә комплексы калачак, анда Россиядән генә түгел, ә Европадан һәм, гомумән, халыкара дәрәҗәдәге күргәзмәләр дә киләчәк. Шәһәребездә мондый югарылыктагы мәйданның булганы юк иде әле. Ә бу, үз чиратында, зур күргәзмә активлыгы да, яңа эш урыннары да, салымнар белән өр-яңа мөмкинлекләр дә, дигән сүз. **Т**

«ЛУЖНИКИ»: ЛЕГЕНДАР ДИВАРЛАРНЫҢ ЯҢА СУЛЫШЫ

Россиянең 1956 елда төзелгән иң зур стадионнарының берсендә илебез спорты тарихына кереп калган шактый гына матчлар узды. Ул дистәләрчә чемпион өчен – alma mater, байтак дөнья рекордларының шаһиты. Һәм спорттагы гына да түгел! «Лужники» стадионының электән килгән мәгърур кыяфәтен саклап калып, шул ук вакытта сыйдырышлылык, иминлек һәм уңайлылык буенча Халыкара футбол федерациясе (FIFA) таләпләренә җавап бирерлек заманча спорт корылмасы булдыру – Мундиаль-2018 уеннарына әзерләнү кысаларында стадионны өченче, иң колачлы реконструкцияләүдә мәшгуль проектчылар һәм белгечләр алдына шундый бурыч куелган иде. Бу эшнең барышы турында безгә проектта катнашучылар – «Казан Гипронииавиапром» АҖ белгечләре сөйләде.

ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ ХЕЗМӘТТӘ – ИННОВАЦИЯЛӘР

– Әлеге чыннан да гаять зур эштә катнашуыбыз белән без горурланабыз! «Мосинжпроект» АҖ, «Метрополис» ҖЧҖ, «СПиЧ» ҖЧҖ коллегаларыбыз белән тыгыз иҗади хезмәттәшлектә без архитектура, конструкцияләр, технология бүлекләренең, шулай ук генераль планның эш документациясен әзерләдек, – ди «Лужники» спорт комплексы Зур спорт аренасын реконструкцияләү проекты баш инженеры Гүзәлия Гайсина. – Спорт аренасының яңа конструктивы (элекке объекттан нибары тышкы диварлар һәм түбә конструкциясе генә сакланып калган иде) бик тыгыз вакыт графигында эшләнде. Һәр 3–5 көн саен эш документациясенең чираттагы комплекты бирелде. Эш көннәрендә генә түгел, кичен, төнлә һәм ял көннәрендә дә эшләдек!

Әмма хәтта шундый катлаулы шартларда да хезмәтнең сыйфаты институт проектчылары өчен иң мөһим критерий булып калган. Белгечләр, максималь төгәллеккә ирешү һәм шул ук вакытта графикка сыешу өчен, проектлаштыруның иң яңа чараларыннан файдаланганнар. Металл конструкцияләр Tekla* программасында, архитектура һәм конструктив элементлар – Revit** программасының BIM***-моделендә эшләнгән, бу чиктәш бүлекләрнең сызымнарындагы тоташмауларны мөмкин кадәр киметкән.

– Әмма эшнең нәтиҗәсе тырышлыкларыбызныаклады, – ди Гүзәлия Тәбриз кызы. – Белгечләребезнең югары грамоталылыгы, иң катлаулы бурычларны хәл итү сәләте, көтелмәгән чишелешләр табу осталыгы безгә, чиктәш эш төркемнәре белән үзара хезмәттәшлектәге кайбер кыенлыкларга, тыгыз вакыт кысаларына һәм эшнең күләме бик зур булуга карамастан, Мәскәү шәһәре төзелеш департаменты куйган срокка җитешү мөмкинлеген бирде. Стадион 2017 елның июлендә файдалануга тапшырылды!

ИҢ ШӘП АРЕНА

Шулай итеп, 2014 елда башланган һәм өч ел дәвам иткән реконструкция тәмамланганнан соң, объект файдалануга тапшырыла. Һәм шунда ук, StadiumDB.com. профессиональ спорт порталы версиясе буенча, 2017 елның иң яхшы спорт аренасы дип танyла. Архитектура ягыннан кыйммәте, функциональлек һәм инновацион технологияләр кебек критерийлары буенча стадион иң югары бәяне ала.

Стадион FIFA стандартларына тулысынча җавап бирә. «Лужники» инфраструктурасы уникаль: стадионда – табигый газон, керткән тупны теркәү системасы куелган, трибуналар футбол кырына мөмкин булганча якынлаштырылган, аларның авышлык градусы зурайтылган. Объектның сыйдырышлылыгы 81 мең кешегә кадәр җиткерелгән. Бинаның эчке периметры буенча урнаштырылган 44 җәяүлеләр баскычы «челтәре» проектлаштырылган. Халыкның аз хәрәкәтле төркемнәре өчен уңайлы шартлар тудырылган, шул исәптән – 300 урынлык аерым трибуна булдырылган. «Иминлек периметры» уникаль системасы каралган. Медиа-түбә турында аерым әйтергә кирәктер, мәйданы 39 мең квадрат метрлы гаять зур түбә-экран уен исәбен, катнашучы командаларның әләмнәрен һәм башка мәгълүматны трансляцияләү өчен файдаланыла.

РУХ САКЧЫЛАРЫ

Яңартылган аренага килүчеләр, стадионны күргәч, соклану хисе кичерә.

– Бу стадионның атмосферасын һәм рухын саклап калуларын сизелә. Проектта тарих белән хәзерге заман уңышлы кушылган! Стадионга кергәндә, йөрәк катырак тибә башлый: бу уенчылар өчен дә, җанатарлар өчен дә искиткеч урын булачак, – дип белдерде FIFA президенты Джанни Инфантино.

«Россия-2018» оештыру комитеты генераль директоры Алексей Сорокин «Лужники» стадионының заманча технологияле булуын ассызыклап үтте:

– Әлбәттә, ул күп яктан уникаль: бу хәтер, тарих та, заманча технологияләрнең искиткеч симбиозы да. Биредә футбол матчларын рәхәтләнеп карап булачак.

– Проектның баш инженеры булarak, бу югары бәягә өстәмә рәвешендә, мин дә әлеге уникаль проектның тормышка ашырылуына бөтен күңелен биреп, көчен сарыф итеп эшләүчеләрне атамый кала алмыйм. Бу «Казан Гипронииавиапром» АҖ баш конструкторы Георгий Никитин, конструкторлар Рөстәм һәм Марат Сафиуллиннар, Тимур Максутов, Андрей һәм Михаил Индейкиннар, Татьяна Галкина һәм башкалар, архитектура остаханәсе башлыгы Галия Уткузова, проектларның баш архитекторы Рөстәм Ибраһимов, архитекторлар Руслан Вәлиев, Татьяна Ганина, Анжела Белова, Фәрит Хисаметдинов, Рамил Галләмов, Борис Блинов, генплан төзүчеләр Лариса Березина белән Дамир Гарифуллин, технологлар Дмитрий Есин, Гөлфия Степанова, Алина Салихова, Ришат Йосыпов, – ди Гүзәлия Гайсина. – Проектны эшләүчеләр коллективының никадәр яшь булуы, һәм аның теләсә нинди катлаулы объектларны проектлау буенча ни дәрәҗәдә һөнәрмәндлеккә ия булуы аңлашыладыр, дип уйлыйм! Яшь белгечләрнең мондый осталыгы һәм грамоталылыгы институтыбыздагы яшьләрне өйрәтү мәктәбенең казанышлары һәм проектлаучылар буынының дәвамчанлыгы турында сөйли!

Казанский Гипронииавиапром

420127, Казан ш., Дементьев ур., 1 нче йорт
Тел. (843) 571-95-48,
факс (843) 571-96-56

Реклама

Фотолар «Казан Гипронииавиапром» АҖнән алынды

*Текла, **Ревит – өч үлчәмле модельләштерү программалары,***Building Information Modeling – БИМ, биналарны мәгълүмати модельләштерү технологиясе

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Олы Әтнәдә футбол өчен **НИЧЕК** җан аталар

Әгерҗе кызлары футбол буенча Россия командасына **НИЧЕК** булыша

Татарстан уенчыларыннан дөнья җыелмасын **НИЧЕК** төзергә

Гёкдениз Караденизкиләчәккә **НИНДИ** хыяллар кора

FIFA





ФУТБОЛ БӘЙРӘМЕНДӘ КАТНАШУЧЫЛАР

ФУТБОЛ ПЛАНЕТАСЫНДА БӘЙРӘМ

Безнең планетада дүрт елга бер тапкыр күңелле метаморфоза булып тора. Бөтен биш континентның да сәясәтчеләре, эшкуарлары, галимнәре, дипломатлары, гади гражданнары бер үк нәрсә – галиҗанәп футбол тирәсендә бөтерелә. Чикләр юкка чыга, төрле милләт вәкилләре бер-берсенә якыная һәм ай буена дөньядагы хакимлекне бөтен армияләр арасыннан аеруча эмоциональ, кыю һәм күптелле булганы – җанатарлар армиясе яулап ала.

Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Казанда һәм Россиянең тагын сигез шәһәрендә үтә торган футбол буенча дөнья чемпионаты-2018 матчлары шулай ук искәрмә түгел. Киң колачлы гаҗәеп футбол спектакле һәр матчта бер генә драматург та уйлап таба алмаслык интригалар, көтелмәгән сюжет борылмалары һәм чишелешләр вәгъдә итә. Башкаручылар арасында – Месси, Роналду, Неймар, Салах һәм башка спорт йолдызлары. Әле тагын – рефери, волонтёрлар, аш-су осталары һәм алардан башка Футбол планетасы бәйрәме мөмкин булмаган башка меңнәрчә кеше. Мундиальдә катнашучы төп затлардан тагын бер катламны күз уңыннан ычкындырырга ярамый – болары гадәти җанатарлар, ягъни – сез һәм без.

Фото: Александр Ефремов, Ната Смирнова

ФУТБОЛЧЫ



ФАРСЫ ШАҺЗАДӘСЕ МӘЙДАНГА ЧЫГА

Сердар Азмун өчен Европаның топ-клублары көрәшә, ә социаль челтәрләрдә аның җанатарлары саны инде күптән миллионның аръягына чыкты. Бүгенгә кадәр ул күләгәдә калуны кулайрак күрсә дә, дөнья чемпионаты прожекторларының яктысы һәркайда үтеп керәчәк.

Автор:
Ксения Сёмина

Сердарның гаиләсе инде алты ел Казанда яши. «Әти-әниең монда ни белән шөгыльләнә», – дигән сорауга футболист болай дип җавап бирә: «Тормыштан тәм табалар». «Алар эшләми. Мин аларның эшләвен теләмим», – ди Азмун һәм бөтен акчасын әти-әнисенә кайтарып бирүен өстәп куя. Иран блогерының Татарстан башкаласында яздырган видеосында Сердарның әнисе аларның Казандагы тормышы ничек көйләнгән икәнен бик рәхәтләнеп бәян итә. Ул бик иркен, ләкин шактый тыйнак җиһазландырылган фатирларын күрсәтә, гадәттә нинди ризыклар әзерләве турында сөйли. Әтисе Хәлил Азмун блогер өчен Казан урамнары буйлап экскурсия уздыра. «Бу – шәһәрнең изге мөселман гыйбадәтханәсе, бик матур мәчет», – ди ул, Кол-Шәрифкә ымлап. Сердарның әти-әниләре үзләрен бик гади тота. Урамда очратсаң, аларның улы дөнья футболының йолдызы, Италиянең «Лацио» командасы «Рубин»нан 15 млн еврога сатып алырга әзер Сердар Азмун икәнен һич уйламыйсың.

БУЫННАН-БУЫНГА КИЛГӘН ТУП

Югыйсә, нәкъ менә гаилә горефгадәтен саклап, Сердар спортка әнә шулай иртә һәм бик уңышлы килә дә. Апалары – профессионал волейболчылар. Ә Хәлил Азмун, Сердар сүзләренчә, үз вакытында Иранның волейбол буенча җыелма командасын җитәкли, аннары озак еллар үзләренең туган каласы Гомбеде-Кавуста тренер булып эшли. Бу шөгылен, бәлки, дәвам да иткән булыр иде, ләкин берничә ел элек узган бер уңышсыз уеннан соң әтисенә карата мөнәсәбәтне ошатмаган Сердар аннан тренерлык эшен ташлавын үтенә.

«РУБИН» ДӨНЬЯСЫНА

Гаиләдә Сердарны волейбол карьерасы ясарга берәү дә кыстамаган. Бик яшьли ул үзен тегесендә дә, монысында да сынап карап, футболны сайлаган. 15 яшьтә Сердар инде «Сепахан»да – Иран чемпионатының югары дивизионында чыгыш ясый торган клубта уйный. 2012 елда футболчы Берлек кубогында (Кубок Содружества) Иран җыелма командасы өчен чыгыш ясый, шунда аны Казанның «Рубин» клубы селекционерлары күреп ала. Унҗиде яшьлек спортчыга кире кагып булмаслык тәкъдим ясыйлар. Ләкин шунда ук түгел.

БАШ ОСТАЗ

Иң элек бер-береңне карауөйрәнү периоды була. «Рубин» делегациясе Сердарның әти-әнисе янына юл тота, аннары Хәлил әфәнде Казанга килә. «Рубин»га күчү карарына нигездә Татарстанның мөселманлык һәм татар теле таралган төбәк булуы йогынты ясады», – дип сөйләде Сердар бер әңгәмәсендә. Монда, Казанда, уенчының холкы да, әлкәннәр сүзен тыңлаучанлык, дини йолаларга хөрмәт белән карау, максатка ирешү өчен үзеңне бик күп әзерләү кебек гаилә тарафыннан сеңдерелгән сыйфатлары да «Рубин»ның баш тренеры Корбан Бердыев белән нәтиҗәле хезмәттәшлекнең нигезен тәшкил итә. Корбан Бердыев Иран егетенең бүген дә төп остазы булып калып, яшь уенчыга дөньякүләм футбол мәйданында яхшы

Фото: «Рубин» футбол клубының рәсми сайтыннан



күренеп торырлык югарылыкка кадәр үсү мөмкинлеген тәэмин итә.

ТУП КЕРТҮ ҖИҢҮ ДИГӘН СҮЗ ТҮГЕЛ

«Ул – Россиянең иң яхшы тренеры. Килешәсезме?» – дип сорады бервакыт Сердар бер журналист кыздан, Корбан Бердыевны күздә тотып. Остазы турында сөйләгәндә, Иран егете һәрвакыт аның клуб эшендәге уңышларын искә ала, әйтик, нәкъ менә Корбан Бердыев тырышлыгы белән «Ростов»ның 2015/2016 еллар сезонында күрсәткән дәрәҗәсенә күтәрелүен. Клубны Премьер-лигада саклап калу өчен керткән үз өлеше турында Азмун телгә алмый – аңа тыйнаклык хас. Аның каравы, Корбан Бердыевның гадел, аяусыз таләпчәнлеген, уенчыны иң югары дәрәҗәдә файдалана белүен мактап уза. «Син «Бавария»гә гол керттең икән, үзеңне күкнең җиденче катына күтәрелдең дә, һичкайчан шуннан егылып төшмәссең дип уйларга ярамый», – дип, футболчы остазының сүзләрен дә мисалга китерә.

ГЕРОЙНЫ ТӘРБИЯЛӘҮ

«Азмун – миңа якын кеше. Ул төрекмән булганга гына түгел (Корбан Бердыев үзе дә чыгышы белән төрекмән – ред. иск.). Аның табигать тарафыннан бирелгән сәләтенә килгәндә, ул бит әле бернәрсә дә эшләмәде. Үзен югары дәрәҗәдә ни-нәрсәгә сәләтле икәнен расласын. Сердар футболда беренче адымнарын гына ясый, ул артык яшь әле. Аның белән саграк булырга кирәк. Мин аның белән башкалардан кырысрак сөйләшәм. Моңа хакым бар. Әтисе миңа бөтен ысулларны кулланырга рөхсәт бирде», – 2016 елда Ростов клубының матбугат хезмәте аркылы Корбан әфәнде Сердарга мөнәсәбәтен әнә шулай ачыклап китте. Ул елгы уңышлары өчен, шул исәптән 2018 елгы дөнья чемпионатына сайлап алу уеннарында Иран җыелма командасы белән керткән дүрт голы өчен Сердар Азмун Азиянең иң шәп яшь футболчысы булып танылды. Аны еш кына «Фарсы шаһзадәләренең берсе», «Иран Месси» дип атыйлар, чынлыкта исә футболчы үзенең кумиры итеп Златан Ибрагимовичны телгә ала («Шундый буе белән дә ул техник яктан осталык күрсәтә ала!» – дип аңлата Сердар).

ИЛНЕҢ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ – КЛУБ ТҮГЕЛ

Азмун клубташлары белән һәрчак яхшы мөнәсәбәттә. «Ростов»та уйнаганда, Джанаев, Гацкан, Калачев, Кудряшов, Навас, Нобоа һәм Эзатолахине ул «туганнарым» дип атый иде, «Рубин»нан Тарас Бурлак һәм Магомед Оздоев белән дуслыгын да яшермәде. Сүз уңаеннан, 2017 ел ахырында элеккеге футболчы Стэн Коллимор белән әңгәмәсендә Сердар Россия клублары (карьерасындагы барлык 137 уенда 37 гол) һәм җыелма команда (33 уен, 23 гол) өчен керткән тупларның аермасы хакында мондый аңлатма биреп үтте: «Илең өчен чыгыш ясау һич тә клуб өчен уйнау белән бер түгел. Илнең җыелма командасында уенчылар арасында бәйләнеш көчлерәк. Клуб белән җыелма команда өчен уеннарның аермасы – бердәмлекнең дәрәҗәсендә».

ТӨРКЕМНӘН ЧЫГАРГА

23 яшендә инде Азмун – Иран җыелма командасының чын йолдызы. «Ул көчле, яхшы уенчы, һәм аның уйнавы безнең өчен бик мөһим. Ул дөнья чемпионатында безгә бик булыша ала. Португалия һәм Испания командалары кәгазьдә бик көчле, ләкин футбол – 90 минут дәвам итә торган уен, анда теләсә нинди хәл килеп чыгарга мөмкин», – дип белдерде ТАСС агентлыгына җыелма команда уенчысы Масуд Шоджаи. Сердар исә аек акыл белән фикер йөртү яклы: «Дөнья чемпионатында чыгыш ясау бәхете әле бөтен футболчыга да тәтеми. Турнирның финал өлешенә сайлап алыну да – зур уңыш инде ул. Минем өчен төп максат – илебезнең җыелма командасы төркемнән чыксын өчен, бар көчемне биреп тырышу».

ЕВРОПАГА ТРАМПЛИН

Ләкин уңышлы уздырылган чемпионат Азмун өчен Европа лигаларының берәр клубына күчүдә ярдәмче трамплин булырга мөмкин. Былтыр җәй Сердарның «Лацио»га трансферын туктатып калган Корбан Бердыев сүзләренчә, скаутлар «Рубин»га һәм Сердарның әтисенә көн саен шалтырата. Кызыксынучыларның исемлек башында – «Арсенал», «Селтик», «Эвертон» кебек топ-клублар. Шул ук вакытта Италия матбугаты хәбәренә ышансак, итальяннар тәкъдим иткән 15 млн евро урынына Россия клубы уенчы өчен 20 млн евро сораса да, Азмунның «Рубин»нан «Лацио»га трансферы – инде хәл ителгән мәсьәлә. Икенче яктан, Азмун бервакыт Англиянең премьер-лигасында уйнарга теләвен белдергән иде...

ДАН ЙӨГЕ БИК АВЫР

Инстаграмда Азмунның сәхифәсенә ике миллионнан артык кеше язылган. Корбан Бердыев яшь уенчының мондый даннан, танылганлыктан башы әйләнеп китәр дип, шактый борчыла. Сердарның 2017 елгы – «Рубин»да уздырган бик аз нәтиҗәле ярымсезоны турында «Бизнес-онлайн»га биргән әңгәмәсендә тренер мондый аңлатма бирә: «Азмунның миллионлаган җанатары бар, аңа иситкеч игътибар күрсәтелә – ул менә шушы йөкне күтәрә алмады... Аллаһның аны шулай сынавына мин шөкер итәм. Ул бөтенләй бер гол да кертмәгән булса, тагын да яхшырак булыр иде әле».

Сүз уңаеннан, Инстаграмдагы «Fun times» («Күңел ачу вакыты») дип исемләнгән соңгы фотосында Сердар бик хәйләкәр елмая. Ә беләгенең арткы ягын «Мин кем – шуның өчен ярат» дигән язулы татуировка бизи.

ҖАНАТАР

БӘЙРӘМ ТЕЛИ КҮҢЕЛ!

Яраткан командасы артыннан калмыйча йөреп, трибуналарда төрле тилелекләр кылучы дуамал җанатарлардан түгел ул. Ләкин аның футбол «чир»ен җиңелләрдән дип әйтеп булмый, ник дигәндә, бу «чир» инде ярты гасырга сузылган.

Автор:
Алсу Троицкая

> – Мин чемпионат башланыр көннәрне түземсезлек белән көтәм. Бөтен матчларны да карап, матур футбол өчен җан атачакмын. Әлбәттә, үз күзләрем белән барып карау теләге бик зур! Бөтен җанатарларга да матур уеннар телим, аларның дөнья чемпионаты матчларына сәфәрләре чын бәйрәмгә әйләнсен!

ГЕЛ ЯШЬ!

– Командаң өчен ут йотып тору, аңа бөтен көчеңне һәм энергияңне бирү – файерлар һәм петардалар яндыру дигән сүз түгел бит әле ул, – дип аңлата Камбил Якупов. – Ни гаҗәп, андый «җанатарлар» өчен футбол, минемчә, кызык та түгел, алар уен серләрен өстән-өстән генә белә. Җанатарлар белән фанатларны бутарга ярамый. Алар арасында аерма бик зур. Җанатарлар арасында да төрле категорияләр бар. Кемдер билгә кадәр чишенеп, киемен болгый, кемнәндер ипи шүрлегенә дә менеп төшә, уен буе «сөрән»нәр кычкыра. Андыйларсыз матчларда, мөгаен, бик күңелсез, артык тыныч булыр иде. Ә без бит – авыл кешеләре, гади, тыйнак, җан атуыбыз да тыенкырак, күзгә бәрелеп тормый. Ләкин бу тышкы яктан гына шулай. Без эчтән янабыз. Футбол караганда, күңелемдә нинди давыл уйнаганын үзем генә беләм! Дөрес, үзем яраткан «Рубин» командасының символлары төшерелгән шарфны урамыйм, бәлки, бу кимчелектер дә. Тик кем белә, бәлки, әле киләчәктә киеп-урап та куярмын, – дип елмая Камбил Мәһдиевич, – күңел бит ул гел яшьлектә!

СПОРТТАН – СПОРТКА

– Мин туып-үскән һәм хәзер яши торган Олы Әтнәдә без әле балалар гына вакытта әллә ни ис китәрлек спорт корылмалары булмады. Әмма без, малайлар, спортны шулкадәр яраттык, спортзалга уйнарга кертмәгән өчен җыештыручыны әләкләргә дип мәктәп директорының өенә йөгерә идек. Кулыбызга рөхсәтле язу кисәген тотып, аннан зур җиңүчеләрдәй кире мәктәпкә чабабыз. Әлбәттә, җыештыручы апа җитәкчеләргә каршы килә алмый иде...

1974 елда, пединститутның физик тәрбия факультетын тәмамлаганнан соң, ул мәктәп спортзалына яңа дәрәҗәдә әйләнеп кайта. Шул вакыттан бирле гел балалар белән эшли – мәктәптә физкультура укытучысы, республиканың Әтнә, Кукмара районнарында балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбендә волейбол һәм футбол буенча тренер. Хезмәт юлында бер генә тәнәфес бар – ул елларда укытучыларны армиягә җибәрмәсәләр дә, институттан соң Камбил республиканың хәрби комиссарыннан армиядә хезмәт итеп кайту мөмкинлеген сорап ала.

– Ышанасызмы-юкмы, спорт бүген дә бик күп проблемаларны җиңеп чыгарга булыша. Күңел төшенкелегенә урын калдырмый. Кәеф юк икән – бераз йөреп киләсең, йөгереп аласың, туп тибәсең. Һәм тормыш җайлангандай тоела, төсләргә байый, – дип сөйли Камбил Якупов. – Шәкертләрем алдында минем бурычым – бик тыйнак. Ләкин аларның күбесе, хәтта бөтенесе дә диярлек, спортны үзләренә көндәлек «корал» итеп алды. Әлбәттә, хобби турында гына сүз бара, ләкин бу аларга җыелып килгән негатив энергияне кешечә – хәмерсез һәм башка шуның ишеләрсез генә бушатырга мөмкинлек бирә. Минем өчен иң мөһиме шул.

«МИН – «РУБИН» ҖАНАТАРЫ, БУЛДЫМ ҺӘМ БУЛАЧАКМЫН!»

Бүген балалар спорт белән бик аз кызыксына шул, дип уфтана элеккеге футбол тренеры, югыйсә, шөгыльләнер өчен бөтен шартлар да бар хәзер – спортзаллар да, спорт мәйданчыклары да, киеме, аяк киеме – җаның нинди теләсә шул. Ләкин балалар телефоннарын кочаклап утыра.

– Хәер, футбол белән саташканнары да бар. Алар ишегалдында туп тибүдән генә сөенеч тапмый. Яраткан уеннары белән тренер кул астында шөгыльләнәләр, – дип билгеләп уза Якупов.

Олы Әтнәдә чыннан да андый малайлар бар. Ә балалар футболы монда бик шәп тренер – Таһир Вәлиуллин тырышлыгы белән үсеп килә. Ул малайларны уенга өйрәтә, алардан чын ир-егетләр тәрбияли.

Камбил әфәнде белән бергәләп чираттагы тренировканы күзәтергә юл тотабыз. Малайлар

Фото: Александр Ефремов

уен кырында җитез-җитез йөгереп, бер-берсенә туп тапшыру күнегүен кабатлаган арада, футбол буенча элеккеге һәм хәзерге тренер белән гәп корабыз.

Камбил Мәһдиевич гомере буена «Рубин» өчен җан ата. Тренерның хезмәт хакы бик тыйнак булса да, ул яраткан командасының үз кырындагы уеннарын күзәтү өчен Әтнәдән Казанга бару җаен таба. Тренер үзенең шәкертләренә дә футбол, «Рубин» «чирен» йоктырган:

– Ул чакта бөтен Казан, шул исәптән мин дә унберенче санлы Мурад Задикашвилиның уенына соклана идек. Кыскарак кына буйлы, тыгыз тәнле, җилдән җитез реакциягә ия гаҗәеп өлгер грузин егетен карарга туп-тулы стадион халык килә иде. Клубның үзәк һөҗүмчеләренә биргән нәтиҗәле паслары исә тел шартлатырлык! Шул вакыттан бирле мин «Рубин» уеннарына гел йөрдем. Бара алмасам, телевизордан карый идем, ләкин бер уенны да калдырмадым. Командага тренер булып Корбан Бердыев килгәч – бигрәк тә. Карагыз әле, нинди генә салкын булмасын, ул стадионда пәлтә яки йон-мамыклы куртка түгел, ә костюм киеп утыра. 20 градус салкында – җылы киемсез! Ул бернинди суыкны сизмидер кебек тоела миңа. Моны футболчылар да, җанатарлар да күрә. «Рубин»ның иң төп җанатары нәкъ менә Бердыев үзедер дип уйлыйм. Әйе, аның контратакаларга нигезләнгән тактикасы күпләрнең күңеленә хуш килмәскә дә мөмкин. Атакага корылган футбол, һичшиксез, тамаша кылу өчен матуррак, кызыклырак. Ләкин операция ясаганда хирургка ялгышырга ярамый, бу – пациентның тормышы өчен куркыныч дигән сүз. Монда да, минемчә, нәкъ шулай. Гомумән, кире кайткан Бердыев кул астында «Рубин» Европада үзенең танылган исемен, хөрмәтен янә яулар, Россиянең футбол беренчелегендә исә элеккегечә медальләр өчен көрәшер, дип уйлыйм һәм шуңа ышанам. Өстәвенә, Корбан Бердыевның таланты теләсә нинди уртакул уенчыдан яхшы футболчы ясарга мөмкинлек бирә. Аңа эләккән егетләр яңа яктан ачылып уйный башлый. Җанатар буларак, моның өчен аны бик хөрмәт итәм.

Яраткан командаларымның тагын берсе – Мадридтан «Реал», – дип елмая Якупов. – Бу, әлбәттә, бөтенләй башка уен. Озын-озын паслар матур да, бик төз дә. Туп әле генә штраф мәйданчыгында иде, бер мизгелдә озын пас белән көндәшләр зонасына килеп җитә. Ләкин ул клубта уенчыларның дәрәҗәсе дә бөтенләй башка. Финанслар да башкарак…

– Шулай булгач, «Рубин» өчен җар атарбыз! – дип, хезмәттәшенә ярдәм кулын суза Таһир Вәлиуллин. – Ә хәзергә менә дөнья чемпионатының Франция–Австралия матчына элэгәсебез һәм Антуан Гриззманның уенын үз күзләребез белән күрәсебез килә. Стадионда бөтенләй башка атмосфера ич! Минем бик күп футбол матчларында булганым бар. Фәкать 1985 елның сентябрендә футбол буенча СССР белән Дания җыелма командалары арасында дөнья чемпионатына сайлап алу матчы гына хәтердә уелып калган. Андый хис-тойгыларны мин башка беркайчан да кичермәдем: җанатарлар гөрелтесе стадион тирәсендә үк ишетелә иде һәм ул матч буе тынмады. 100 мең кеше сыйдырышлы «Лужники» трибуналарында бер буш урын да юк. Ә туп Федор Черенковка эләккәндә исә стадион шартлар дәрәҗәгә җитә! Ул чакта безнекеләр 1:0 исәбе белән отты. Җиңү китергән голны Днепропетровск «Днепр»ыннан Олег Протасов кертте.

ВОЛОНТЁР

ЧЕМПИОННАРГА **ВОЖАТЫЙ**

Футбол буенча дөнья чемпионатында Тимур Туфетуловның мөһим миссиясе бар. Стадионда – спортчылар зонасында – ул Испания һәм Колумбия командаларына ярдәм итәчәк. Җаваплылык зур, тик борчылыр урын юк – Тимур бай волонтёрлык тәҗрибәсенә ия һәм кырыкка якын эре чарада катнашырга өлгергән зат.

Автор:
Катерина Котова

ҺӘРКАЙДА ҮЗЕҢНЕКЕЛӘР БУЛСЫН!

Чемпионнар лигасы кысаларында узган «Зенит-Казан – Перуджа» волейбол матчында Тимур Туфетулов берьюлы... ике команда өчен дә җан аткан. Казан спортчылары – үзебезнекеләр, ә итальяннар белән май аенда Татарстан башкаласында узган «Дүртлек финалы» вакытында туганлашып калганнар диярлек!

– Бу гаҗәеп тәҗрибә! – дип, үз тәэсирләре белән уртаклаша Тимур. – «Перуджа» клубы командасында Италия егетләре генә түгел, дөньяның төрле илләре – Аргентина, Австрия, Финляндия, АКШтан килгән легионерлар да бар иде. Ә мин – аларның атташе-тәрҗемәчесе. Һәм бу аралашу үзенә бер күңел җылылыгы белән истә калды. Без күп вакытыбызны бергә уздыра идек, һәм алар мине бик тиз үз командаларына алды.

Бу Тимурның волонтёрлык карьерасындагы кырыгынчы чара дисәк тә була. Аңа социаль проектлар да ят түгел, әмма күбесе спорт вакыйгалары булып чыга. Бадминтон буенча өч дөнья чемпионаты, регби буенча дөнья чемпионаты, су спорт төрләре һәм суга сикерү буенча дөнья чемпионатлары, Конфедерацияләр кубогы турнирлары... Әмма, мөгаен, бу спорт бәйрәмнәре тезмәсендә Тимур өчен иң якты эпизод Универсиада булгандыр. Дөресен генә әйткәндә, нәкъ Универсиададан соң ул үзенең тормышын волонтёрлык белән бәйләгән дә инде.

– 2013 елда мин инглиз теле буенча тирәнтен белем бирүче мәктәптә укый идем, – дип сөйли Тимур. – Шәһәр волонтёрларын җыюлары турында безгә укытучыбыз сөйләде. Кызыксынып киттем – бу яңалык иде! Безгә исә реаль тәҗрибә кирәк, чит ил кешеләре белән аралашасыбыз килә иде. Австралиядә, Төньяк Мариан утрауларында һәм, әйтик, Габонда яшәүче кешеләрне бер үк вакытта тагын кайда очратырга була?

Универсиада алдыннан волонтёрлар өчен уздырылган курсларда яшьләрне бер үк вакытта мәдәниятара коммуникацияләргә дә өйрәткәннәр. Мәсәлән, японнарны кул биреп түгел, ә баш иеп сәламләргә кирәк икән, гарәп илләрендә бераз соңаруның гадәти хәл булуын онытмаска кирәк, ә Германия кешеләренең, киресенчә, пунктуальлекне өстен куюын.

– Шәһәрне кабатланмас атмосфера биләп алган иде! – дип искә ала Тимур Универсиаданы. – Җиңү проспекты безнең үзәк ноктабызга әверелде – чит ил кунакларының иң зур агымы шуннан уза иде. Без, дуслык символы булган һәм һәрчак ярдәм итәргә әзер торуыбызны гәүдәләндергән ачык төсләрдәге кул сурәтләре таратып тордык. Объектка ничек барып җитәргә, матч расписаниеләрен кайда күрергә, шәһәрдә нәрсәләрне карау яхшырак булуы турында сөйләдек. Еш кына әңгәмә оешып, җанланып китә – монысы да безнең вазыйфага керә иде.

Универсиадага кадәр туризм Казанда әллә ни үсеш алмаган иде әле. Безгә килүче кешеләр нигездә стереотипларга таяна. Бәхеткә, алар инде хәзер безнең урамнарда аюлар йөри дип санамасалар да, килгәнче безне аралашу өчен бик кырыс һәм йомык халык дип уйлаганнар. Тимур әйтүенчә, Универсиада чит ил кунакларына безне бөтенләй башкача итеп ачып күрсәтә: баксаң, казанлылар бик тә ачык күңелле һәм кунакчыл икән.

– Мин шулкадәр ачык кеше булачагымны үзем дә көтмәгән идем, – ди ул. – Волонтёрлык кысаларны алып ташларга ярдәм итте. Мин аралашу барьерларын, шул исәптән тел каршылыкларын да җиңәргә мәҗбүр булдым. Мәктәптә безгә грамматика өйрәтәләр бит, ә менә тел тәҗрибәсе алырдай урын әллә ни юк. Минем арсеналда – инглиз генә түгел, немец, испан, япон телләре дә бар. Сүз уңаеннан, Европадагы яшьтәшләрем күзлегеннән караганда, мин һич тә полиглот түгел. Хәзер үзлегемнән итальян һәм төрек телләрен өйрәнәм. Волонтёрлык бу эштә булыша – башка телдә көненә 9ар сәгать сөйләшәсең икән, шул телдә уйлый да башлыйсың. Кайчакта мәзәк хәлләр дә килеп чыга. Бервакыт шулай Бөекбритания командасы белән автобуска утырдык та, мин йөртүчегә кая барасыбызны әйттем, ә ул: «Син шуны ук русча әйтә алмассыңмы?» – дип сорады. Мин шунда гына аның белән инглизчә сөйләшүемне аңлап алдым. Тагын бер очрак: акча аласы бар иде, ә мин «банкомат» сүзен онытып тордым гына бит! Мондый кызык мизгелләрне соңыннан аерым бер җылылык белән искә төшерәсең.

ИҢ КЫЙММӘТЛЕ ТӘҖРИБӘ

Су спорты төрләре буенча чемпионат Тимурның хәтеренә Австралиядән килгән ватерпол командасы белән кереп калган. Әлеге 26–27

Фотолар Тимур Туфетулов архивыннан

яшьлек егетләр чынлыкта гамьсез малайларга тиң булып чыккан, Тимурга аларны чын мәгънәсендә үз карамагына алырга туры килгән.

– Иң беренче сәер хәл: тренировкага барганда, болар табибны онытып калдыра яздылар. Шунда мин вазгыятьне үз кулыма алырга кирәклеген аңлап алдым. Чынлыкта мин алар өчен көн планын төзеп торучы менеджерга әверелдем. Һәм бу бик кызыклы да иде!

Тимурның Универсиададан соң ук мавыгып киткән атташе роле үз эченә күп төрле опцияләрне сыйдыра ала. Әгәр берәр чит ил командасына бары тик тәрҗемәченең озатып йөрүе генә кирәк булса (мәсәлән, бик тә оешкан һәм һәр эштә төгәллек яраткан инглизләр белән шулай булган), икенчеләре белән исә, чын вожатый булып, югалган багажларын эзләүдән башлап, күңелле кичә оештыруга кадәр күпсанлы мәсьәләләрне хәл итәргә туры килгән.

– Бадминтон буенча Европа чемпионатында минем испаннар беренче урын алды, – дип искә ала Тимур. – Егерме кешелек банкет оештыру өчен – бер дигән сәбәп! Ә миңа бу турыда бөтен рестораннар шыплап тулган шимбә кичендә генә хәбәр иттеләр. Әмма мәсьәлә куелган, аны чишәргә кирәк. Бу – волонтёрлык бирә торган иң кыйммәтле тәҗрибә. Ул сине югалып калмаска, бөтен сорауларга һәм теләкләргә тыныч карарга, тиз арада карар кабул итәргә өйрәтә. Нәтиҗәдә барысы да бик яхшы килеп чыкты. Бу татар ашлары ресторанны иде, анда миңа менюны тәрҗемә итәргә туры килде, чөнки испаннар инглизчә белми. Аның каравы, алар шат күңелле, ачык һәм сөекле. Һәм, әлбәттә инде, шаушулы! Кич буе тостлар әйттеләр, котлау өчен хәтта миңа да сүз бирделәр. Мине шулай тиз генә үз командаларына кабул итүләре бик рәхәт булды.

ТЫНЫЧЛЫК – УЛ ДУСЛЫК

Күптән түгел Тимур Италия буйлап сәяхәт иткән. Анда үзенең дусларын – үзе кебек үк волонтёрларны очрату гаҗәп күңелле булган. Испаниягә сәяхәте дә күптән көтелгән очрашулар белән тулып торган. Башкача була да алмый, волонтёрлык нәтиҗәсендә дөньяның йөздән артык илендә дусларың пәйда булсын да!

Аның волонтёрлык «хәзинәсе»ндә – Швециядәге WorldSkills эшче профессияләре чемпионаты линиясеннән башлап, берничә чит ил чарасы да бар. 2016 елда узган EuroSkillsта Тимур карамагына агач эше осталары мәйданчыгын тапшырган булалар. Ә инде тагын бер елдан соң ул Абу-Дабидагы дөнья чемпионатында бәһасез тәҗрибә ала.

– Россиядә волонтёрлык, ни дисәң дә, әлегә аерым структура булса, Абу-Дабида син шунда ук оештыру комитетының бер өлешенә әвереләсең. Һәм бу бик шәп! Ә мондый чараларны башка илләрдә ничек оештыруларын белү безгә 2019 елда, Казанда үзебез WorldSkills чемпионатын кабул иткәндә, һичшиксез, кирәк булачак.

Абу-Дабида читтән килгән волонтёрлар шундагылар белән пар-пар булып эшләгән. Тимурның пары Хамдан бик тә ачык йөзле һәм кунакчыл егет булып чыккан. Ул шунда ук аңа шәһәрне күрсәткән, үзләренең милли мәдәнияте белән таныштырган, әмма беренче көннән үк аның россиялеләргә хас булган сыйфат – йөкләмәләргә һәм төгәллеккә әзер түгеллеге ачыкланган.

– Андагы җирле волонтёрлар таркаурак, – дип сөйли Тимур. – Алар соңга калырга яки, берәр танышларын очратып, озын-озак гәп сатуларга бирелергә мөмкин. Бездә, кемгә дә булса ярдәм кирәксә, егетләр шул арада җыелып ала, анда мондый чакыруларга тиз генә игътибар да итмиләр. Бездә волонтёрларның функциональ бурычлары нюансларга кадәр җентекләп язылган, ә анда мин мондый төгәллекне күрмәдем.

2016 елда Франциядә FISU Халыкара университет спорты федерациясе форумында Тимур Татарстан башкаласында волонтёрлар өчен «FISU Volunteer Leaders Academy 2017» Халыкара белем бирү форумы үткәрү инициативасы белән чыга. «Безнең уртаклашыр тәҗрибәбез бар, һәм без дөньяның төрле илләрендә волонтёрлык хәрәкәтен үстерүгә ярдәм итә алабыз», – ди ул чакта язмабызның каһарманы. Бер елдан Казан 91 дәүләтнең 110 волонтёрын каршы ала.

– Россиядә волонтёрлык хәрәкәте бик нык үскән, ә Казанда, Универсиада мирасына бәйле рәвештә, аның стандартлары чын мәгънәсендә югары дәрәҗәгә җиткән, – ди Тимур. – Көндәшлек коточкыч зур. Башка илләрдә иренмәгән теләсә кемне сөенеп кабул итсәләр, бездә волонтёр булыр өчен, шул исәптән ФИФА волонтёры булыр өчен дә, теләк һәм активлык кына җитми. Хәзер хәтта инглиз телен белү дә җитәрлек дәлил түгел. Тәҗрибәң булу, зарури мәсьәләләрне хәл итә белү, позитив булу кирәк – таләпләр исемлеге шактыйга җыела.

Бүгенге көндә Тимур футбол буенча ФИФА-2018 Дөнья чемпионатын көтү халәтендә яши. «Конфедерацияләр кубогына карап фикер йөртсәң, бу искиткеч киң колачлы чара булачак!» – ди ул һәм Чилидан килүчеләрне искә төшерә. Чөнки шау-шулы, якты күңелле һәм позитив яшьләр бөтен Казанны илһамландырган була!

Әмма волонтёрлар аралашу вәгъдә иткән шатлыкка гына түгел, ә штаттан тыш хәлләргә дә әзер. Бойкотлар, провокацияләр, эвакуация – болар һәммәсе дә махсус тренингларда өйрәнелгән. Тимур конкурсны үткән һәм аңа иң җаваплы участокларның берсен ышанып тапшырганнар – ул килеп туган мәсьәләләрне стадионда, спортчылар зонасында хәл итәчәк.

– Испания һәм Колумбия командаларына булышырмын, дип өметләнәм, – ди ул. – Спорт йолдызларын күрә алырмын, үз чыгышларына аларның ничек әзерләнүен күзәтермен, эмоцияләрен үзем аша үткәрермен – кыскасы, чемпионатның кабатланмас энергетикасын сеңдерермен. Мин моны чын күңелдән дулкынланып көтәм!

РУХЛАНДЫРУЧЫЛАР

БОЛ-ГЁРЛЗ: ФИФАНЫҢ ЯШЕРЕН КОРАЛЫ

Дөнья чемпионаты-2018нең 14 июньдә «Лужники»да үткән ачылу матчында Россия җыелма командасы үзе өчен җан атуларның искиткеч булуын күргәндер. Җанатарлар тарафыннан гына да түгел, юк. Уенчылар белән янәшә, кыр читендә үк, 90 минут буе Бол-гёрлз, үзебезнең Әгерҗе кызлары булды!

Автор:
Алсу Троицкая

МЕНӘ ШУНДЫЙ КЫЗЛАР ФУТБОЛЫ

«Кадетлар» кызлар футбол командасының тренировкасын залга күчергәннәр. Моңа җәйнең күңелсез башлануы «гаепле» – тышта биш градустан да югарырак түгел. Ә биредә, залда, тупка тибү тоташ канонадага әверелә – ирексездән колакларымны каплыйм да күзләремне йомам. Кызлар көлә генә – бу алар өчен гадәти күнегүләр. Капкада Валерия Шмелёва – ул кырыс һәм җитди.

Футболчы кызлар удар, финт һәм пасларны кабатлаган арада, команданың тренеры Илдар Идиятов белән сөйләшергә тырышабыз.

– Футбол ни өчендер бары тик ирләр спорты булып кына санала. Килешмим. Әйе, ирләр футболы ярсурак, югары тизлектәрәк, аның каравы, хатын-кыз уенының башка үзенчәлекләре бар. Ул шулай ук тамашачыларны кызыксындырудан туктамый. Хатын-кыз футболы бары тик ирләрнекеннән үзгә, шул гына. Безнең кызлар хәзер нәкъ менә фубол сыйфатларын үстерү өчен иң отышлы яшьтә – 15–16да, – тренер үзенең сүзен безнең якка туп очып килгән мәлдә тәгәлләп өлгерә. Процесска кушылып китеп, Илдар Рәмисович тупны кызларга кайтара да, сүзен дәвам итә:

– Футболчы кызлар ия булырга тиешле төп сыйфатлар – җитезлек, тизлеккә чыдамлык, тактик күнекмәләр, ихтыяр көче. «Кадетлар»да боларның барысы да бар. Һәм, минемчә, аларның күбесе футболлы киләчәк өчен җитди перспективаларга ия.

БОЛ-ГЁРЛЗ. МУНДИАЛЬ ТАРИХЫНДА – БЕРЕНЧЕ

Әгерҗе кызларының спортчылар өчен бик мөһим тагын бер сыйфаты бар икән – ул да булса тәвәккәллек. Әлеге сыйфат кызларга, хыялларын тормышка ашырып, һәркем дә булырга теләгән искиткеч зур бәйрәмдә катнашу мөмкинлеген биргән. Футбол буенча дөнья чемпионаты-2018 гә путевканы алар #ГотовыКПодаче! интернет-конкурсында откан. «Бол-бойз» Бөтенроссия конкурсы «Күн туп» турнирында теркәлгән һәвәскәр яшьләр командалары арасында үткән. Конкурста катнашучылар ВКонтакте социаль челтәрендә рәсми төркемдә сайлау башлануы турында репост ясарга һәм үз тормышларында футболның роле турында җыйнак кына инша язарга тиеш булганнар. Жюри иң яхшы эшләрне сайлап алган. Ә җиңүчеләрне футбол буенча Россия җыелма командасы уенчылары сайлаган. Кызларны җиңүләре белән котлап, Россия җыелмасы сакчысы Фёдор Кудряшов аларның футбол буенча ФИФА дөнья чемпионаты ачылу матчында тупларны биреп торачагын игълан иткән. Бу хәл турнир хуҗаларының Согуд Гарәбстаны командасы белән очрашуында булачак. Уенчыларга тупларны кызлар командасының бирүе – моңа кадәр мундиальдә булмаган хәл.

Күнегүләрне туктатып, Илдар Рәмисович безгә үз шәкертләре белән сөйләшү мөмкинлеге бирә.

– Мондый шанс гомергә бер генә бирелә. Без дөнья спорты йолдызлары белән янәшә торачакбыз. Моның белән бик нык горурланабыз, – дип сөенәләр кызлар, һәм шунда ук авыр сулап:

– Тик алар янына якын килергә дә, сүз әйтергә дә, автограф алырга да мөмкин булмаячак: кагыйдәләр буенча тыелган, – дип өстиләр. – Аның каравы, без шушындый дәрәҗәдәге футболны «тереләй» күрәчәкбез! Һәм үз кумирларыбыз белән янәшә үк торып күрәчәкбез.

Әмма капкачы Валерия Шмелёва барыбер беркадәр борчыла. Игорь Акинфеевтан автограф алып булмаячагына уфтана:

– Шулай да без Бол-гёрлз эшен намус белән үтәргә вәгъдә итәбез. Хәтта безнекеләр откан чакта да тупны тоткарламаска. Монда

Фото: Александр Ефремов

эш принципта – барысы да гадел булырга тиеш. Бу – спорт!

«БЕЗ ФУТБОЛ БЕЛӘН ЯШИБЕЗ!»

«Кадетлар» кызлар футбол командасы – республика беренчелегенең бронза призёры, «Күн туп» ярышларының төбәк этабында көмеш медаль иясе һәм Президент ярышларының төбәк этабында җиңүчесе.

Яз көне Әгерҗенең футболчы кызлары ике дәрәҗәле турнирда уңышлы катнашкан. Башта алар минифутбол буенча Казанда үткән «Футболга чикләр юк» Бөтенроссия ярышларында, Мәскәү кызларын 4:3 исәбе белән отып, җиңүгә ирешкәннәр. Тагын бер атнадан Алабугада «Күн туп» ярышларының төбәк этабында икенче урын алганнар. Шул ук вакытта алар бер генә уенда да бер генә голны да үткәрмәгән. Бары тик туплар аермасы гына «кадетлар» файдасына булып чыкмаган. Кызлар чын мәгънәсендә футбол белән яши, һәм үзләрен аннан башка күз алдына да китерми. Ә Мәскәүгә барачаклары турында аларга тренерлары сөйләгән.

Һөҗүмче Елизавета Мерзлякова, сөенечен яшерми:

– Башта мин малайлар белән бер командада уйнаган идем. Шуңа төгәл беләм – футбол һәркем өчен дә бер үк уен. Бары тик малайларның ул канында, ә кызларга, яхшы уйнарга өйрәнер өчен, көч түгәргә туры килә. Шуңа күрә җиңү дә рәхәтрәк. Менә бу ачылыш матчына баруыбыз – шуларның берсе. Илдар Рәмисович безне җыеп, күзләребезне йомарга кушкач һәм безнең конкурста җиңүебез турындагы хатны укыгач, барыбыз да шаккаттык. Бик сөендек. Бу онытылмас вакыйга!

Дарья Васильева, һөҗүмче:

– Безнең футбол белән шөгыльләнүебез эксперимент кебек башланды. Башта моннан нәрсә килеп чыгачагын белү кызык иде. Һәм бу кызыксыну көннән-көн арта барды. Хәзер инде үзебезне күнегүләрдән, командадан һәм уеннан башка күз алдына да китермибез. Бу – моңа кадәр беркайчан да татып карамаган эмоцияләр...

> **“ – Футболчы кызлар ия булырга тиешле төп сыйфатлар – җитезлек, тизлеккә чыдамлык, тактик күнекмәләр, ихтыяр көче. «Кадетлар»да боларның барысы да бар.**

Юлия Шустова, ярымсакчы:

– Мин футболның ирләр спорт төре булуы белән килешмим. Ә инде травмаларга килгәндә, алар спортның һәр төрендә дә бар. Хастаханәдә дәваланып аласың да тагын уйнарга ыргыласың! Иң мөһиме – команда һәм сугышчан рух. Менә безнең капитаныбыз Карина Батырова кырда үзенең һәр уенчысын яклый ала. Аның да травмалары күп...

«КАДЕТЛАР»НЫҢ ИНШАЛАРЫННАН...

Карина Батырева, капитан, һөҗүмче:

«...Безнең команда бик тату, һәр уенчы берберсенең ярдәмен тоеп тора, кирәк булганда, иптәше өчен терәк була ала һәм аны кыерсыттырмый.
Без күп җиңүләргә ирештек, әмма спортта җиңелүсез буламы? Һәр оттырган уеныбыз безне көчлерәк итә һәм алга таба тагын да көчәйтелгән күнегүләр ясарга мотивация бирә. Кырга чыкканда һәрвакыт үз алдыбызга тупны оту һәм көчле эмоцияләр алу максатын куябыз. Уенга без аерым әзерлек белән көйләнәбез. Бөтен командабыз белән түгәрәкләнеп утырабыз да уен дәвамында тупны кемнең ничек тибәчәге турында сөйләшәбез. Бу гаҗәбрәк тә тоелырга мөмкин, ә асылда көчле мотивация бирә. Нәтиҗәдә, без чыгабыз да тибәбез. Бу – футбол».

Сабина Гадршина, сакчы:

«Футбол белән мин өченче ел шөгыльләнәм инде. Бу өч ел эчендә ул минем өчен тагын да мөһимрәккә әйләнде. Ул – минем тормышымның бер өлеше, аннан башка мин инде мин булмаячакмын. Күнегүләрсез яшәвемне бөтенләй күз алдыма китерә алмыйм.
Безнең өчен боларның һәммәсенең – күнегүләрнең, уеннарның, ярышларның, керткән голлардан, команданың җиңүеннән алынган шатлыкларның никадәр әһәмиятле булуын күпләр аңламый. Сине тренер мактаганда, көннән-көн яхшыра баруыңны үзең дә аңлыйсың. Берничә көндәшеңне узып, гол керткәндә дә, менә дигән паслар тапшырганда да, һөҗүмчеләрдән тупларны әләктереп алганда да... Футболны яратыгыз һәм аның белән яшәгез!»

Анастасия Смирнова, ярымсакчы:

«Киләчәктә мин үз тормышымны спорт белән бәйләргә телим, шуңа күрә ул минем өчен бик мөһим. Ә футбол минем өчен – тагын да зуррак төшенчә. Бу – азарт, көч, бу – тормыш. Мин бер көн дә күнегүләрсез яшәвемне күз алдыма китерә алмыйм... Футболны яратам. Ул минем тормышымның мөһим бер өлеше, аннан башка мин – мин түгел. Уен гына түгел, тормыш бу!» Т



ЛЕГЕНДАЛАР ҺӘМ ӨМЕТЛӘР ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

Футбол буенча дөнья чемпионаты алдыннан «Татарстан»ның спорт редакциясе шактый катлаулы, әмма гаять патриотларча сорауга җавап эзләде: илнең футбол буенча җыелма командасы, әгәр аңарга чыгышы буенча Татарстаннан гына булган спортчыларны тупласалар, нинди булыр иде икән?

– Шактый тыйнак булыр иде, – дип җавап бирәчәк мәсьәләдән хәбәрдар булган, әмма пессимистик караштa торучы җанатар.

– Лаеклы, гаярь, дошманны өркетерлек һәм конкуренциягә сәләтле, – диячәкбез, ныклы дәлилләр китерергә тырышып.– Әлбәттә, бер шарт белән: моның өчен символик җыелма командага Татарстанда туып-үскән футболчыларның иң-иң шәпләрен генә тупларга кирәк булачак. Һәм... хәзергеләрен генә дә түгел, әле футболкаларында СССР тамгасын йөртеп, илнең намусын яклаган элгәрләрен дә җәлеп итеп...

Шулай итеп, таныш булыгыз: «Татарстан» журналының Татарстанча версиясе, ягъни соңгы 50 ел эчендәге иң шәп җыелма команда, әлбәттә, символик.
Укыгыз, искә алыгыз, горурланыгыз. Һәм, билгеле инде, Россия җыелма командасы өчен җан атыгыз!



Руслан Нигъмәтуллин, капкачы
1974 елның 7 октябрендә Казанда туа.

2001 елда Россиянең иң яхшы футболчысы буларак таныла. Ике мәртәбә Россиянең иң яхшы капкачысы буларак таныла (2000, 2001 елларда), 2002 елда илебезнең җыелмасы составында футбол буенча дөнья чемпионатында катнаша. Россия җыелма командасының 24 матчында уйный. Казанның «Электрон» командасында тәрбияләнә. Һөнәри карьерасын Яр Чаллының «КАМАЗ»ында башлый. Россиянең «Спартак», «Локомотив», ЦСКА, «Терек», СКА (Ростов-на-Дону), Италиянең «Верона» һәм «Салернитана», Израильнең «Маккаби Ахи» клубларында уйный. Өч мәртәбә Россия чемпионы (1996, 1997, 2004 еллар), ике тапкыр Россия Кубогына ия булган футболчы (2000, 2001 еллар).

Эльмир Нәбиуллин, сакчы
1995 елның 8 мартында Казанда туа.

Татарстанның иң перспективалы футболчыларыннан берсе санала. Аңа әле, билгеле, җанатарлары белән тренерларының олы өметләрен аклар өчен шактый күп көч куярга кирәк булачак. Тәүге тапкыр 2014 елда Казанның «Рубин» командасы өчен «Анжи»га каршы матчта катнаша. Дүрт елдан соң, «Рубин»нан Санкт-Петербургның «Зенит»ына күчә, соңгысы белән дүрт еллык контрактка кул куя. Россия җыелма командасында 2015 елның 31 мартында тәүге кат катнаша. Казахстан җыелма командасы белән иптәшләрчә очрашуда алмашка чыга.

Евгений Варламов, сакчы
1975 елның 25 июлендә Казанда туа.

«Волна» Казан футбол мәктәбендә тәрбияләнгән Евгенийның карьерасындагы иң югары нокта 90нчы елларга туры килә. Ул бу чорда Яр Чаллының «КАМАЗ»ы өчен өчен чыгыш ясый, аннан аны ЦСКАга чакыралар. Башкала армеецлары составында ул Россия Кубогын (2000 ел) яулый, илебезнең көмеш (ике мәртәбә – 1998 һәм 2002 елларда) призеры, бронза (1999 ел) призеры дәрәҗәләренә ия була. 1998 елда, иң яхшы сакчы буларак, «Стрелец» премиясен ала. 1997 елда «КАМАЗ» – «Шинник» матчында 12 минут аралыгында өч туп кертә – бу РФ чемпионатларындагы иң яхшы күрсәткеч. Россия җыелмасы өчен 10 матчта катнаша, бер туп кертә.

Вячеслав Булавин, сакчы
1946 елның 18 апрелендә Казанда туа.

Һөнәри карьерасын Бөгелмәдәге «Нефтяник»та башлый, аннары Казандагы «Рубин» составына күчә. 1967–1977 елларда Ленинградның «Зенит»ы өчен Югары лигада чыгыш ясый. СССР чемпионатларында 226 матчта уйный, ун тапкыр туп кертә. 1972 елда СССРның Олимпия җыелмасы өчен ике матчта катнаша.

Владислав Игнатьев, ярымсакчы
1987 елның 20 гыйнварында Брежнев (хәзер – Яр Чаллы) шәһәрендә туа.

Быел ул «Локомотив» составында илебез чемпионатында «алтын» яулады, бер ел элек Россия Кубогына ия булган иде. Профессионал буларак карьерасын 2004 елда Түбән Каманың «Нефтехимик» командасында башлый. Самараның «Крылья Советов»ы, «Локомотив», «Кубань», «Краснодар» кебек клублар составында уйный. «Локомотив»ка 2016 елда кайта. Россия җыелмасындагы дебюты 2015 елның 14 ноябрендә Португалия җыелма командасына каршы иптәшләр матчында була. Илебезнең җыелмасы данын Владислав өч матчта яклый. Май аенда Россиянең футбол буенча баш тренеры Станислав Черчесов Игнатьевны өебездәге дөнья чемпионатындагы киңәйтелгән кандидатлар исемлегенә кертте.

Далер Кузяев, ярымсакчы
1993 елның 15 гыйнварында Яр Чаллы шәһәрендә туа.

Санкт-Петербургның «Зенит» командасы уенчысы Россиянең баш тренеры Станислав Черчесов тарафыннан футбол буенча өйдәге чемпионаттагы җыелма составына кертелде. Кузяевның рәсми дебюты 2017 елның 7 октябрендә була – ул Көньяк Корея белән иптәшләрчә очрашуда катнаша. Җыелма команда составында барлыгы дүрт матчта чыгыш ясый. Профессионал уенчы буларак карьерасын биш ел элек – Түбән Каманың «Нефтехимик» беренчелегенең тулы булмаган сезонында башлый. 2017 елның җәендә Кузяев Санкт-Петербургның «Зенит»ы белән өч еллык контрактка кул куя. Россия чемпионаты матчының беренчесендә үк гол кертә. Әлеге ел аның җитлеккән чор карьерасында – беренче.

Галимҗан Хөсәенов, һөҗүмче
1937 елның 27 июлендә ТАССРның Октябрь районы Яңа Иглай авылында туа.

Мәскәү «Спартак» клубының һәм СССР җыелма командасының легендар футболчысы, 60нчы еллар җанатарларының яраткан каһарманы. Яхшы техникага ия кечкенә генә буйлы Гиля (дуслары аны шулай атап йөртә) команданың чын мәгънәсендә лидеры, капитаны була. Ул очрашуларның нәтиҗәсен хәл итәрдәй голлары белән атаклы шәхес. Галимҗан Хөсәенов СССРда сезонның иң яхшы футболчылары исемлегендә 33 исемнән сигез мәртәбә 1нче булып танылa. «Спартак» белән бергә ул ике тапкыр СССР чемпионатында җиңүгә ирешә, өч мәртәбә СССР Кубогын ала, беренчелектә ике кат – көмеш, ике кат бронза призер була. 1963 елдагы илебез Кубогы финалында Хөсәенов почмактан туры бәреп гол кертү мөмкинлегенә ирешә. СССР җыелмасы өчен 33 матчта катнаша, дүрт гол кертә, шуларның берсе – 1964 елдагы Европа чемпионаты вакытында испанлылар белән уенда. Илебез җыелмасы составында 1966 елдагы дөнья чемпионатында дүртенче урын ала. СССР чемпионаты һәм җыелма команда матчларында барлыгы 145 туп кертә. Григорий Федоров клубына кабул ителә. 2010 елда Мәскәүдә вафат була.



Николай Осянин, һөҗүмче
1941 елның 12 декабрендә ТАССРның Соболевское авылында туа.

Казан «Искра»сында тәрбияләнгән егетнең таланты чын мәгънәсендә Мәскәүнең «Спартак» клубында ачыла. «Аклы-кызыллы»лар составында Николай Осянин 1966 елдан алып 1976 елга кадәр чыгыш ясый (Алма-атаның «Кайрате»сы составында уздырган ике сезонын исәпкә алмаганда – ред.иск.). «Спартак» белән бергә Осянин 1969 елда илебез чемпионы була, ил Кубогын яулый, ике тапкыр көмеш призер дәрәҗәсенә лаек дип табыла. «Спартак» өчен 248 матчта катнаша, 50 туп кертә. СССР чемпионатының Югары лигасында барлыгы 402 матчта уйный, 70 туп кертә. СССР җыелма командасының өч матчында катнаша, бер гол кертә. СССРның Олимпия җыелма командасы өчен биш матчта уйный.

Виктор Колотов, ярымсакчы
1949 елның 3 июлендә Казан янындагы Юдино бистәсендә туа.

70нче елларда Европадагы иң яхшы футболчыларның берсе, аны Йохан Круифф, Герд Мюллерлар һәм җанатарларның башка кумирлары белән бер рәткә куялар. Викторның футбол карьерасындагы иң күренекле чоры 1970нче еллар башына туры килә. Шулчакта аны, Икенче лига уенчысын, кинәт кенә илебезнең җыелма командасы составына чакыралар. Озак та үтми, ул Казан «Рубин»ыннан Киевтагы «Динамо»га күчә. Киев өчен чыгыш ясап, Колотов УЕФА Суперкубогына (1975 ел), УЕФА Кубоклары ияләре Кубогына (1975 ел) ия була, алты мәртәбә илебез чемпионы, ике тапкыр СССР Кубогы иясе буларак таныла. СССР җыелма командасы составында Европа чемпионатындагы көмеш призер (1972 ел) булып таныла, ике мәртәбә Олимпия уеннарының бронза призеры (1972, 1976 еллар) дәрәҗәсенә ирешә. Виктор Колотов – СССР җыелмасының Европа чемпионатлары матчындагы иң шәп бомбардир (җиде туп). Җыелма һәм клуб уеннарында барлыгы 103 туп кертә. СССРда сезонның иң яхшы футболчылары исемлегендә 33 исемнән җиде мәртәбә 1нче булып таныла. 2000 елның 3 гыйнварында Киев шәһәрендә вафат була.

Геннадий Еврюжихин, һөҗүмче
1944 елда Казанда туа.

СССР җыелмасының 60-70нче еллардагы уенчысы, 1972 елдагы Олимпия уеннарының бронза призеры, УЕФА Кубогына ияләре Кубогы финалисты (1972 ел). Еврюжихин кебекләр турында, гадәттә, «аның таланты Ходайдан» диләр. Футболны ул Казан ишегалларында уйнап үзләштерә, бернинди спорт мәктәпләренә дә йөрми. Әмма бу аңарга, Ленинградтагы югары уку йортына укырга кергәч, студентлар җыелмасына эләгергә комачауламый. Студентлар командасыннан ул турыдан-туры «Динамо»га (Ленинград) кабул ителә. 1966 елда Еврюжихин – инде башкаланың «Динамо» командасы уенчысы. Совет футболының Югары лигасында голларга исәпне беренче матчта ук ача, ярты елдан соң СССР җыелма командасына чакырып алына. «Динамо» өчен 1976 елга кадәр уйный. СССР чемпионы, ике мәртәбә көмеш призер, ике тапкыр СССР Кубогы иясе. «Аклы-зәңгәрлеләр» өчен 283 матчта 54 туп кертә. СССР җыелма командасы өчен 37 матчта катнаша, алты гол кертә. 1998 елның 15 мартында Мәскәүдә вафат була.

Александр Бохаров, һөҗүмче
1985 елның 12 мартында Брежнев шәһәрендә туа.

Футбол белән әле үзенең туган шәһәрендә үк шөгыльләнә башлый. 2005 елдан алып 2010 елга кадәр Казан «Рубин»ында чыгыш ясый. Татарстан клубындагы алты сезон эчендә 103 матчта уйный, 37 тапкыр туп кертә. 2010 елдан алып 2014 елга кадәр «Зенит»та уйный, соңгы дүрт сезонда «Ростов» өчен чыгыш ясый. «Рубин» белән «Зенит» составында дүрт мәртәбә илебез чемпионы дәрәҗәсенә ирешә, ике тапкыр Суперкубокка ия була. Россия Премьер-лигасы командалары өчен 284 матчта 74 мәртәбә гол кертә. Илебезнең милли җыелма командасы өчен тугыз матчта катнаша, бер туп кертә.

Әскәр Сабиров **әзерләде**

«КАЗАН ҺӘРВАКЫТ МИНЕМ ЙОРТЫМ БУЛАЧАК!»

Темпераментлы бу төрек егете «Рубин» җанатарлары күңелен бик тиз арада яулады. Гәрчә Гёкдениз Карадениз биргән интервьюлар бармак белән генә санарлык булса да, беркемгә дә әллә ни ачылып китмәсә дә, аны шунда ук үз иттеләр. Шулай да «Татарстан» журналисты белән әңгәмә корырга ризалашты атаклы футболчы. Сәбәбе җитди: хушлашу матчы гына түгел, ә футболчы лаек булган «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены да.

Автор:
Ольга Туманская

Караденизнең «Рубин» составындагы хушлашу матчына 25 меңнән артык тамашачы килде, шулар арасында республиканың ике президенты да – беренчесе һәм хәзергесе. Менә шундый гомумхалык мәхәббәте! «Мин сезне бик яратам! «Рубин» җанатарлары, мин сезне бик яратам! Казан һәрвакыт минем йортым булачак», – дип, татарча һәм русча (мөгаен, беренче тапкыр тәрҗемәчесездер) җавап бирде хисләре ташыган Карадениз трибуналарның үзен сәламләп гүләвенә.

61 НЧЕ САНЛЫ ЛЕГЕНДА

– Үземне белә башлаганнан бирле гел туп уйныйм, – дип сөйли ул үзе турында. – Бу минем яраткан уенчыгым иде – башкаларына әйләнеп тә карамадым. Һәрвакыт футболчы буласым килде. Хыялым чынга ашты – мин бәхетлемен.

Бүген төрекләрнең «Трабзонспор» аренасының «Хөсәен Авни Акер» стадионына керү юлларының берсе Карадениз хөрмәтенә аталган.

– Бу миңа хөрмәт билгеседер, дип уйлыйм, – ди ул. – Мин «Трабзонспор» тарихында файдалы килешү сәбәпчесе булдым. Уенчы буларак мине сату клубка күп акча китерде. Һәм мин моңа шат, чөнки үземне «Трабзонспор» шәкерте дип саныйм, аны да яратам.

Аның футбол карьерасында әлеге ике клуб кына бар. Һәркайсына унар ел гомер бирелгән. Мондый кеше көнләшерлек тугрылык – ул үзенә күрә бер стратегияме, әллә характер үзенчәлегеме?

– Тегесе дә, монысы да. Әмма мин даимилекне, тотрыклылыкны яратам – бусы дөрес, – дип елмая Гёкдениз. – Моннан ун ел элек «Рубинга» килгәч, миңа бирелгән әйберләр арасында артсыз резин туфлиләр – сланцы да бар иде. Алар хәзергә кадәр минем белән! Үзләрен беркемгә дә бирмәячәкмен, чөнки мин алар белән чемпион булдым!

Бүген «Казан Арена» өстендә, әләм кебек, аның 61 нче санлы футболкасы җилферди. Әлеге сан Караденизгә гомерлеккә бирелгән. «Рубинның» бөтен мөһим җиңүләре, шул исәптән Европаның топ-клубларын оту да аның исеме белән бәйле.

«РУБИН» ҖИҢҮЛӘРЕНЕҢ АМБИЦИЯЛӘРЕ

«Мин чемпион булыр өчен килдем», – дигән кыю игълан белән кушыла Карадениз рубинлылар сафына. Әмма мондый ышаныч каян килгән соң?

– «Трабзонспор» берничә тапкыр Төркия кубогын яулады, шунлыктан җиңү минем өчен күнегелгән халәт иде. Иң югары урыннар һәм бүләкләр өчен көрәшү зарурлыгы турындагы фикер дә канга сеңгән. Әмма «Рубинга» килгәндә, баштарак команда минем сүзләргә әллә ни ышанмады бугай. Ә инде ота башлагач, барысы да үзгәрде. Мин командага 2008 елда килдем, һәм шул елны ук без Россия чемпионы булдык – бу минем өчен бик мөһим иде.

Әлеге җиңү Казан клубы тарихында беренчесе. Вакыйгалар бик тиз һәм көтелмәгәнчә алышына. Башта – бер-бер артлы җиде җиңү! Бу Премьер-лиганың яңа рекорды була! «Зенит» та, «Динамо», «Локомотив» та «Рубин»нан артта кала. Әмма алда аларны Мәскәү «Спартагы»ннан җиңелү көтә, аннары тагын җиде уен рәттән отылалар...

– Ул чакта без бик озак вакыт буе җиңә алмадык, – ди Карадениз. – Әмма безнең көндәшләребез дә җиңә алмады бит! Хәтерлим әле, ул чакта мин үземә: «Димәк, без үзебез генә түгел, Аллаһы Тәгалә дә безнең чемпион булуыбызны тели», – дигән идем.

Төрек ярымсакчысы голлары җиңү яулауга сизелерлек өлеш кертә. Караденизне бик кыйбатлы, әмма команда өчен гаять мөһим уенчы дип атыйлар. Шуннан соңгы ун ел – моңа дәлил. 2009 елда «Рубин» кабат ил чемпионы була, аннары Россия кубогын яулый. Ике тапкыр Суперкубокны ота. Хәзер инде Казан футболы йолдызы булган Карадениз барлык казанышларга да үз өлешен кертә. Һәм команданың искиткеч җиңүләре уңышсызлык чоры белән алышынгач та, җанатарлары аның уенына сокланып туймый. «Рубин» уенчысы сыйфатындагы соңгы

Фото «Рубин» ФКның рәсми сайтыннан (www.rubin-kazan.ru) алынды

сезон да Караденизгә шәхсән үзенең җиңүе сыйфатында трофей китерә – җиденче турда «Анжи» капкасына керткән тубын команда җанатарлары иң яхшы гол дип таба.

КАЗАН – МӘҢГЕГӘ

Сүз уңаеннан, ун ел элек «Трабзонспор»дан Карадениזне Испания, Англия клублары да сатып алырга теләк белдергән була. Әмма көндәшләр көрәшендә Казан клубы җиңеп чыга. Вакыйгаларның мондый борылышы Карадениз өчен уңайлы була. Казан турында мәгълүмат туплагач, ул – чын мөселман – үзенә бу шәһәрдә яшәве рәхәт булачак, дигән нәтиҗәгә килә. Һәм ялгышмый – шәһәрне дә, «Рубин»ны да үз итә. Хәтта аларга мәхәббәтен тәненә «ФК Рубин Казан» татуировкасы итеп төшерә.

– Баштарак миңа биредә кыен булды, – дип дөресен әйтә ул. – Мин шәһәрне дә, аның кешеләрен дә белми идем. Гаиләм Истанбулда калды. Һәм мин хәзергә кадәр салкынга чыдарга өйрәнмәдем! Әмма, монда кичергәннәремне бергә тупласам, ихластан әйтә алам: Казанда мин бәхетле булдым. Биредә минем икенче улым туды, өлкән улым белән кызым халыкара мәктәпкә укырга керде – без хәзер кабат барыбыз да бергә. Мин кешеләрнең миңа мөнәсәбәтен күрәм: чын күңелдән яратканнарын, хөрмәт иткәннәрен. Һәм мин дә аларга шундый ук хисләр белән җавап бирәм. «Рубин» һәм Казан минем тормышымда зур урын били.

Казанлыларга исә истәлек булып Караденизнең җиңүләре һәм керткән туплары турындагы хатирәләр генә түгел, ә аның Калинино авылында төзеткән мәчете дә ядкарь булып калачак. Ул якынча ярты елдан төзелеп бетәргә тиеш.

– Төркиядә мәчетләр бик күп, монда – азрак. Мин төзеткән җирдә якын тирәдә бер генә мәчет тә юк. Шунлыктан бу урынны сайладым да. Төзелешкә килгәндә, аның өчен күп сәбәп таләп ителми. Мин мөселманмын, һәм моны Аллаһның ризалыгы өчен эшлим. Мәчет хакында туктаусыз сорап йөдәтүләре миңа бер дә ошамый. Ниндидер мактану кебек килеп чыга, рәхәтлек хисе югала...

Аның иманының тагын бер ягы да бар әле – дөрес яшәү: «Мин беркайчан да икейөзле булып кыланып маташмадым, һәрвакыт нәрсә күрүемне һәм ни уйлавымны ачыктан-ачык әйтәм». Ихтимал, аның намуслылыгы һәм туры сүзлелеге бөтен кешегә дә ошап бетмидер.

– Минем фикерем мондый: без бүген чын команда булып җитешә алмадык әле, – дип кабатлый Гёкдениз. – Моның өчен яхшы уенчыларны гына туплау аз. «Команда» төшенчәсе күпкә киңрәк – бу җанатарлар да, иганәчеләр дә, шәһәр һәм республика хакимиятләре дә. Барысы да «Рубин» тирәсендә тупланса гына, без чын командага әйләнәчәкбез! Бүген клубның проблемалары бар, ә тулаем берләшү әлегә юк. Әмма зур футболда барысы да бер-берсенә тыгыз бәйләнгән. Тренер яхшы состав тупларга, алар белән көне-төне шөгыльләнергә мөмкин, әмма, мәсәлән, уенчылар вакытында хезмәт хакы алмый икән, алар никадәр яхшы уйнар икән? Беләсезме, команда ул – зур кораб. Кечкенә генә тишек хасил булса да, батарга мөмкин.

– Туры сүзле булуыгыз сезгә комачауламыймы?

– Әлбәттә, моның аркасында кыенлыклар да булгалады. Әмма мин Аллаһы Тәгалә каршында ялганлый алмыйм, мин үзем күргән проблемаларны әйтергә тиеш. Хакыйкать башта ошап бетми. Әмма беразвакыт үткәч, кешеләр минем хаклы булуымны күрә. Икенче яктан караганда, һәркемнең үз дәреслеге – мин моның белән бәхәсләшмим. Дәлилләрен тыңлыйм, ялгышканымны күрсәм, моны һичшиксез таныйм. Үземә тәнкыйть сүзләрен дә шулай кабул итәм. Үзем турында беркайчан да: «Мин һәрвакыт һәрнәрсәне дөрес эшлим», – димәячәкмен.

ДИНАСТИЯГӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

Караденизнең «Рубинда» узган гомерендә төрле чаклар була. Әйтик, испанлы Хави Грасия җитәкчелегендәге сезонда, аларның икесенә генә мәгълүм сәбәпләр аркасында. Гёкденизне кырга бик сирәк чыгаралар. Ул чакта ул футболсыз интегә.

– Минем ул чакта авыр чорым булды, дип әйтәсем килми, – ди ул. – Футбол карьерасында мондый зигзаглар – нормаль күренеш. Әмма, ул сезон исемә төшкән саен, аның минем өчен гаделсез булуы әрнетә. Бу мине әрнетә, борчуга сала иде. Нигә алай булдымы? Монысын инде тренердан сорарга кирәк. Үзем исә бары шуны гына әйтә алам: мине беркем дә тренировкаларда аз шөгыльләнүдә, тырышмауда гаепли алмас.

Дөрестән дә, Карадениз кырда һәрчак гаҗәпләндерә – футболны аның кебек яраткан кеше «Рубинда», мөгаен, бүтән юктыр да ул.

– Мин кырда гына шундый дуамал, өйдә исә бик тыныч! – дип көлә ул. – Мөгаен, мондый уен стиле минем туган җиремнән киләдер – анда бик темпераментлы халык яши. Минем әнием кебек! Ул берьюлы дүрт төрле ризык әзерли ала – мин аның артыннан өлгерә алмыйм. Хатыным да шундый ук.

Караденизнең футбол гаиләсендә Корбан Бердыев аерым урынны били. «Минем карьерамда ул – иң яхшы тренер», – дип билгели аның ролен Гёкдениз.

– Әгәр теләсә, футболчы Бекиечтән күп нәрсәгә өйрәнә ала. Төрек клубында мин гел һөҗүм ягына гына уйный идем. Бердыев исә миңа һөҗүм генә түгел, сакланунуң да шулкадәр үк мөһим булуын күрсәтте. Мөһим момент – ул детальләрне бик ярата. Техник, тактик нюансларны һәрвакыт тикшерә. Мәсәлән, мин Төркиядәге карьерамда ауттан гол керткәнебезне хәтерләмим. Ә Бекиеч белән без моны эшләдек. Башта алымны тренировкада шомарттык, аннары, кырга чыккач, махсус шундый момент тудырдык һәм ауттан туп керттек. Мондый хәлләр күп булды. Моннан тыш, Бердыевта уенчыларны ачу таланты бар. Ә бит һәр тренер да талантны күрә белми! Шундый очраклар булды: Бекиечкә эләккәч, футболчының карьерасы шунда ук үргә менә, ә инде икенче клуб сатып алгач, анда аның кирәге калмый...

Үзенең тренерлык карьерасы турында хыялларын да Гёкдениз Бердыев белән бәйли: «Аның шәкерте буласым, аның яхшы ярдәмчесенә әйләнәсем килә. Клуб үз мөмкинлекләреннән чыгып хәл итәргә тиеш – калдыра алалармы мине, әллә юкмы».

Аның беренче шәкертләре – уллары. Кечесенә – дүрт, олысына – ун яшь. «Без синнән яхшырак уйныйбыз!» – дип үртиләр алар әтиләрен. Ул көлә генә. Малайлар футболны ярата, тик бу уен аларның язмышына әйләнерме?

– Үзләре сайласын, – ди Карадениз. – Ә менә мин үз тормышымны футболдан башка күз алдына да китерә алмыйм. ▪

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

Редакция кухнясы

КУНАКЛАР ӨЧЕН ДЕЛИКАТЕС: **ИТТӘН ТОРТ**

Фото: Луиза Янсуар

Казанда футбол буенча дөнья чемпионаты узган көннәрдә без дә спортны, мәдәниятне, коллекционерлыкны, сәяхәтләрне һәм телне йотардай тәмле, затлы деликатеслар әзерләү осталыгын берләштерергә булдык. «Татарстан» журналына бу эштә ярдәмгә Югары Осланда урнашкан «Республиканың стендка ату буенча махсуслашкан балалар һәм яшүсмерләр Олимпия резервы спорт мәктәбе» администраторы Альмира Гайнуллина килде.

Автор:
Луиза Янсуар

«МАМА ЧОЛИ»

Аның турында ишетеп белә идем инде: «И, син Альмираның чәйнекләр коллекциясен күрсәң!» – дигән саен, бу ханым белән танышу теләге көчәя генә барды. Һәм менә, ниһаять, насыйп булды. Залесный бистәсендәге йортларында Альмира һәм аның тормыш иптәше Рөстәм Гайнуллиннар әле һаман да ремонт ясауларын дәвам итә. Без килгәндә дә, аш бүлмәсендә кухня гарнитурын җыеп бетерү процессы тәмамланып килә иде. Әмма Альмира ханым – гаҗәеп кунакчыл һәм киң күңелле зат буларак – бу вак-төякләргә игътибар итмәскә кушты да эшкә керешге. Безнең редакция кухнясын бу сан да бизәячәк ризык – бавырдан әзерләнгән катлы торт.

– Теләсә кайсы илдән килгән кунакны сыйлардай ризык, – дип, куәтләдем мин аны.

– Милли ризыклар да әзерләргә яратам, – дип елмайды хуҗабикә. – Ә менә бу рецепт гаиләбез өчен дә, дусларыбыз өчен дә аерым бер кадер-хөрмәткә ия. Аны өйдәгеләр хушлансын дип кенә түгел, ә кунакларга да, хәтта балаларымның эштәге коллегалары өчен дә еш хәстәрлим. Кызым Әлинәнең хезмәттәшләре, туган көн булсынмы, башка берәр бәйрәмме, бернинди дә кибет ризыгы алып килмә, әниең әзерләгән теге бавыр тортын алып кил, яме, дип сорыйлар. Ә миңа нәрсә, кыенмыни, барысына да җитәрлек итеп хәстәрләп җибәрәм.

– Шулай җиңел әзерләнәме? – дип кызыксынам.

– Бер авырлыгы да юк, – ди Альмира ханым. Ул инде безнең килешкә бавырны иттарткычтан чыгарып та куйган иде. Тагын бер порциясе күтеп тора. Анысы – кичке табынга, өйдәгеләр барысы бергә җыелгач, сыйланырга. Алар бу өйдә ишле гаилә булып, өч буын вәкиле бергә яшиләр. Кызлары Әлинә белән аның тормыш иптәше Евгений, аларның уллары, ягъни Альмира ханым белән Рөстәм әфәнденең оныклары Данил. Кече уллары Рәсих белән аның хатыны Диана. Ә менә уртанчы уллары Рәзил контракт буенча хәрби хезмәттә икән. Тиздән кайтып җитәргә тиеш, диделәр.

Баксаң, бик җылы, гармонияле атмосфера хөкем сөргән бу йортта яшәүче өч буын вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләр, Мексика сериалларындагыча, шактый үзенчәлекле дә икән. Әлинә – олы кызлары – Альмира ханымның беренче гаиләсендә тапкан баласы. Альмира ханым «уртанчы улым» дип атап йөрткән Рәзил – ире Рөстәмнең вакытыннан алда вафат булган беренче хатынынннан малае. Ә менә төпчекләре – Рәсих – инде алар икесе кушылгач, дөньяга килгән уллары.

– Бу җәһәттән безнең гаиләдә бер кызык сүз дә йөри, – дип искә ала Альмира ханым. – Рәсих тугач, шулай бервакыт Рөстәм мине шыпырт кына дәшеп алды: «Альмира, – ди, – кил әле, кара: синеке белән

Хәер, Месси, кыяфәтенә караганда, үз исеменнән дә, тормышыннан да бик канәгать тоелды безгә. Ул кич буе тортны хәстәрләү процессын җентекләп контрольдә тотты.

Ул арада Альмира ханым, икенче таба астына ут элеп җибәрде дә, бавырга сөт агызып, он, тоз, борыч кушып, массаны яхшылап болгатып, бавыр «коймак»ларын кыздырырга да кереште.

– Ничә «коймак» кирәк шулай да? – дип төпченәм.

– Ашаганда авызга сыярлык булсын инде, – ди хуҗабикәбез. – Мин, гадәттә, 5-6 катлы итеп ясыйм... Бер ясаганда берничәне әмәлләп ташлыйм. Тиз дә, җиңел дә, тәмле дә бит.

«Коймаклар» кызган арада Альмира ханым белән сәяхәтләр темасына күчтек.

– Кешене үзең яратып әзерләгән ризык, күчтәнәч белән сөендерүдән дә рәхәт нәрсә юк дөньяда.

минеке безнекен кыерсыта». Бала-чаганың үзләренә күрә шаяруы иде инде ул, уеннары. Әмма Рөстәмнең сүзләре шулкадәр кызык яңгырады – башта үзебез рәхәтләнеп көлдек, аннары туган-тумачалар, дус-ишләр дә, бу хәлне искә алып, истәлек итеп сөйли торган булдылар. Үз балаларым миңа «әни» диеп дәшсә, Рәзилебез һәрчак, аерып куеп, «әнием» дип эндәшә. Әле ике яктан да үз әти-әниләребез исәнсау! Шуңа без бик бәхетле балалар, дип саныйм.

Кечкенә уллары Рәсих хоккей белән мавыга башлагач, Альмира ханым аны шөгыльләнергә йөртә башлый. Малайга тренерлары зур өметләр баглый, әнисе белән улы һәртөрле ярышлардан, бәйгеләрдән кайтып керми. «Рәсихне генә түгел, ә башкаларның балаларын да йөртә идем, күз-колак булып, – дип сөйли Альмира ханым. – Барысының да әти-әниләренең вакыты, мөмкинлекләре юк бит. Кайда гына булмадык! Мине әти-әниләр «мама Чоли» дип атап йөртәләр иде. Ул «Богатые тоже плачут сериал» модада чаклар...

МЕССИ – ӨЙЛӘРЕНДӘ

Шулай истәлекләргә бирелә, сөйләшә-сөйләшә, торт өчен кирәк булган 6 баш суганны турады, газны кабызып, табаны чама белән майлап, аны кыздырырга куйды. «Суган – бик мөһим ингредиент, аны җәлләмәгез: нәкъ менә ул бавырны татлы, сусыл итә, алтынсу төскә кергәнче, сүрән утта яхшылап кыздырырга кирәк», – ди Альмира ханым. Үзе бу тортның рецептын каян алганын хәтерләми дә инде хәзер, гел пешергән кебек, ди. Ә балачагында әнисе бөтен төрле ризыкны бик оста хәстәрли торган булган икән. Аеруча таба ашларын искә алып сөйләде Альмира ханым.

– Аның таба ашларын, «пирожкилар»ын бер мин генә түгел, ә дусишләрем дә гел сагынып сөйли. Бездән бит кеше өзелми торган иде. Авылда үз йортыбыз белән торганда да, аннары, шәһәргә күчкәч тә. Авылда кунакка дип кайталар иде, монда исә без шәһәргә йомыш белән килгән һәркем өчен кунып китә, сугылып чыга торган бер пост булдык. Әни берәүне дә сыйламыйча, күчтәнәч тәямичә җибәрмәде. Аллага шөкер, җитеш яшәдек, ә үзеңә җиткәнне ничек инде кеше белән бүлешмисең...

Уллары Рәсих хәзерге көндә Татарстан Республикасының Хоккей федерациясендә тренер булып эшли. Бу гаиләдә спортка зур ихтирам яши. Без барып кергәндә, аш бүлмәсе диварына урнашкан телевизордан гөрләп футбол матчы бара иде. «Мин үзебезнекеләр һәм Колумбия өчен җан атам», – ди Альмира ханым. Колумбия уенчыларын ул тормышта да белә, шуңа аларга мөнәсәбәте – әниләрчә. Безнең суганыбыз кызып өлгергән арада кухняга дәрәҗәсен белеп, йомшак кына атлап Месси килеп керде. Газ плитәсе янындагы урындыкка менеп кунаклады да игътибар белән хуҗабикәнең хәрәкәтләрен күзәтергә кереште.

– Белмим, нишләп берәр хоккейчы иseme белән атамагандыр үзен Рәсих, – дип аңлатырга кереште Альмира апа. – Җитмәсә, әле ул безнең кыз песи дә...

«БАРСЕЛОНА УРТАСЫНДА УТЫРЫП ЕЛАДЫМ»

– Төркиядә дә, Мисырда да булганым бар инде, дип уйладым да, чыгып киттем Европа буенча круизга, – дип, үзе өчен аеруча истәлекле булган сәяхәте хакында тәмләп сөйли башлады ул. – Төркия аша Барселонага очтым. Лайнерга утырганчы, әле ике көнем бар иде Барселонаны карап йөрергә, шуңа исәп тотып килдем дә бит. Барселонаны гаҗәеп матур диләр, спорт белән дә бәйле, Гауди шәһәре дә бит... Килеп төштем аэропортка, таксига заказ бирәсе килмәде, алдан бронь ясап куйган кунакханә урнашкан урынга автобус белән бардым. Төштем автобустан, карыйм: кунакханәгә охшаган бернинди алагаем бина да калкып тормый. И Ходаем, дим, ялгыш килдем микәнни. Урамның бер башыннан икенче башына багажымны һәм сумкамны сөйрәп, белмим, күпме йөргәнмендер. Менә шушында гына ул, дип күрсәтәләр, юк кына бит! Телне дә белмим, кул хәрәкәтләре белән аңлашабыз. Инде караңгы төште. Эскәмиягә утырып елап та алдым. Аптырагач, туктаттым бер таксистны: зинһар өчен, илтеп куегыз мине шушы адрес буенча, дим. Ә ул урамда юл хәрәкәте бер генә яклы икән. «Мин сезне анда илтсәм, күрше урамнарны урарга туры киләчәк, акчагыз гына әрәмгә китә, ә ул монда – янәшәдә генә», – дип, ишарәләп күрсәтә бу. Баксаң, аларда отельләр, Төркия, Мисырда туристлар өчен махсус каралганча түгел, күккә ашып утырмыйлар икән. Тыйнак кына, башкалар шикелле үк күркәм

бер йортта урнашкан булып чыкты ул – ишегалды эчендә. Тапкач, сөенгәнемне белсәгез!

Барселонаны бик яраттым. Ә лайнерга утыргач, безнең сәяхәтебез Марсель, Генуя, Неаполь кебек шәһәрләрне үз эченә алды, аннары Сицилиягә кердек тә Туниска төштек. Урта диңгезнең чиксез зәңгәр киңлекләреннән күз камаша! Мин барганда су коеныргa әле иртәрәк иде, әмма матурлыкка сокланып, диңгез җилен иснәп баруның үзенә бер рәхәтлеген тоеп кайттым. Яр буйларындагы шәһәрләрне күргәндә дә, аларның үзенчәлегенә, күркәмлегенә исләрең китә. Бик матур манзаралар! Марсельдә безне шунда ук кисәтеп куйдылар: башбаштаклыклар бара, гарәпләр яшәгән районнарга берүк бара күрмәгез, диделәр. Юкса Европа шәһәрләре бик тыныч, хәвефсез, уңайлы тоелды миңа. Генуя, Неаполь буйлап сәяхәт иткәндә, Россиядән килгән туристлар белән бергә берләшеп йөрдем. Танышып, дуслашып киттек. Бик рәхәт кешеләр булып чыктылар. Алар кызыклы урыннарның картасын махсус кәгазьгә бастырып алганнар да, шулар буенча гидсыз-фәләнсез генә үзебез йөрдек. Кешеләр андый чакта бер-берсенә ярдәмләшергә әзер тора – шунысы рәхәт. Юлыма юньле кешеләр чыгарып куйсаң иде, дип, һәрчак Аллаһтан теләргә кирәк. Теләкләр бит кабул була.

Тагын бер кызыклы хәл: инде Барселонадан кайтырга чыккканда, аэропортка шактый иртә килеп утырдым. Шунда гына черем итеп алдым да рейсны көтәм. Аэропорт мыжлап тормый, иркен, буш. Duty Free кибетенә сугылырга булдым. Керсәм, карыйм: анда утыручы сатучының куен кесәсендәге ярлыкка татарча исем язылган. Әллә ничек кенә рәхәт булып китте: «Сез татармы әллә?!» – дип сорадым. «Әйе, – диде ул, елмаеп. – Үзбәкстаннан». Баксаң, алар Советлар Союзы җимерелгән елларда Испаниягә күченеп килгәннәр икән. «Акрынлап туган-тумача Барселонага күченеп бетте диярлек, мондагы тормыш шартлары, ни дисәң дә, яхшырак шул», – дигәне хәтердә. Бик җылы итеп аралашып, мин рейсымны көтеп җиткергәч, туганнарча хушлашып аерылышытык. Чит илдә үз кавемдәшеңне очратуның зур сөенеч икәнен аңладым.

ӨЙДӘГЕ МУЗЕЙ

Әзер «коймак»ларны, һәр катына майонез сылап, кыздырылган суганны ягып, тортыбызны хәстәрләп тә куйды шул арада Альмира ханым.

– Инде матур итеп бизисе генә калды, – диде.

Әзер катлы тортның ян-якларын вак итеп туралган укроп белән бизәп чыкты, өстенә тигез итеп урталай киселгән черри томатларын тезде. Шуннан соң, аны ярты сәгатькә суыткычка алып куйды. Ә ул арада безне икенче каттагы музеена чакырды.

Килеп кердем дә тел генә шартлаттым. Һәр чәйнек, чынаяк, касә, поднос, самовар һ.б. коллекция предметлары кадерләп үз урынына урнаштырылган. Пөхтәлек, чисталык, зәвык хөкем сөрә бу бүлмәдә. Һәр кечкенә генә подвеска рәвешендә эшләнгән чәйнекнең дә үз кадере, тарихы барлыгы сизелеп тора.

– Аларның да, безнең кебек үк, үз язмышлары инде. Кайчак әллә кайлардан табып аласың – кадерсез булып, тузан җыеп, кыерсытылып яталар, бәгырьләрем. Өйгә алып кайткач, бала кадерләгәндәй буласың... Әнә, Европаның затлы император йортларында кулланылган раритет сервизлар, 63 сантиметрга кадәр җиткән подностар, Кузнецовның атаклы фарфор йорты эшләп чыгарган тәлинкәләр, чынаяклар, Гжель коллекцияләре, совет чорында империя чорыннан калган ысулларны саклап, фабрикаларның югары стандартына җавап биреп эшләнгән сирәк савытлар... Һәрберсенең тарихын, каян табылганын, кемнән алынганын, бәясен-хакын биш бармагыдай хәтерли Альмира ханым.

– Монда ничә предмет бар? – дип сорыйм.

– Ой, мин инде хәзер санамый да башладым, – дип елмая ул. – Бер утырып исемлеген төзисе булыр...

– Балаларыгыз, ирегез ничек карый бу мавыгуга? – дим.

– Рөстәм баштарак көлә генә иде: «Тиле савыт җыя», – диеп. Ә аннан, минем Интернеттагы сирәк савыт-саба – антиквариат сайтла-

рына кереп чумуымны абайлагач, бу мәхәббәтнең чын булуын аңлады. Башта мин чәйнекләр генә җыя идем, әллә ни зур максат та куймыйча: җаныма ошаган, үзенчәлекле чәйнекләрне сатып алам, шул гына. Дуслар да, мавыгуымны белеп алып, бүләк итә башладылар. Ә менә тора-бара шушындый сирәк, затлы предметларга кызыксынуым көчәйде. Махсус кешеләр белән таныштым: алар предметларның датасын, чыгышын ачыкларга булыша. Кайбер затлы әйберләргә, көтмәгәндә-уйламаганда, «хәерче» базарында юлыгасың. Бер бабай сатып утырган тәлинкәгә күзем төште. Күренеп тора: затлы әйбер, тарихы бар. Антикварлар сайтында меңнәр тора... Алар бит билгеле бер серия белән чыккан була – гадәттә, коллекционерлар тулы серияне туплый, шулай итеп, «коллекцияне яба». Үз алдыма андый шарт куймыйм: мин – стихияле коллекционер. Әмма сайтларда утырып, бик күп нәрсәләрне өйрәндем: элеккеге чорларда эшләнгән һәр нәрсәдә ярату, кадер тойгысы бар. Бизәкләрдә дә чагыла ул, сыйфатта да, хәтта һәр савыт-саба әзерләү йортының вензелендә үк. Британия сервизлары бик нечкә, нәзберек, кытайныкылар да... Россия император йортына савыт-саба китерү хокукы алган сирәк осталарның да маркасы, стиле шунда ук күзгә ташлана. Яратып эшләнгән, яратып кулланылган әйбердән рәхәт бер җылылык бөркелеп тора. Һәр чынаяк, һәр чәйнек, гомумән теләсә кайсы предмет күргән-кичергәннәрен үзендә саклый.

– Менә бу совет чорына – безнең балачак елларына караган чәйнекләрне генә алыйк... – дип, махсус киштәгә игътибарыбызны юнәлтә Альмира ханым. – Аларның борыннары кителә иде, шуларга бау бәйли иде әбиләр... Аларны күргән саен, балачакны, яшьлекне уйлыйм... Тирәнгәрәк кереп күмелсәң, искиткеч кызыклы өлкә бу... Очы-кырые юк!

Аның музеена ярты сәгатькә генә диеп кергән идек, сәгать кенә дә йөрмәгәнбездер. Соңыннан, беренче катка төшеп, табынга утыргач, безгә дә чәйне затлы чәйнектә пешерде ул.

– Чәйнең тәме чәйнектән тора, – дип, тортыбызны кисеп куйды да, табынга тагын әллә никадәр нигъмәт чыгарды. – Безнең әбиләр белгән аны...

P.S. Чәйнең тәме чәйнектәндер, бәлки, ә менә табынның яме, өйнең бәрәкәте – хуҗабикәдән, моныса иманым камил. Рөстәм абыйның баянда уйнавын гына ишетми калдык, ярый, анысы икенче баруыбызга калсын. Ә Альмира апа белән аларның йортында атмосфера шундый – киткәндә үк яңадан барасың килеп китәсең.

КИРӘК БУЛАЧАК:

1. Сыер бавыры – 500–600 г
2. Йомырка – 5 данә
3. Суган – 6 данә
4. Сөт – 1 стакан
5. Он – ярты стакан
6. Сыек май – 40-50 г
7. Майонез – чама белән
8. Тоз, борыч – чама белән
9. Укроп – чама белән
10. Черри помидорлары – бер тортка 3-4 данә

ӘЗЕРЛӘҮ ЫСУЛЫ:

Сыер бавырын иттарткычтан чыгарып, сөт салабыз. Йомырка, он, тоз һәм борыч өстибез, яхшылап туглыйбыз. Суганнарны, ярым боҗралар рәвешендә турап (ваграк итәргә дә була), сыек май тамызган табага салып кыздырабыз. Сүрән утта аны йомшарганчы һәм алтынсу төскә кергәнче тотабыз. Икенче табага сыек май тамызып, аш чүмече белән бавырлы массаны тигез итеп агызабыз. «Коймак»ның бер ягы кызгач әйләндерәбез. Бер торт өчен 5–6 коймак таман гына. Һәр «коймак»ка майонез белән суганны, катнаштырып, тигез итеп ягабыз да өстенә икенчесен каплыйбыз. Тортның ян-якларын вак итеп туралган укроп белән бизибез, ә өстенә черри помидорларын бүлеп тезәбез. (Тортның өстен уылган кишер белән дә бизиләр. Ул да тортка үзенә күрә бер татлы тәм бирә). Аннан тортны ярты сәгатьләп суыткычта тотып алабыз. Җылы килеш яратучылар, шулай да ашый ала.

Ашларыгыз тәмле булсын!

1. Итне чыгарабыз!

2. Турыйбыз!

3. Өстибез!

4. Кушабыз!

5. Туглыйбыз!

6. Кыздырабыз!

7. Пешерәбез!

8. Ягабыз!

9. Бизибез!

10. Тезәбез!

РЕКЛАМА

Илион, МД

НОВИНКА

90 Г/ Л КЛОПИРАЛИДА (2-ЭТИЛГЕКСИЛОВОГО ЭФИРА)
+ 40 Г/Л ИМАЗАМОКСА

ОТ СОРНЯКОВ НАДЕЖНЫЙ БАСТИОН

**ГЕРБИЦИД СИСТЕМНОГО ДЕЙСТВИЯ
ДЛЯ БОРЬБЫ СО ЗЛАКОВЫМИ И ДВУДОЛЬНЫМИ СОРНЯКАМИ
В ПОСЕВАХ РАПСА, УСТОЙЧИВОГО К ИМИДАЗОЛИНОНАМ**

- Максимальная эффективность за счет препаративной формы и сочетания двух действующих веществ
- Высокая скорость проникновения в листья сорных растений, быстрое передвижение в точку роста, корни, корневища
- Уничтожение как наземной части, так и корневой системы сорняков, включая почки возобновления и корневые отпрыски
- Сдерживание появления следующих волн сорняков (при достаточной влажности почвы)

ЩЕЛКОВО АГРОХИМ
российский аргумент защиты

Представительство «Щелково Агрохим» в Республике Татарстан
г. Казань, ул. Красносельская, д. 51а. Тел.: (843) 562-34-85
kazan@betaren.ru

www. betaren.ru

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Дөньяда иң матур җирләр **КАЙДА**

Болгар ханнары турында **НИЛӘР** беләбез

Тамырларны **НИЧЕК** өйрәнергә

Күңелең белән **НИЧЕК** яшь калырга

Өшкерүчеләр **КАЙДА** яши

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

ӘЛКИ РАЙОНЫ: ГЕРОЙЛАР ҖИРЕ

Базарлы Матак буйлап барганда, бина, стела һәм һәйкәлләргә беркетелгән такталарга күз салсаң, кайсы гына йөзьеллыкны алма, һәркайсына «тамырлары» шушында – Әлки җирендә булган үз герое туры килгәнлеге ачыклана. Әйтерсең лә, район үзенең аерым көч тупланган урыннарына ия һәм аларны сер итеп саклый. Әмма биредәге заманча объектларның нинди шартларда барлыкка килгәнен һәм хәзерге тормышның ничек баруын белгәч, нинди дер серле көч чыганагы юклыгын аңлыйсың. Дөресрәге, бар ул, ләкин җирдә түгел, ә монда яшәүче кешеләрнең үзләрендә.



Крайнов урамындагы ике катлы матур кирпеч йортта җирле туган як музее урнашкан. Анда – космонавтика залы, ә ул, беләсегез килсә, Россия космонавтика музейлары ассоциациясенә керә. Базарлы Матакны космонавтика белән нәрсә бәйли соң, дип сорарсыз. Барысы да бик гади: музей урнашкан йортны 1814 елда беренче гильдия сәүдәгәре Сергей Лисенков төзегән, ә аның оныгының улы Анатолий Михеев космос тармагында эшли. Тик Әлки ягының космик тарихы моның белән генә тәгәлләнми: космонавт Владислав Волковның бабасының атасы һәм аэрокосмос тармагының тагын тугыз эшлеклесе тумышы белән шушы яктан. Алар ярдәмендә уникаль экспозиция барлыкка килгән дә инде. Музей залларының берсендә XIX гасырдагы сәүдәгәр кибете күренеше торгызылган. Һәм кичәге, бүгенге, иртәгәге вакытны исәпләп, сәгать текелди...

Базарлы Матак Үзәк район хастаханәсенең ничек җиһазлануыннан теләсә кайсы шәһәр хастаханәсе көнләшерлек. Күчмә рентген, берничә яралгы белән көмәнле пациенткаларны карау өчен УЗИ аппараты, өр-яңа үрнәктәге реанимация җыелмалары... Моннан тыш – иркен кабинетлар, палаталар һәм кайгыртучан, квалификацияле белгечләр. Биредә «прогресс двигателе» – баш табиб Светлана Одушкина. Аның Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка язган хатыннан соң, Үзәк хастаханәнең бала тудыру бүлеген реконструкцияләү һәм тиешле барлык җиһазлар белән дә тәэмин итү өчен район 35 миллион сум акча алган.

Татарстанның парклар һәм скверларны үстерү программасы уңайлы җәмәгать урыннары һәм заманча балалар мәйданчыклары җитмәгән торак пунктларны баштанаяк үзгәртте. Базарлы Матакта паркларны яңарту мәсьәләләре белән республика программасына старт бирелгәнгә кадәр күпкә иртәрәк шөгыльләнә башлаганнар. Җирле инициативаның республиканыкы белән кушылу нәтиҗәсе искиткеч була. Мәсәлән, республика ярдәменә һәм гражданнарның үзара салым акчасына төзелгән «Геройлар паркы»нда тарих турында сөйләнә генә түгел, ул әле күрсәтелә дә. Монда Т-54 танкы куелган. Базарлы Матакта туган кече лейтенант Степан Крайнов нәкъ шундый танк белән идарә иткән, ул бөтен сугышны үтеп, Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган.

Әфган сугышында катнашкан Рөстәм Шәйхетдинов җитәкчелек итә торган «Хәрби туганлык» («Боевое братство») оешмасы хәрби хәрәкәт ветераннарын берләштерә. Киләсе елга аның Базарлы Матакта ачылуына 10 ел тула. «Туганлык»та катнашучылар ветераннарга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итә, сугышларда һәм локаль бәрелешләрдә катнашкан Әлки кешеләре турындагы истәлекләрне саклау турында кайгырта – аларның хөрмәтенә, район мәктәпләре укучылары ярдәме белән, Базарлы Матакта һәйкәл куелган һәм Дан аллеясы ачылган. Ә инде «От Афгана до Чечни» дигән вокаль-инструменталь ансамбль Россия һәм халыкара солдат җыры фестивальләрендә катнаша, яшь буын арасында патриотик эш белән шөгыльләнә. Күптән түгел «Туганлык» «Время выбрало нас» («Вакыт безне сайлады») дигән хәтер китабын чыгарган. «Китап яшьләргә илебез тарихы, якташларыбыз язмышы турында белергә ярдәм итәр, халык язмышы турында ихлас борчылырга өйрәтер, аларда шәхес буларак һәм ватанының патриоты буларак бәяләнә торган сыйфатларны тәрбияләр», – дип ышанып әйтә Рөстәм Шәйхетдинов.

Районда социаль инфраструктураның динамик үсешенә нигезле фундамент – Агросәнәгать комплексыннан башка ирешеп булмас иде. 2017 елда авыл хуҗалыгы продукциясенең гомуми күләме дүрт млрд сумга якын күләмне тәшкил иткән. Аның якынча 80 проценты эре авыл хуҗалыгы предприятиеләренә – «Кызыл Шәрык» ААҖнә һәм «Хузангай» ҖЧҖнә туры килә. Агросәнәгать комплексында барлыгы 1,3 мең кеше мәшгуль. Район хуҗалык итүнең кече формаларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга актив булышлык күрсәтә. Аның территориясендә бүгенге көндә 45 фермер хуҗалыгы, шул исәптән 28 гаилә фермасы эшли. 2017 елда ике дәүләт программасы буенча алты Әлки хуҗалыгы гомуми бәясе 22,9 млн сумлык грантлар откан. Аннан алдагы ике елда районда 56 мини-ферма төзелгән. АСК үсешендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе – терлекчелек тармагы. 2017 елда терлекләрнең баш саны, 2016 елның шул чоры белән чагыштырганда, ике процентка арткан һәм мөгезле эре терлекнең саны 32154 башны тәшкил иткән.

БАЗАРЛЫ МАТАК: КҮР ӘЛЕ, СИН ЯШИ ТОРГАН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

«Әлки районында бик максатчан кешеләр, талантлы яшьләр яши. Биредә Олимпия уеннарының булачак призёрлары барлыкка киләчәгенә бер шик юк», – ди Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Базарлы Матакта «Ләйсән» бассейнын тантаналы ачу вакытында. Берничә ел элек «Алина» спортзалы төзелгән. Мондый лирик яңгырашлы исемнәр спорт объектларына Олимпия чемпионы Алина Кабаева һәм аның сеңелесе Ләйсән хөрмәтенә бирелгән. Аларның бабасы – тумышы белән Урта Әлки авылыннан...

Республика трендына кушылып, район җитәкчелеге һәм каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару буенча җирле оператор чүпне аерым җыю өчен берничә нокта оештырганнар. Беренче контейнерлар Базарлы Матакның үзәк урамында пәйда булган.

ЯҢА ЭРА ТУДЫРУЧЫЛАР

Яшьләр көне алдыннан «Татарстан» журналы проектлар төзү институты белән таныштыра. Анда әлеге нигез шулкадәр ныклы һәм сыйфатлы итеп салынган ки, яшь белгечләр инде хәзер үк көннән-көн зуррак уңышларга ирешә.

ҖИҢҮ – АЛАР КУЛЫНДА!

... Икенче тайм бара. Исәп кировлылар файдасына – 2:3. Аларның Казаннан килгән көндәшләренең җиңүгә түгел, хәтта уртак нәтиҗәгә дә өмете юк кебек. Кырга Казан командасының уенчы тренеры Дмитрий Благов чыга һәм, бернечә минуттан соң ук, бик тиз комбинация ясап, тупны капкага кертә. «Казан Гипронииавиапром» АҖнең мини-футбол командасы авиация сәнәгате предприятиеләре хезмәткәрләре арасында Профавиа кубогына май азагында Туапсе шәһәрендә үткән XIX турнирның беренче уенын шул рәвешле уртак нәтиҗәгә тәмамлый. Калган матчларда команда бик шәп уйный, финалга үзенең беренче лигасында җиңүче булып килеп җитә. Бүләктән тыш, казанлылар, иң тәртипле команда буларак, дипломга да лаек була, Дмитрий Благов исә турнирның иң шәп уенчысы дип таныла.

– Турнирга Екатеринбург, Сарапул, Киров, Ростов, Таганрог, Арсеньевтагы авиация сәнәгате предприятиеләре белгечләре килгән иде. Әлеге предприятиеләрнең күбесе белән безнең уртак проектларыбыз бар, ә рәсми булмаган шартларда аралашу җитештерүләр арасында хезмәттәшлекне арттыруга булыша. Моннан тыш, башка проектлар белән эшләүче коллегаларыбызныңниләр майтаруы белән танышу да һәрвакыт кызык, – ди институт командасы капкачысы, авторлык күзәтчелеге инженеры Дамир Габитов.

– Казанда без «Туполев» ГАҖ филиалы – С.П.Горбунов исемендәге КАЗ, «Союз» СКБ, КВЗ һәм башка командалар белән югары лигада мини-футбол уйныйбыз. Туапседагы турнир безгә офыкларны киңәйтү, башка шәһәрләрдән килгән командалар белән уйнау мөмкинлеге бирде. Әмма футболдан тыш аралашу да күп булды, һәм бу да бик мөһим, – ди команда уенчысы, проектның баш инженеры Ринат Әдһәмов.

Бередә уен традициягә әйләнмәсә, һәм бу традицияне үзләренең шәхси үрнәкләре белән өлкән буын конструкторлары һәм проектчылары сакламаса, институт командасы шундый көчле булыр идеме икән соң? Аларның күбесе әле бүген дә яшьләрдән уздыра. Генераль директорның проектлаштыру һәм технологик җиһазландыру буенча беренче урынбасары, баш технолог Сергей Лалетин, генераль директорның фән буенча урынбасары Александр Коршунов һаман футбол уйныйлар. Мини-футбол буенча команда төзү исә – Борис Тихомировның әллә никадәр спорт инициативаларыннан берсе. Ул үз хезмәткәрләренең физик үсешен һәм сәламәт яшәү рәвешен хуплый: институтта моның өчен кирәкле бөтен нәрсә дә бар – һәр кабинеттагы селектордан (аның буенча 11.00 һәм 15.00 сәгатьтә физзарядка программасы тапшырыла) алып тренажер залына кадәр. Шунлыктан институт белгечләре спортның төрле төрләре буенча шәһәр һәм тармакара ярышларда даими җиңү яулыйлар. Инженер Александр Шимин йөзү буенча төбәк, федераль һәм хәтта халыкара ярышларда беренчелекне бирми. Инженерлар Владимир Грачев белән Василий Симаков яткан килеш штанга күтәрә (127,5 кг). Институтның Роберт Шәфигуллин һәм Александр Игнатов җитәкчелегендәге чаңгычылар командасы барлык ярышларда актив катнаша һәм быелгы сезонны япканда тармактагы «Профсоюзлар яшьләр чаңгы ярышы – 2018» бәйгесенең сайлап алу этабында җиңгәннәр. Институтның спорт активистлары арасында пневматик винтовкадан ату, өстәл теннисы, волейбол буенча төрле ярышлар призерлары, алтын, көмеш, бронза ГТО билгеләре ияләре дә бар. Шунлыктан «Казан Гипронииавиапром» АҖнә эшкә яңа урнашучылар спорт тормышыннан берничек тә читтә кала алмый. Ә сәламәт тәндә, мәгълүм булганча, сәламәт рух һәм йөгерек акыл да!

ХАЛЫКАРА ҮРНӘКТӘГЕ ПРОЕКТЛАШТЫРУ

Быел ноябрь аенда төрекләрнең «Алабуга» МИЗ территориясендә урнашкан «Хәят Кимья» санитария-гигиена өчен кирәкле кәгазьләр һәм тастымаллар чыгару заводы икенче җитештерү чиратын эшләтеп җибәрәчәк. Хәтерләсәгез, Төркиянең заводка керткән инвестицияләре 150 миллион долларны тәшкил итте. Ул 2015 елда рекордлы кыска срокта (18 айда) төзелде. «Минем сезне котлыйсым килә – сез «Алабуга» МИЗ кебек структура төзи алдыгыз. Мин мондагы шартлардан көнләшә генә алам. Бирегә яңа инвестицияләр агылыр, дип уйлыйм», – диде заводның ачылу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка Төркиянең икътисад министры Нихат Зейбекджи. Предприятиене төзү вакыты һәм башкарылган эшнең

Фотолар «Гипрониавиапром» АҖнән алынды.

Реклама

сыйфаты төрекләргә куәтле тәэсир итте. Болар барысы да әлеге колачлы җитештерү өчен сыйфатлы проект документациясен эшләүчеләрнең хезмәте нәтиҗәсендә мөмкин булды.

– «Хәят Кимья» – безнең «Хәят» холдингы өчен ясалган икенче проектыбыз. Беренчесе – «Кастамону интегрейтед вуд индастри» МДФ-панельләр җитештерү заводы. Аның проектын төзүче оешманы эзләү этабында «Хәят» вәкилләре Татарстан һәм Россия компанияләренә коммерция тәкъдимнәрен җибәргән. Аларны безнең тәҗрибәбез һәм проектта катнашучы төп белгечләрнең төрекчә белүе кызыктырган, шуңа безне сайлаганнар, – дип сөйли проектның баш инженеры Ринат Әдһәмов. – Хезмәттәшлек процессында, төрле җитештерүләрнең технологияләре белән танышу өчен, без берничә тапкыр Төркиягә бардык. Туристлык зоналарына түгел, бәлки Кастамону, Еникей, Мерсин кебек сәнәгать шәһәрләренә. Шул рәвешле безнең шактый хезмәткәребез – конструкторлар һәм технологлар – чит ил җитештерүләрен өйрәнү буенча яхшы тәҗрибә туплады. Шулай булса да, «Хәят» проектлары безнең өчен нәрсәсе беләндер өр-яңа иде. Без кайбер чишелешләрне яңабаштан ясадык. Мәсәлән, Төркиядә башка климат, башка төрле җил һәм җылылык күрсәткечләре. Моннан тыш, анда заводлар җир тетрәү ихтималын исәпкә алып салына, бездә исә андый куркыныч юк. Шунлыктан хәтта инде типлаштырылган чишелешләр дә кабат исәпләүне таләп итте. Кайбер чишелешләр Россиядә гамәлдә булган нормативларга тәңгәлләштерүне таләп итте. Һәм без төрек ягы вәкилләренә болай эшләүнең зарурлыгын дәлилләргә мәҗбүр булдык. Мондый мизгелләрдә шәхсән минем үземә төрекчә белүем бик булышты. Моннан тыш, стандарт булмаган чишелеш таләп иткән бурычлар да күп иде. Бу һәрвакыт проектка уникальлек өсти, һәм чишелешләрне табу бик кызыклы.

Хәзер институт төрек инвесторларының Татарстан һәм башка илләр территориясендә яңа җитештерүләр проектлаштыруның берничә юнәлеше буенча эшли. Болар барысы да – Татарстанның ышанычлы партнер буларак имиджын көчәйтүгә бер өлеш, республика һәм ил территорияләрендәге проектлар белән кызыксынган чит ил инвесторларына безнең һәрьяклап булышырга әзер булуыбызны күрсәтә. Апрель азагында Истанбулда үткәрелгән Татар-төрек форумы кысаларында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация (аның составында «Казан Гипронииавиапром» АҖ вәкилләре дә бар иде) төрек бизнес-элитасы белән яңа проектлар өчен перспективалар ачкан очрашулар үткәрде.

ФӘН ҺӘМ ЯШЬЛЕК КУШЫЛМАСЫ

Сезгә Иннополис университетының үзәк ишек өстендәге консоль эчендә урнашкан аудиториясендә булырга туры килсә, тәрәзәгә карагыз һәм әлеге консоль «эленгән» вантларны күрерсез. Беренче карашка шундый гади тоелган конструктив чишелеш «Казан Гипронииавиапром» АҖ белгечләреннән проект бурычына фәнни яктан якын килүне таләп иткән. Конференц-залны проектлаштырганда да шундый ук технология кулланылган. Архитекторлар идеясе буенча, аның гаять зур мәйданы колонналар белән бүленмәскә тиеш булган, шунлыктан зал өстендәге катны «элмә» рәвештә ясарга карар кылганнар…

– Без кайчандыр уйлап тапкан стандарт булмаган «конструктивлар» турында тулы бер китап язып булыр иде. Мондый бурычлар шактый еш очрый, һәм, кагыйдә буларак, катлаулы объектларда, ә безнең «база», авиация тармагы өчен нәкъ шундыйлар проектлана да инде. Проект төзүче еш кына нормаларда чишелеше булмаган хәлдә кала. Әмма ул фәнни яктан көчле икән, идеаль чишелешне таба алачак. Тик чишелешне тапканчы исәпләүләр үткәрү зарур. Исәпләү үткәрү өчен тикшерену кирәк, бу исә озакка сузылган һәм күп хезмәт таләп итә торган процесс. Шунлыктан яшь конструктор яки инженер фәнни эшчәнлек белән никадәр иртәрәк шөгыльләнә башласа, җитди мөстәкыйль проектка керешкән вакытка тәҗрибәсе шулкадәр күбрәк булачак, – ди генераль директор урынбасары, институтның баш конструкторы, техник фәннәр кандидаты Георгий Никитин.

«Казан Гипронииавиапром» АҖ җитәкчелеге үз хезмәткәрләренең фәнни эшчәнлегенә һәрвакыт хәерхаһлы карый. 2017 елда институтта «Елның иң яхшы яшь проектчысы» конкурсы уздырыла башлаган. Ул ике этапта үткән, һәм бәйгедә катнашкан 26 белгечнең 7 се 2018 елда җиңгән. Төп критерийлар – конкурсантның игътибарга алырлык тикшеренүләре һәм исәпләүләре, фәнни публикацияләре, диссертациясе булу. Җиңүчеләрнең берсе – Василий Симаков. Ул былтыр декабрьдә диссертация яклаган, 8 фәнни мәкалә бастырган, бәйгегә исә бетон конструкцияләрдәге горизонталь кушылу урыннарының

ярылуга чыдамлыгын исәпләү методикасын тәкъдим иткән. Методиканы төзү этапларының берсендә Аграрная урамындагы күпкатлы парковка тикшерену объектына әйләнгән.

Тармакның нәтиҗәлелеге предприятиеләрнең нәтиҗәлелегенә нигезләнә, аларның уңышы исә, шул исәптән, алардагы белем һәм тәҗрибә күчү системасының никадәр алга киткән булуына да бәйле. Генераль директор Борис Тихомиров керткән яшьләрне җәлеп итү һәм «үстерү» традициясе нәтиҗәсендә бүген «Казан Гипронииавиапром» АҖ нең берничә төп бүлеген 30–35 яшьлек җитәкчеләр җитәкли. Бу предприятиегә өр-яңа технологияләрне активрак кертү, тармактагы трендлардан алдарак бару һәм Россия проект төзү компанияләре белән институтлары арасында лидерлардан берсе булу мөмкинлеген бирә.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

АЛМЫШТАН СОҢГЫ БОЛГАР ӘМИРЛӘРЕ

Болгар дәүләте X гасыр башларында оешып (бәлки, бераз элегрәктәдер әле), 1236 елга, монгол-татар яуларына кадәр, ягъни аз дигәндә 336 ел чамасы яшәгән, дигән идек. Шул заман эчендә ил белән, ким дигәндә, ике дистәдән артык хан (әмир) идарә иткән булырга мөмкин (һәр хан тәхеттә уртача 15 ел чамасы утырган очракта). Ханнар арасында берничә ел гына идарә итеп калганнары да булган, әлбәттә. Кызганыч, үз язма чыганакларыбыз булмау аркасында, ханнарыбыз турында бик аз беләбез. Узган язмаларыбызның берсендә Шәлки угылы Алмыш / Җәгъфәр ибне Абдаллах турында бераз мәгълүмат биргән идек. Хәзер аннан соңгыларына тукталып үтик.

Автор:
Фаяз Хуҗин

БЕЗ АЛАРНЫ БЕЛӘБЕЗМЕ?

Җәгъфәр ханның кайчанга кадәр идарә итүе төгәл билгеле түгел. «332 (943) елда әмир Җәгъфәрнең сәламәт булуы, Кастантиния һәм шул тарафтагы мәмләкәтләргә һөҗүм итүе Әбел-Хәсән Мәсгуди китабында ачык итеп әйтелгән», – дип яза Мәрҗани, Идел болгарлары белән Дунай болгарларын бутап. Әхмәт ибне Фадлан язмаларыннан Алмышның берничә улы булганлыгы мәгълүм, тик аларның исемнәре атап әйтелмәгән.

X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп тарихчысы һәм географы әл-Мәсгуди, Җәгъфәр хан угылларының берсе, өлкәнрәге (**Мәмәктай?**), әле Мөкътәдир хәлиф исән вакытта ук (908–932) Мәккәгә хаҗ кылды, дип язып калдырган. Мәмәктайның исеме 921–922 елларда сугылган акчаларда да сакланган. Мәмәктай озак идарә итмәгән һәм үзеннән соң нәсел калдыра алмыйча үлеп киткән, дип фаразлана.

Микаил ибне Җәгъфәр Болгар дәүләтенең өченче ханы булган. Аның исеме шулай ук Мөкътәдир хәлиф заманында сугылган болгар дирһәмнәрендә сакланып калган. Микаил ибне Җәгъфәр 930 нчы елларга кадәр хакимлек иткән дип фаразлана. Ул хакимлек иткән чорда калалар төзү эше тагын да киңрәк төс ала, ә Болгар белән Сувар исә хәтта гарәп сәяхәтчеләренең хезмәтләрендә дә телгә алына башлый. Микаил ибне Җәгъфәрдән соң бу ике шәһәр мөстәкыйль вилаятьләрнең (кенәзлекләрнең) башкалаларына әверелеп китәләр. Икенче төрле итеп әйткәндә, Сувар, ниндидер сәбәпләр аркасында, Болгардан аерылып чыга.

Абдаллах ибне Микаил – Микаил ибне Җәгъфәрнең улы, Болгар дәүләтенең дүртенче ханы. Ул 940 нчы елларда хакимлек иткән булырга тиеш, аның исеменнән сугылган көмеш дирһәмнәр 946 елда тәхетеннән куылган (һәм үтерелгән) хәлиф әл-Мөстакфи чорына карый.

Мөэмин ибне әл-Хәсән исемле хан 976–985 елларда идарә иткән. Аның исеменнән суктырылган акчаларда хәлиф ат-Таи (974–992) исеме бар. Мәгълүм булганча, Суварда акча сугу эше 976 елда тукталып кала. Шул фактка нигезләнеп, без Мөэмин ибне Хәсәнне яңадан берләштерелгән Болгар-Сувар вилаятьләренең – Идел Болгары дәүләтенең ханы дип әйтә алабыз.

Мөэмин ибне Әхмәд Сувар әмире Талиб ибне Әхмәднең бертуган энесе булырга тиеш дип фаразлана. Аның исеме 975–976 елларда Суварда һәм 976–977 елларда Болгарда сугылган акчаларда сакланып калган. Күренекле нумизмат С.А. Янина мәгълүматларына караганда, Мөэмин бине Әхмәд Болгар дәүләте белән әле 986–987 еллар тирәсендә идарә иткән.

Күргәнегезчә, X гасырда Болгар тәхетендә утырган ханнар арасыннан без бары тик бишесенең генә исемен атый алабыз. 950–960 нчы һәм 990 нчы елларда Болгарда кемнәр идарә иткәндер – нәмәгълүм.

Кырык ел чамасы – 930 нчы еллардан башлап 970 нче елларга кадәр – Сувар мөстәкыйль вилаять рәвешендә яши, дигән идек. Нумизматика чыганакларына таянып, Сувар идарәчеләренең исемнәрен дә атый алабыз. Аларның беренчесе – Талиб ибне Әхмәд 948–958 елларда, икенчесе – югарыда телгә алынган Мөэмин ибне Әхмәд – безгә 975–976 елларда сугылган акчалары аша таныш.

Фотолар автордан алынды

ИБРАҺИМ ХАН ЭЗЛӘРЕННӘН...

Ни гамәлләр кылганнардыр безнең ханнар үзләре идарә иткән чорда – билгеле түгел. Әмма фаразларга мөмкин. 977, 985, 994, 997 елларда Киев Русенең бер «изгесе» – халыкны чукындырып, илгә православие дине индергән өчен «Красное Солнышко» кушаматы алган кенәз Владимир Святославич Болгар иленә яу чаба: «много ратовав, их победи и възвратися с радостию в Киев», «болгары воложскиа и камские одолев, плени их». Болгарлар исә Рус дәүләтенә бер тапкыр да сугыш белән бармыйлар, әмма үзләренең шәһәр-авылларын чит-ятлардан саклап калу өчен батырларча көрәшәләр. Аңлашыла ки, бу көрәшне оештыручылар, чик буйларында дошманнарга каршы тора алырлык кала-крепостьлар төзетүчеләр ил башында утыручы ханнарыбыз була. Болгарлар Рус дәүләте белән сәүдә итешү юлы аша якынлашырга омтылалар. Нәкъ менә алар башлангычы белән 985 елда Русь белән Болгар арасында рәсми рәвештә сәүдә килешүе төзелә. 986 елда, Владимир Святославичның мәҗүсилек урынына яңа дин «эзләү» чорында, болгар ханы Киевка хәтта махсус илчелек җибәрә, Владимирны, ике ил арасында дуслык җепләрен ныгыту максатында, ислам дине кабул итәргә чакыра. Кыскасы, X гасырда ил башында утыручы болгар ханнары тыныч хезмәт белән мәшгуль булганнар, дип әйтә алабыз. Ул хезмәтнең нәтиҗәләрен без XI гасыр башында идарә иткән **болгар ханы Ибраһим** мисалында күрәбез.

Ибраһим ханның ничәнче елларда тәхеттә утырганын белмибез. Аның турында бердәнбер язма XII гасыр фарсы тарихчысы Әбүл-Хәсән Бәйхаки хезмәтендә сакланган. «Тарихи Бәйхак» дип аталган әлеге хезмәттә

түбәндәге юллар бар: «Болгарның һәм тулаем Болгар дип атала торган өлкәнең әмире Әбү Исхак Ибраһим ибне Мөхәммәд ибне Б.л.т.вар [элтебер – юлбашчы] исемле кеше иде. 415/1024–1025 елда ул үзенең биләмәсендә төш күрә: сиңа, имеш, Нишапур өлкәсендәге Бейхакка, шундагы Себзевар һәм Хөсрәүҗәрд исемле шәһәрләрдә Җәмигъ мәчетләре төзеттерү, шул эшкә сарыф итү өчен акча җибәрергә кирәк… Ул Нишапурга чыннан да бик күп акча, Хөрәсән патшасы өчен исә моңа кадәр бер кеше дә күрмәгән-белмәгән гаҗәеп бүләкләр (дөнья могҗизасы!) җибәрә. Шул вакытта ук акчаларны шул ике мәчетне төзүгә сарыф иттеләр». Бу хәбәрдә Болгар иленең XI гасыр башларындагы икътисадый һәм мәдәни халәтен объектив рәвештә күз алдына китерү өчен кыйммәтле мәгълүматлар тупланган. Беренче чиратта, безне Болгарның – әлбәттә, тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре нәтиҗәсе буларак – ерак өлкәләргә таралган даны таң калдыра. Күрәсең, Болгар иле бай дәүләт булган, хәерче дәүләт әллә кайдагы, күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирдә мәчет салу өчен хәйрия акчасы җибәрмәс иде.

Шул ук 1024 елга караган тагын бер хәбәр. Бусы рус елъязмаларында теркәлеп калган: «Суздаль җирендә бик зур фетнә-чуалышлар һәм ачлык («мятеж велик и голод») булды. Ач халык Идел буйлап Болгарга агылды, аннан ашлык алып кайтып, ачлыктан котылды». Әйе, Болгар җире – уңдырышлы, халкы – эшчән, менә дигән игенчеләр, иген уңышы үзләренә дә җитә, сатуга да кала. Алай гына да түгел, кайчакта, ачлык елларны, болгарлар үзләренең рус күршеләренә ашлыкны бушлай, хәйрия рәвешендә дә җибәрә торган булганнар. Ике ил арасындагы дустанә мөнәсәбәтләр 1006 елда – Ибраһим хан тәхет хуҗасы булган чорда! – төзелгән сәүдә килешүенә нигезләнгән.

Икътисад үсешенә бәйле мәсьәләләргә килеп төртелгәч, XI гасырда һөнәрчелек өлкәсендә барлыкка килгән яңалыклар турында да әйтеп үтәргә кирәктер. Ул яңалыкларның берсе югары технологияләр таләп итүче пыяла һәм ялтыравык йөгертелгән керәч савыт-саба эшләп чыгару, икенчесе зәркән сәнгате өлкәсенә карый. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: һөнәрчелекнең пыяла эшләп чыгару тармагы озак еллар буе русларда һәм болгарларда гына үсеш алган. XII гасыр Болгар иленең чәчәк атып яшәү чоры дибез икән, әлеге чорның чишмә башын, минемчә, нәкъ менә Ибраһим хан дәвереннән эзләргә кирәктер.

Укучыларбыздан тагын бер нәрсәгә игътибар итүләрен сорыйбыз: нәкъ менә Ибраһим хан идарә иткән чорда бит инде Казан белән Алабуга кебек атаклы болгар калаларына, исемнәре тарихта эзсез югалып калган күп кенә башка шәһәрләргә, авылларга нигез салына. Рус елъязмаларында берничә тапкыр телгә алынган Бряхимов шәһәре дә (аны галимнәр элегрәк Алабуга, аннан соң Болгар, ә кайберәүләр Ока елгасы буендагы болгар каласы белән тиңләштереп карадылар), һичшиксез, Ибраһим ханга нисбәтле, дип уйлыйбыз. Ярыйсы гына бай шәһәрләр булган алар. Биләр, Сувар, Мөрән (Муромский городок, Самара өлкәсе), Кызыл Сөндек (Красносюндюковское городище, Ульяновск өлкәсе) кебек эре шәһәрләрдә иҗтимагый биналар кирпечтән һәм таштан салынган. Аларның хәрабәләре төрле елларда археологлар тарафыннан казып тикшерелде.

Кыскасы, Ибраһим хан Болгар дәүләте тарихында җуелмас эз калдырган. Тикмәгә генә аңа Алабуга шәһәрлегендә («Шайтан каласы»нда) мәһабәт һәйкәл торгызып куймадылар инде. Ибраһим хан анда атка атланган җайдак рәвешендә сурәтләнгән. Башкалабызга нигез салган хан буларак, аңа бер бик матур һәйкәл куюны Казан халкы да дәррәү күтәреп алыр иде, шәт.

ОНЫТМАСАК ИДЕ…

Гаҗәп хәл: Ибраһим ханнан соң идарә иткән бер генә болгар ханының да исеме тарихи чыганакларда сакланып калмаган. Хуш, югарыда саналганнарның да исемнәрен башлыча нумизматлар ачты бит. Болгарда, гомумән бөтен Европада диярлек, X гасыр ахырыннан алып XIII гасыр башларына кадәр көмеш акчалар сугу чимал җитмәү сәбәпле тукталып торган, димәк ки, ханнарның ул акчаларга язылырга тиешле исемнәре дә безнең көннәргә кадәр килеп җитә алмаган.

Атаклы дин галиме һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре үзенең «Мостафадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле китабында, XVIII йөз ахыры тарихчысы Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәренә таянып, ышанычлы чыганаклардан безгә билгеле булмаган болгар ханнарының исемнәрен санап үтә. Биредә Шәлки һәм аның улы Алмыш/Җәгъфәр ханга кадәр идарә иткән ханнар арасында Тукый, аннан соң аның улы Айдар (әлеге хан вакытында, ягъни VII гасырда, Болгарга, имештер, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләре килгән, халык мөселманлыкны кабул иткән), аннан соң Зөбәер хан күрсәтелгән.

Җәгъфәрдән соң идарә иткән беренче хаким сыйфатында Шиһабетдин Мәрҗани Әхмәд ханны атый: «Бу шәхес Мөкътәдир биллаһ хәлифәлеге вакытында Багдад аркылы хаҗга барып, хәлифәлек диварыннан аңа күп маллар, хайваннар, киемнәр, байраклар, музыка кораллары бүләк итеп бирелгән». Әхмәд ханнан соң тәхетне аның улы әмир Талиб биләп торган («338/949 елда бу шәхес исемендә шәһре Болгарда сугылган тәңкәләр бар»). Аннан соң аның улы Мөэмин әмир булып торган. Аннан соңгы ханнар: Шәмгун («Бу кеше Дунай болгарларыннан булса кирәк», – дип искәртә Мәрҗани), аның улы Мөхәммәд, аның улы Сәгыйд, аннан соң Бараҗ, Ибраһим («1164 тә бу кеше әле исән була»), аның улы Сәлим. Болгарларның монгол-татар яуларына каршы торуын оештырган соңгы ханнары – Илһам («ул патшалык иткән заманда, 620/1223 елның ахырында, татарлар шәһре Болгарга килеп, болгарлардан җиңелеп, исән калганнары… Чыңгыз хан алдына кайтып китә»).

Шиһабетдин Мәрҗани үзе Мөслиминең «Тәварихы Болгария»сен кискен тәнкыйтьли, авторын хәтта алдакчы дип атый, шулай да ул телгә алган ханнарның исемлеген нигездә хуплый.

Соңгы сүз итеп, нәрсә дияргә соң? Әйе, болгар ханнары турында мәгълүматларыбыз бик ярлы. Киләчәктә тулыланыр дигән өмет тә ул кадәр ныклы түгел. Яңа язма документлар табылу ихтималлыгы юк дәрәҗәсендә. Моңарчы билгеле булмаган хан исеме язылган тәңкәләр табылса гына инде. Ә шулай да безгә мәгълүм ханнарның исемнәрен онытмаска иде. Бүгенгебез шулардан юл алган бит.

ТНВ «ТАЛАНТ» өчен миллион бирә

«Талант» конкурсының төп призы – яңа авторлык программасын булдырган өчен бер миллион сум. Конкурста җиңгән проект ТНВ каналындагы эфир вакытына ия булачак.

Инде март аенда ук игълан ителгән татар телендәге «Талант» видеопрограммаларына конкурс – татар телендә эксклюзив проектлар эшли алучы иҗади сәләтле кешеләрне эзләүгә юнәлтелгән. Башкарма директор урынбасары – «ТНВ»-ның сәнгать тапшырулары буенча баш редакторы Данил Гыйниятов әйтүенчә, конкурс эшләрен сайлау барышында өстенлек профессиональ студияләрдә эшләнгән проектларга бирелә. «Әмма, – дип басым ясады ул, – барлык конкурс видеолары да һичшиксез каралачак, чөнки «Талант»ны оештыручыларны әзер продуктлар гына түгел, оригиналь идеяләр дә кызыксындыра.

Иҗади ярышта җиңүчеләр уникаль шанска – авторлык программасының республика төп телеканалында трансляцияләнүенә һәм киләчәктә ТНВ белән хезмәттәшлек итү мөмкинлегенә ия була.

Конкурста катнашучыларга татар халкының, Татарстан авылларының тарихы, республиканың үткәне һәм бүгенгесе, фольклор, төрки халыкларның музыка кораллары, иҗади шәхесләрнең портретлары белән таныштыра торган заманча актуаль темаларны яктыртачак яңа телепродукт булдыруда үз көчеңне сынап карау өчен сирәк шанс бирелә. Әлеге юнәлештәге эшләр «Тарихи» һәм «Әдәби-музыкаль» номинацияләрдә катнаша ала. Әле тагын «Шоу-программа» номинациясе дә бар, ул креатив һәм эксклюзив күңел ачу проектларын булдыруны күздә тота.

Иҗади ярышны оештыручылар конкурска бары тик татар телендәге эшләрнең генә кабул ителәчәгенә аерым басым ясый. «Безнең конкурсның төп бурычы – татар телен пропагандалау һәм популярлаштыру. Конкурста безнең республикада яшәүчеләр генә түгел, Россиянең башка төбәкләрендә һәм шулай ук якын һәм ерак чит илләрдә яшәүчеләр дә катнаша ала», – дип билгеләп үтте ТНВның әдәбимузыкаль редакциясе баш редакторы Миләүшә Сибгатуллина.

Ул, иҗади хезмәтләрне бәяләгәндә, жюриның яктыртыла торган темага заманча караш, милли колорит, грамоталылык, креативлык, әдәби татар телен белү һәм, әлбәттә, эчтәлекнең оригинальлеге кебек критерийларга аерым игътибар итәчәгенә басым ясады.

ТНВ җитәкчелегенең конкурсантларга махсус теләкләре дә бар.

«Телепрограммаларны төрләндерәсебез килә. Мәсәлән, бездә Татарстанның табигате һәм хайваннар дөньясы турында программа юк – республикада бу турыда, бигрәк тә татар телендә, бер генә проект та юк. Бездә шулай ук татар телендә медицина һәм икътисад программалары да юк. Бүген сәламәтлек һәм сәламәт тормыш алып бару турында программалар популяр. Ләкин бездә анысы да юк. «Талант» конкурсында катнашучылар безнең теләкләрне ишетер дип өметләнәм. Хәзер халыкка кыска программалар кирәк – зур проектлар үзләштерелми, тамашачыга берәр сәгатьлек программалар кызык түгел. Ә аларны зур проектларда тотып тору бик катлаулы – моның өчен зур ресурслар да кирәк», – дип сөйләде Данил Гыйниятов.

«Талант» конкурсына эшләр 31 июльгә кадәр кабул ителә. Аңа нәтиҗәләр 31 августта ясалачак.

Һәр номинациядә җиңүчеләр дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә һәм үз программасының ТНВда трансляцияләнү хокукына, шулай ук киләчәктә «Яңа Гасыр» телеканалы белән хезмәттәшлек итү мөмкинлегенә дә ия була.

Конкурс шартлары белән киңрәк ТНВның

www.tnv.ru

рәсми сайтында танышырга мөмкин.

Реклама 0+

НӘСЕЛ АГАЧЫҢНЫ БЕЛӘСЕҢМЕ?

Шәҗәрә төзү – үткәннәргә сәяхәт, маҗара һәм, ахыр чиктә, үзең турында күбрәк белү ысулы да ул.

Автор:
Ксения Сёмина

«Младенец Василий, родился 22 августа, крещён 23 августа. Родители Фома Семёнов и Параскева Егорова. Восприемники (крёстные – **ред.**) крестьянин Яков Семёнов и девица Яковлева», дип язылган Сапуголи авылының 1894 ел өчен чиркәү метрика кенәгәсендә. Моннан бер-ике гасыр элек яшәгән кеше турында шундыйрак кыска белешмәне мөселман метрика кенәгәләре дә бирә. Әмма шул нәни генә мәгълүматны табар өчен шактый тырышырга кирәк.

Иң гади ысулдан башлау зарур: нәселдәге иң өлкән кешедән сораштырып, әби-бабайлар турында бар мәгълүматны сурәттәге шикелле итеп агач ябалдашына язып куярга кирәк. Болай эшләгәндә, язмаларны табу, үзара чагыштыру, яңа ачыкланган мәгълүматны өстәп кую җиңелрәк тә, уңайлырак та. Башта нинди дә булса бер генә ботакны ачыклау яхшы. Әби-бабаларның туган һәм үлгән еллары, исемнәре (якыннары һәм танышлары ничек эндәшкән, рәсми документларга ничек кертелгән) зур әһәмияткә ия. Инде бу этапта ук сезне сюрпризлар көтәргә мөмкин.

МОРЗАЛАР АВЫЛЫ

– Мәсәлән, крестьяннарның даими фамилияләре рәсми до-

Фото: Александр Ефремов



кументларда чагыштырмача күптән түгел–XIX гасыр азагы – XX гасыр башында гына пәйда булган. Русларныкы бераз алданрак, татарларныкы соңрак. Ул вакытка кадәр бала атасының исеме үзеннән-үзе фамилиягә әйләнә торган булган. Төрле документларда исем-фамилия төрлечә язылырга да мөмкин, – дип сөйли тарихчы һәм архивчы Ленар Мифтахов. – Мәсәлән, төрле чыганакларда минем бабамны төрлечә язганнар: Сатретдинов (Сагдетдинов һәм тагын 9 төрле язылыш) Зәйнәк/Зәйнетдин/ Зәйнәлзәбетдин Габделвәли улы. Бабамның әтисен мин көчкә эзләп таптым, чөнки аның исемен документларда Габделвәли дип түгел, Вәли дип язганнар икән. Әни нәселе ягыннан шәҗәрә төзүгә минем 8 еллап вакытым китте.

– Революциягә кадәр эш кәгазьләре татар телендә тутырылган, анда фарсы һәм гарәп алынмалары бик күп булган. Метрика кенәгәсенә гарәп хәрефләре белән язганнар. Канцелярия теле сөйләм теленнән бераз аерылган, бу русларда да шулай.

Мәсәлән, XIX гасырның икенче яртысындагы «Ревизия язмалары»нда «билетлы солдат» термины очрый. Димәк, ул үзе срогы чикләнмәгән ялда булган, әмма солдат хезмәтендә саналган, – дип сөйли Ленар Мифтахов. – Әмма кыенлык көтелмәгән җирдән дә килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән, керәшеннәрне православие метрикаларына да, мөселман метрика кенәгәләренә дә кертмәгәннәр. Һәм менә Урта Чаллы авылы (хәзерге Түбән Кама районы) керәшеннәре үзләрен татар дип танытыр өчен берничә дистә ел буе йөргән. XX гасыр башында, ниһаять, үз дигәннәренә ирешкәннәр. Шулай итеп, әйтик, нинди дә булса Николай Петров кинәт Мөхәммәд Бадыйковка әйләнгән икән, рәсми документлар да, гомумән исемне алыштыру факты үзе дә беркайда да теркәлмәгән.

– Ә инде сезнең бабаларыгызның морза титулы булса, алар турында белешмәләр Санкт-Петербургтагы Үзәк дәүләт архивында сакланырга тиеш, – дим.

– Моннан берничә ел элек безгә бер кеше мөрәҗәгать итте һәм үз бабаларының кенәзләр булуын дәлилләтергә теләде. Эзләнү барышында без аның, беренчедән, чыннан да татар морзалары Янбулатовлар нәселеннән булуын ачыкладык, алар әлеге титулны XVI гасырның икенче яртысында ук алган. Икенчедән, аның туган авылындагы (Менделеевск районы Татар Кокшаны авылы) төп халык – рус-төрек сугышында катнашучы кенәз Рәхмәтулла Янбулатовның варислары яки туганнары булып чыкты, – дип сөйли архивчы.

МУЛЛА ЭЗЛӘП...

Аның турында мәгълүмат табарга ниятләгән бабагыз 1919 елдан соң туган яки теркәлгән икән, монысы чагыштырмача җиңел эш: сезгә ЗАГСка барырга кирәк. Мәгълүмат алыр өчен туганлыгыгызны раслый торган белешмә бирү җитә. Революциягә кадәр исә халыкны «исәптә» тотуның төп ысуллары булып чиркәү һәм мәчетләрнең метрика кенәгәләре, православие динендәгеләрнең чиркәүгә тәүбәгә йөрү исемлекләре, бай гаиләләрнең исемлекләре саналган. Һәм, ниһаять, «Ревизия язмалары»нда (1720 елдан 1859 елга кадәр вакытны эченә алган 10 том) – салым түләүчеләрнең исемлегендә һәркемнең исеме, яше, милләте, һөнәре һәм яшәү урыны күрсәтелгән. Әлеге документларның барысы да конкрет бер урындагы, конкрет бер вакыттагы кешеләрне исәпкә алган. Ягъни күченү очраклары, исем алыштыру очрагы аларда берничек тә чагылдырылмаган.

– Татарстанның бер танылган архивчысы озак еллар буе Габдулла Тукай шәҗәрәсен өйрәнгән. Тик Габдулла туган Кушлавыч авылы метрикаларында ул шагыйрьнең әти-әнисенең тууы һәм никахлашуы турында белешмә тапмаган. Аның әтисен Кушлавычка мулла итеп билгеләгәннәр дә, ул анда икенче авылдан күченгән икән бит. Шунлыктан шагыйрьнең бүгенге шәҗәрәсенә берникадәр үзгәрешләр керергә мөмкин, – ди Ленар Мифтахов.

Барлык сакланган документлар да федераль һәм төбәк архивларында ята. Татарстан Республикасы Милли архивы бу җәһәттән иң байлардан берсе. Әмма шатланырга иртә әле: әгәр сезнең бабаларыгыз элек Вятка (Нократ), Уфа, Сембер һәм башка губерналарга караган территориядә яшәгән икән, документларны Уфа, Киров, Ульяновск һ.б. җирләрдән эзләргә кирәк. Мөселман гаиләләре буенча мәгълүматны Оренбургта та-



быт була, чөнки революциягә кадәр Диния нәзарәте шунда урнашканга, Казан губернасы территориясендәге бөтен мәчетләрдә тутырылган метрикаларның икенче данәсен шунда җибәргәннәр. Православие рухани консисториясе Казанда урнашкан була, шунлыктан 1724 елдан 1929 елга кадәрге арада православие динендәгеләрнең җирле тормышына бәйле документларны ТР Милли архивында табарга мөмкин.

ТЫРЫШКАН – ТАБАР

Ихтимал, сезнең бабагыз нинди дә булса җәмгыятькә файдалы эшкә яки, киресенчә, җәмгыятькә каршы эшчәнлеккә мөнәсәбәтле документларда телгә алынгандыр. Мәсәлән, татарстанлы Евгений Степанищев «Описи архива Разрядного приказа XVII века» җыентыгында мондый язма тапкан: «Судное дело осколенина (жителя Старого Оскола – **ред.**)

Мирона Кандаурова что искал на осколенине ж на Кондратье Розщупкине по двум челобитным своево бою, да жены своей бесчестья, да грабежу десяти рублёв, да смертного убийства брата своего; а Григорий Розщупкин искал на нем Мироне встрешно бою своего и безчестья жены своей да помореной скотины лошеди и коров и всякой животины на сорок пять рублев. Дело не решено». Үзенең нәсел агачына мөмкин кадәр күбрәк туганнарын кертүне максат итеп куеп, ул менә шушы 1629 елда язылганнарга кадәр килеп җиткән. Хәзер аның шәҗәрәсендә 3 мең кеше теркәлгән. Эзләнү барышында Евгений борынгы бабалары турында күп мәгълүмат туплаган. Ул чактагы кардәшләренең һәр-

кайсына туганлык хисе тоймаса да, хәзер Евгений шул катламнан чыгуын яхшы белә, һәм алар белән ниндидер якынлык сизә.

– Архивта эшләү – йөзләрчә еллык бик күп кульязманы берәмтекләп карап чыгу ул, әлеге документлар буенча бернинди «эзләгеч» тә юк. Үз гаиләмнең тарихын өйрәнгәндә, мин Казандагы гына түгел, бәлки Бөгелмә, Самара, Курск, Мәскәүдәге архивлар белән дә эшләдем. Мондый география күп вакыт таләп итә. Шунлыктан кайчак түләү файдалырак – тикшеренүнең һәм тикшеренүченең ни дәрәҗәдә үз эшенең остасы булуына бәйле рәвештә берничә йөз сумнан алып дистәләрчә мең сумга кадәр җитәргә мөмкин, – дип сөйли Евгений. – Мәсәлән, Татарстан Милли архивы электрон почта аша җавап бирә, бу арзанга төшә, әмма озакка сузыла. Борынгы актлар Россия дәүләт архивында бер-ике мең сумга берникадәр мәгълүмат табып бирергә әзер тикшеренүчеләр бар. Әмма ерактагыларына (мәсәлән, Бөгелмә шәһәре архивына) барырга кирәк, юл өчен дә заказчы түли. Электрон архивлар булган җирдә мин үзем эзләнәм – электрон эшләрне соратып алам да, үз компьютерымда бит артыннан битне карап утырам, кайчагында бер кичтә берничә мең бит актарырга туры килә.

Татарстан Милли архивы бик күп мәгълүматны, шул исәптән «Ревизия язмалары»ның 10 томыннан 3 томын цифрлаштырган. Бердәнбер минус – электрон күчермәләрне архивның уку залында гына карарга мөмкин (керү бушлай, укучы билеты буенча), һәм мәгълүмат цифрага текст сыйфатында түгел, рәсем рәвешендә күчерелгән. Ягъни бер-бер артлы бөтенесен рәттән карап чыгарга туры киләчәк. Архив буенча «Татарстан Республикасы бердәм архив мәгълүмати системасы» онлайн-эзләү хезмәте эшли (хәзер сайт реконструкцияләнә һәм «гостевой вход» буенча керергә кирәк). Әгәр эзләү графасына кеше яки торак пункт исемен кертсәң, система әлеге сүзләр кергән бөтен документны күрсәтәчәк. Документлар үзләре йә архивның Солдатская урамындагы төп бинасында, йә 8 Март урамындагы бинада саклана.

Андрей Тузиков,
социология фәннәре докторы:

– Без җәмгыять «глобаль кешелек оясына» («человейник» – фәлсәфәче Александр Зиновьев антиутопиясендәге термин – **ред.**) әйләнергә инде шактый якынлашкан чорда яшибез. Моның нәтиҗәләре: мәдәниятләр төрлелеге арасында чикләр җуелу, кешенең бөтен рольләренең бердәнбере – глобаль икътисадны кулланучы роленә алышынуы. Әлеге контекстта шәҗәрә төзү – үзеңнең асылыңны саклау коралы, яңа социаль-икътисадый тенденцияләр диңгезендә үзенә күрә бер якорь ул. Сүз уңаеннан, СССР заманында тормышка ашырылган уңышлы проектларның күпчелегенең нигезендә күпмилләтлелек яткан. Бу бүген дә Россиянең халык буларак тотрыклылыгы факторларыннан берсе.

Дмитрий Люлин,
медицина психологы:

– Туу һәм үлү даталарын, авыруларны, гаилә тормышын үзгәрткән драматик вакыйгаларны кертеп генограмма, ягъни нәселнең график сурәтен төзү – психотерапия коралы. Ул гаиләдә кабатлана торган закончалыкларны билгеләргә, нәселдән күчә торган авыруларны, мөнәсәбәтләрнең тискәре моделен, әтиәниләре тормышыннан балалар үзләренекенә күчереп ала торган кодларны ачыкларга булыша. Без хәзер гаилә кризисы кичерәбез. Бу бигрәк тә балаларда күренә. Үсмерләр үзләреннән зәгыйфьрәкләрне кыйнап, шуны төшергән роликларны социаль челтәргә куя икән, бу, беренче чиратта, җәмгыятьнең психологик халәтен күрсәтә. Күзгә күренеп торганыннан тыш, әлеге процесста яшерен куркыныч та бар: гаиләсенә бәйләнмәгән, үз тамырларын белмәгән кешенең үзе яшәгән тирәлек белән эмоциональ бәйләнеше дә юк. Мондый кеше белән идарә итүе җиңел. Мондый кешегә теләсә нинди күрсәтмәләрне сеңдерүе җиңел. Милләт, халык масштабында бу бик җитди проблемага әйләнергә мөмкин.

БЕЗ – КЕМНЕҢ КАРАЛАМАСЫ?

2018 елның Россия киноиндустриясендәге иң көтелгән премьералары рәтендә Сергей Мокрицкийның «Черновик» лентасы еш искә алынды. Һәм менә күпләр зарыгып көткән фильм, ниһаять, прокатка чыкты да тәнкыйтьчеләр белән тамашачылар лагерен икегә бүлде, кайнар бәхәсләр кубарды.

АПГРЕЙД КИРӘКМЕ?

Соңгы араларда даими тенденциягә әйләнгән апгрейд, хайпка йөз тоту баштарак аптырашта калдырды. Экраннарга нинди генә проект (ә без хәзер сериалларны да, фильмнарны да, хәтта 3–4 минутлык клипларны да, олыдан кубып, шулай атыйбыз) чыкмасын, аны һичшиксез заманчалаштыру, кайсы да булса мәгълүмати сәбәпкә яраштыру безнең заманның бер чиренә әверелде, дисәк тә буладыр. Ни өчендер, без шулай иткән очракта «кәттәрәк», кызыклырак, үзенчәлеклерәк, дип уйлыйбыз. Әмма тышчасы матуррак, чуаррак булып әверелгән саен, тирәнлек югалып, фрагментарлык, «клип фикерләве» дә өскәрәк калкып чыга бара. Лукьяненко әсәре буенча браузерда уенның да булуы (ә бу үзе эре бер платформа һәм аны кулланучылар гаять күп) фильмда тирәнлекне, күп планлыкны саклауны күздә тота иде, билгеле. Әмма «Черновик»ны төшерүче команда аны артык авырлаштырмауны, тармакландырмауны нигез итеп алган булып чыкты. Минем карашка – моның белән отмады, ә оттырды.

Әмма режиссер тәкъдим иткән продукт, аңа карап, сыйфатсыз һәм очсыз, дип әйтеп булмый. Бик күп нюанслары белән минуска китсә дә, мин бу премьераны уңай кабул иттем, апгрейд ысулларының кайберләре белән «афәрин!» дип килештем дә. Режиссер өчен Лукьяненко әсәренең чын мәгънәсендә «каралама», этәргеч материал гына булуын тойгангадыр, бәлки. Әйдәгез, «Лукьяненко әсәре мотивлары буенча» төшерелгән «Черновик»ка иркенләбрәк тукталып үтик әле.

Лукьяненко романы нәкъ менә автор тудырган дөньяларның ассоциатив эчтәлеге, интертекстуальлеге, Россиянең интеллектуаль катлам укучысына таныш булуы белән кызыклы иде. Ул үз чорындагы күпсанлы продуктлар, күренешләр белән көнкүреш элементларын да текстура нигезенә алганга, нуленче елларның визит карточкасы буларак кабул ителә алуы белән дә уникаль булды. Фильмда, ни кызганыч, тулы ике пластны – нуленче елларның тарихи-көнкүреш яссылыгын һәм Лукьяненко тудырган «Черновик» галәмен (картографиясен) уратып диярлек узганнар. Беренчесе очрагында аны гомумән төшереп калдырып, бүгенге көннең чынбарлыгы белән алыштырсалар (әйтик, Инстаграм белән Яндекс-такси хезмәте фильмга яхшы гына спонсорлык иткән, дигән тәэсир калды), икенчесендә режиссер, нигездә, бүгенгегә аваздаш һәм хәзерге ноктада резонанс тудыра алырдай гына дөньяларга мөрәҗәгать итә. Әмма «Черновик» романы Җилпәзә (Веер) буенча билгеле бер тәртиптә урнашкан дөньяларының төрлелеге, чуар колориты белән кызыклы: Земля-1, Аркан (киләчәк дөньясы, башка дөньяларны полигон буларак куллана чы), Земля-2, Демос (безнең дөнья), Земля-3, Вероз (XIX гасырда калган, фәнни прогресс кичермәгән, әмма фаунасына зыян килмәгән дөнья, ул атаклы Кимгим, мөселманнар тупланган Орысолтан, Зархтан кебек шәһәрләре белән билгеле), Земля-4, Антик (колбиләүчелек режимы хөкем сөргән, төзелеше белән антик дәүләтләрне хәтерләткән дөнья), Земля-17, Заповедник (Җилпәзә системасында экологик курорт буларак кулланыла), Земля-22, Нирвана (әсирләрне, ирексезләрне урнаштыру ноктасы, гөмбәләр үсеше нәтиҗәсендә, наркотик эффект таралып, мутацияләр активлашу урыны), Земля-46, Билгесез дөнья (бу дөньяга әле функционалларның чыкканы юк, әйтүләренчә, ул технократик яктан да, рухи яктан да хәтта Арканны ук күптән узып киткән) h.б.

Фильмны караганнан соң, тулаем күмелеп, Лукьяненко әсәрен тәмләп укып чыгарга киңәш итәр идем. Ул тудырган дөньялар тулы бер тарихи-иҗтимагый процессны күздә тота, һәм Россиянең социаль барышына да анализ буларак кабул ителә ала. Әсәрендә Лукьяненко каһарманы Кириллны, геймдизайнер карьерасына бәйләп, романга уен элементы да өстәп җибәрә. Әсәрнең пафосы тоелырлык рәвештә җиңеләя төшә, ләкин шуңа бәйле рәвештә, эчтәлеге тагын да драматик, киеренкерәк төсмер ала.

Автор:
Луиза Янсуар

– Сейчас поневоле происходит переустройство. Люди и государства пытаются найти и новые цели, и новые подходы. Как в свое время коммунизм, социалистическая идея зашла в тупик, и развалился Советский Союз, так и сейчас в тупик зашла классическая капиталистическая идея. Не зря в свое время академик Сахаров, будучи человеком умным, без каких-либо "закидонов", настойчиво говорил, что нужен симбиоз идеологий, нужно искать возможность построения нового общества, которое возьмет сильные стороны обеих систем и уберет их недостатки. Этим сейчас мир и занимается. Есть те, кто пытается найти новую-скажу таким канцелярским, политическим языком – "новую парадигму" развития цивилизации, а есть те, кто пытается цепляться за уходящий порядок, потому что им при нем комфортно. Если человечество найдет, как жить по-новому, тогда угаснут и религиозные, и прочие войны.

(Сергей Лукьяненко белән әңгәмәдән)



КӨТЕП АЛЫНГАН ЭКРАНИЗАЦИЯ

Сергей Лукьяненко фильмографиясе белән лаеклы рәвештә горурлана алырлык автор. Башлыча, язучы Россия тамашачысына «Дозорлар» сериясе буенча яхшы таныш. Танылган фантастның китапларын кулына алып карамаучылар да Тимур Бекмамбетов төшереп экраннарга чыгарган, Константин Хабенский һәм башка кино һәм шоу-бизнес йолдызлары популяр иткән фильм-дилогияне – «Ночной дозор» (2004), «Дневной дозор» (2005) – карамый калмагандыр.

«Черновик» – Сергей Лукьяненконың күпчелек әдәбият сөючеләр һәм әдәбият белгечләре тарафыннан «Дозорлар» сериясенә караганда югарырак бәяләнүче әсәре. Дөрес, ул шул ук парадигманы дәвам итә: биредә Башкалар, Яктылар белән Караңгылар урынына – функционаллар, кураторлар, ә Хабенский образында – һәркем яратып өлгергән Антон Городецкийга алмашка килгән, Данила Козловский типажын (ә ул типажны, беләбез, Россия тамашачысы ярата!) дәвам итүче Никита Волков. Югарыда әйткәнебезчә, фильм белән ул нигезләнгән адаптацияләнгән сценарий арасында тигезлек билгесе куярга ярамый да, кирәкми дә.

Эчтәлеккә килгәндә, сүз 2005 елдагы Мәскәүдә килеп чыккан вакыйгалар турында бара. Кирилл исемле каһарманны көннәрдән бер көнне тормышыннан «сызып ташлыйлар»: фатиры да, анда яшәүче эте дә башка кешенеке булып чыга, аның әлеге адрес буенча пропискада түгел икәнлеге ачыклана, Кирилл белән бергә эшләүчеләр, хәтта сөйгәне белән дусты, әти-әнисе дә, егетне исләренә төшерә алмый. Кирилл инде тәмам шашар хәлгә килгән мәлдә аның мобиль телефонына шалтыратталар һәм инструкцияләр бирәләр. Шулай итеп, ул Мәскәү-3 станциясе янәшәсендәге су башнясына килеп эләгә. Әлеге башня, баксаң, дөньялар арасындагы пункт икән, ә Кирилл исә, миссиясе буенча, таможенник, бихисап параллель дөньяларга ишекләр ачарга сәләтле функционал. Һәм мондый функционаллар да... бер ул гына түгел.

Дмитрий исемле сәясәтче Кириллга инде менә ярты гасыр буена бер генә функционал да ача алмаган Аркан турында сөйли. Фаразлар буенча, ул безнең дөньябыздан 35 елга алга киткән дөнья, нәкъ менә Аркан башка дөньяларның көйләнешен җайлап тора, нәкъ менә Аркан өчен без – каралама... Әмма Кирилл Арканга ишек ачканнан соң, анда бары тик 1971 ел гына булуы ачыклана, ә башка дөньяларга полигон булып бөтенләй икенчесе хезмәт итә. Һәм менә акрынлап Кирилл ачылмаган дөньяларның асылында ни ятканын аңларга тырыша башлый. Без барыбыз да – эксперимент полигоннары гынамы? Бу Җилпәзәнең нигезен ни тәшкил итә? Кем монда – төп кагыйдәләрне булдыручы? Әлеге сораулар аның миен бораулый башлаган көннән ул инде үз миссиясенә тугры функционаллар рәтендә генә кала алмый, алар белән дә, системаның үзе белән дә котылгысыз конфронтациягә керә. Җәмгыятьнең җайсыз кешесенә әверелә...

БЕЗ БУ ДӨНЬЯНЫ ТАНЫЙБЫЗ БИТ..!

Лентаны совет системасын каралтып күрсәтүе, монархиягә йөз тотуны чагылдырган элементларга бай булуы өчен пыр тузып сүктеләр. Әмма, ни өчендер, бу «өске катлам»да гына тукталып та калдылар. Минем үземә фильмның кычкырып торган заманыбыз чагылышы булуы, режиссерның детальләр сайлауда, укылышны билгеләүдә гаять кыю адымга баруы ошады. Үлем коралы булган трансформер-матрешкалар – бу деталь генә дә аны икенче разрядлы «проходной» картиналар исемлегеннән алып чыга һәм игътибарга лаеклы эксперимент буларак бәяләргә мөмкинлек бирә. Дөресен генә әйткәндә, аны шушы рәвешле – цензурасыз, купюраларсыз (ә бит безнең мәмләкәттә хәзер янәдән шуңа таба йөз тоталар) – прокатка чыгаруларына минем исем китте. Бу хакта Кинопоиск сайтындагы бәяләмәләрдә дә искә алучылар шактый булды. Һәм, әйтергә кирәк, нәкъ менә шул элементлар минем әсәр/фильм төшенчәләренә караш ноктамны тәгаенләп куючы булды да.

«Черновик», асылда, бөтенләе белән монархик карашларны алга сөрми, киресенчә, ул, система-корылыш буларак монархиянең (совет чоры булсынмы, патша Россиясеме, әллә хәзерге көннәрме) безнең локализация, менталитет өчен беркайчан да үзгәрми торган кодировка икәнлеге турында сөйли. Урыны-урыны белән – тәнкыйтьләп, урыны-урыны белән – көлемсерәп. Без шушылай яшәдек, яшибез һәм, мөгаен, яшәрбез дә инде – «каралама» булудан туктамас безнең тормыш, дигән идеяне сала фильмның «эчке катлам»ына аны тудыручылар. Белмим, кемгә картинаны мәгънәсез буш куык буларак кына билгеләү кирәк булгандыр, әмма нәкъ менә социаль яңгырашы, эчтәлек, мессенджы ягыннан ул – бик тә вакытлы һәм актуаль. 400 биттән 100 биткә калган сценарийда романның социаль төеннәренә басым ясаганнар, моны режиссер, миңа калса, махсус эшләгән. Функционаллар белән идарә итүче элита (хакимият) кешеләре арасындагы бер затны сәясәтче Ирина Хакаманың уйнавы да кызыклы алым. Беренче карашка, бу үзенә күрә бер хайп, уен элементы кебегрәк кабул ителә, әмма аннары, органик рәвештә, мәгънәләр катламын тулыландыра, интертекстуаль пазлга әверелә.

Романдагы дөньялар картасындагыча, фильмда да без Земля-2 вазыйфасын үтибез. (Әйткәнебезчә, Лукьяненко искә алган дөньялар «Черновик» фанатлары тарафыннан инде бик күптәннән картага күчерелгән, җентекләп классифи-

«Черновик»ны Россия прокатының быелгы «иң зур провалы» дип атадылар. Югыйсә, Лукьяненко үзе Сергей Мокрицкий прокатка чыгарган фильмга бик лояль мөнәсәбәт белдерде. Анда хәтта кечкенә генә эпизодик роль дә башкарды – Кириллга метрода ярдәм күрсәтүче очраклы бер узгынны уйнады ул. Лента прокаттагы беренче өч атнада 145 миллион (2,3 миллион доллар) җыйды, шуларның 141,6 миллионы – Россиядә, 3,8 миллионы – БДБ илләрендә. Бу фильмның төшерү бюджетына сарыф ителгән акчаны – 200 миллионны кайтармады да хәтта. Кайсыбер аналитиклар фикеренчә, «Черновик» – кискен бәяләмә, рецензияләргә бәйле рәвештә килеп чыккан касса провалы. Россия матбугатында аны бик көчле тәнкыйтьләделәр чөнки. Бигрәк тә «Российская газета» басмасының күзәтүчесе фильмны беренче көннәрдә үк кара тамга белән мөһерләде: «Черновик» арзанлы бер ясалма әйбер кебегрәк тоела, аны күз яшеннән башка карау мөмкин түгел».

кацияләнгән). Биредә шулай ук безнең дөньяны, икенче төрле итеп, аныклап, Демос дип атап йөртәләр. Демократия сәяси системасы өстенлек иткәнгә, билгеле. Әмма бу демократиянең ни дәрәҗәдә демократия булуын… тора-бара күрәбез. Лукьяненко бер әңгәмәсендә болай дигән иде: «Безнең, фантастларның, сәяси система, тарихи барыш турында кинаяләп әйтү мөмкинлегебез бар». Бу очракта режиссер Мокрицкий кинаясе дә – аермачык, өстә үк ярылып ята.

Апокалипсистан соңгы ГУЛАГ рәвешен алган Нирвана да, элитар төен дип исәпләнгән Аркан да – бары тик безнең инде аңыбызга сеңдерелгән идарә итү формаларын гына кабатлый булып чыга ахыр чиктә. (Режиссер, шул рәвешле, дөньялар түгел, ә без тудырган иллюзияләр генә күптөрле, дигән фикергә дә ишарәли). Кирилл ачкан Аркан исә гомумән Россия медиапространствосы актив спекуляцияли торган тагын бер мифологеманы күз алдыбызга китереп бастыра – безне кытайлар яулап алачак та, тоталитар режим кире кайтачак икән. «Черновик» моны, Тарковскийның «Сталкеры» (Стругацкийлар әсәренә нигезләнгән булуын онытмыйк!) рухындагы стилизациягә йөз тотыбрак, Зона форматында күрсәтә. Әнә, Арканның ялтыравык чынбарлыгын, технократик корылышын тотып торучы субайлар, диварлар эчен ә нәҗес тутырылган. (Алар берьюлы Берлин стенасына да, «тимер пәрдә»гә дә сылтама буларак кабул ителә ала). Әнә, роман буенча «Нирвана» дип аталучы Земля-22 дөньясына алып чыккан хәрәбәләр арасында мутация кичергән алагаем зур балтырганнар үсеп утыра – алар атмосферага психоделик матдәләр тарата. Ә шуны сулаган кешеләр (сүз уңаеннан, алар бирегә башка дөньялардан репрессияләнгән) өр-яңадан урак белән чүкечкә ант китереп, кызыл комач япкан трибуна-мөнбәргә менгереп бастырган теләсә кемгә иман китерергә әзер.

Аркан һавасын кистереп очкан матрешкалар (Matryoshka Killer) берара безнең хәзерге күгебездә тыныч, имин генә очып йөргән Яндекс спутникларын, навигаторларын хәтерләтеп ала. Әмма Кирилл, кызганычка каршы, җәмгыятькә уңайлы персонаж түгел, шуңа да матрешкалар котылгысыз рәвештә, үзләре дә сизмәстән, үлем коралына әйләнергә мәҗбүрләр. Алар ярдәмендә «империяләрнең» эчке генә түгел, ә тышкы сәясәте турында да сөйләмиме Мокрицкий?

Ә инде актерларга килгәндә… Никита Волковның уенында тирәнлек җитеп бетмәде, ул әле яхшырак та уйный аладыр, дигән тәэсир калды. Ләкин фильмны «тартып чыгарды», анысы бәхәссез. Аның сөйгәне Аннаны уйнаган Ольга Боровская да ясалмарак иде, ул, каһарман буларак та, әллә ни симпатия уята алмады, киресенчә, әсәрдәге героиннядан аермалы буларак, мәхәббәтендә шикләнерлек тәэсир калдырды. «Черновик»тан соң бу парны тамашачы үз итәчәк», – дигән иде режиссер, әмма бу – шикле инану. Асылда, мәхәббәт өчпочмагы монда тиешле психологик концентрациясендә ачылмый, бәлки, бу режиссерның игътибары башкага юнәлтелгән булу белән аңлатыладыр. Әллә безнең чор эчкерсез, ихлас мәхәббәткә ышандыра алырдай әсәрләр, кинолар өчен түгелме икән?

ГАЛӘМНӘР ЧИКСЕЗЛЕГЕНДӘ

Ә менә саундтреклар мәсьәләсенә һәм яшь композитор Кирилл Рихтерның «Черновик» өчен махсус иҗат иткән музыкасына килгәндә, «афәрин!» диясе килә. Рихтер тудырган атмосфера шәхсән миндә бик яхшы тәэсир калдырды. Мокрицкийның Россия тамашачысы өчен укылышы һәм яңгырашы таныш булган трекларга мөрәҗәгать итүен дә хуплап кабул иттем. Бу җәһәттән үз замынында «Дозорлар» да популяр иделәр – Бекмамбетов картиналарын Uma2rman (Уматурман) төркеме белән компиляциядән тыш күз алдына китереп булмый. Мокрицкий да әлеге эффектка ставка ясаган, күрәмсең. Мәхәббәт линиясен ягымлырак итәр өчен (гәрчә җыр, фильмдагы линиягә ярашмыйча, һавада гына эленеп калса да) ул, әйтик, Леонид Агутин белән Анежелика Варумның «Я буду всегда с тобой» дигән популяр дуэтын куллана. Ә социаль эчтәлекне ачканда, нәкъ менә нуленчеләргә таба борылыш ясап, Noize Mc иҗатына мөрәҗәгать итә.

Лукьяненко иҗатын яраткан тулы бер буын өчен идол булган (үзенең сәяси активлыгы, Россиянең тышкы сәясәтенә карата тискәре актив гражданлык позициясе белән аерылып торган) рэперның «Вселенная бесконечна» композициясенең мессенджы, фильмны караганда, искиткеч органик эффект тудыра. Җитмәсә, күптәннән таныш булуы, күңелгә якын булуы белән дә – ота. Кинотеатрда минем яшьтәгерәк тамашачы кушылып җырлап утырды:

Если Вселенная бесконечна действительно,
Значит, есть куча копий нашей планеты,
Где-то сейчас происходят те же события,
Копия меня пишет копию песни этой.
Если Вселенная бесконечна и вправду,
То прямо следует из этого факта,
Что ты точно так же ждешь, когда я вернусь обратно,
Где-то там в глуби далеких галактик,
То есть не ты, конечно, а твоя копия,
И не меня, а мою копию, конечно,
Если, конечно, все это не утопия,
И Вселенная действительно бесконечна.

Бог – одинокий ребенок,
Брошенный всеми в пустом магазине игрушек,
Бродя среди полок, убивающий время,
Понимая, что взрослым не нужен,
Он собрал уже тысячи конструкторов разных,
Он распечатал всех кукол,
Но он все еще ищет детали для пазлов,
Он все еще ходит по кругу…

P.S. Россия кинопрокатына чыккан картиналарның күбесенә безнең үзебезнең артык көчле тәнкыйди караштa булуыбыз да күп нәрсәне хәл итә. Мин никтер Гильермо дель Тороның «Форма воды»сы белән чагыштырып утырдым. «Черновик» – үзенчәлекле һәм укылышы ягыннан шактый тәэсирле уен фильмы. Әсәр буларак аның кыйммәте икеләтә көчлерәк, билгеле. Әмма фильмны да, аерым бер продукт буларак, исемлектән сызып атмаска киңәш итәм. Карарга. Һәм уйланырга.

ДӨНЬЯ ЙӨГЕН ТАРТКАН ӘМИНӘ

Көчле рухлы, иманлы, бик сөйкемле әбиләр була. Без аларны акъәбиләр дип йөртәбез. Шундыйларның берсе Апас районының Биеш авылында яши. Ун яшеннән асрамага бирелеп, өч класс белем белән калуына карамастан, үз чорының «бизнесмены» була ул. Сугыш чорында гаиләсен ачлыктан коткарып кала.

Автор:
Руфия Фазылова

«АСРАМАГА БИРӘМ...»

Әминә апа Камалиева белән Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылына баргач таныштым. Олы кызы Кадриядә кунакта иде ул. Туксан бер яшендәге әбинең зиһене дә, сәламәтлеге дә, ә иң мөһиме – изге күңеле сокландырды. Гаҗәп: шулкадәр михнәт күреп тә, шаянлыгын югалтмас, көр күңеленә тап төшермәс икән кеше.

Әминә апага бик яшьли – 10 яшеннән тормыш арбасын тартырга туры килә. Ләкин ул зарланмый. «Аллаһы Тәгалә шулай кушкан, язмыш», – дип, сабыр гына елмая:

– Без Яшел Үзән районының Мамадыш авылында яшәдек. Әтиебез 1932 елда вафат булды. Ул исән булса, бәлки бу кадәр михнәт тә күрмәгән булыр идек. Әтидән дүрт бала калдык. Миңа биш яшь тә тулмаган иде. Тормыш бик авыр. Яңа власть килгәч, дөньялар тиз генә тотрыкланмады бит. Колхозда бушка эшлисең, җирең дә, атың да, сыерың да юк. Көчкә авыл мәктәбендә өч класс тәмамладым. Әни бик укымышлы иде, өйдә дә безнең белән шөгыльләнде. Шулай итеп укуда шактый тиз алдырдым, яшьтәшләремә караганда әйбәтрәк укый идем.

Кечкенә Әминәгә укытучысы сабакны ташламаска кушса да, кыз бүтән мәктәпкә бармый. Туган авылын ташлап, Норлатка – туганнарына китә ул.

– Һич онытмыйм, – ди Әминә апа. – Җәй уртасы иде. Әни алдына утыртты: «Кызым, әйдә, җыен. Норлатка алып китәләр сине. Туган апаңнарда яшәрсең. Бер яшьлек кызларын карарга кеше кирәк икән. Тамагың тук, өстең бөтен булыр. Миңа рәнҗемә, кызым. Шулай яхшырак булачак...

Куркып кына:

– Әни, мин аннан соң яңадан өйгә кайтаммы соң? – дим.

Әни кочып алды:

– И, кайтасың, кызым, кайтмый ни. Әле яхшы тормышны күргәч, безнең белән яшисең дә килмәс.

Шулай итеп кечкенә Әминә бер ел туганнарында яши. 1939 елның җәендә туган авылы Мамадышка кайта. Өс-башы яңарган, битләре алсуланган...

– Туганнар миңа карата хәерхаһлы булды, – ди Әминә апа. – Кечкенәдән тырыш идем. Бала йоклаган арада хуҗалар кайтканчы идәннәрне юып, ризык әзерләп куям. Әллә шуның өчен дә яраттылар.

Көзен үсмер кызны янә Норлатка алып китәләр. Тик бу юлы ул туганнарында җәйгә кадәр яшәми.

– Кисәк кенә туган апа үлеп китте, – ди Әминә апа. – Туган абый мине кире авылга кайтарды. Һәм 1940 елның җәендә гел басуда эшләдем. Һәр йортка җир бүленгән бит, эшләргә кирәк. Ә әнигә басуга чыгарга ярамый иде – эсседә аның кан басымы күтәрелә. Ул абый белән мин эштән кайткан вакытка ашарга әзерләп торды.

СУГЫШ ЭЗЛӘП – АВЫЛ БАШЫНА!

Бөек Ватан сугышы башланганда Әминә апага ундүрт яшь була. Ел әйләнәсе колхоз эшендә булган үсмер кыз, шул көннән башлап кисәк олыгая.

– 16 июньдә Рәхим абыйны армиягә озаттык, – ди Әминә апа. – 22се сугыш башланды. Әле дә истә: иртән әни йөгереп кергән. «Балалар, торыгыз, сугыш башланган бит, – ди. Без, аны-моны белештерми, урамга атылып чыктык. Ату тавышлары ишетелми, тирә-як тып-тыныч. «Кайда сугышалар икән?» – дибез. Күрше балалары белән авыл башына йөгердек: сугыш карарга! Анда да берәү дә атышмый. Сугыш күргән балалар түгел бит. Нәрсә, ничек булганын да аңламыйбыз. Аннан төшендек инде...

Сугышның чын йөзен Мамадыш балалары тиз күрә: бер-бер артлы авылның әзмәвердәй егетләре, ир-атлары фронтка китә. Эшләргә техника, атлар калмый.

– Авылда карап торган ике трактор бар иде, – дип, истәлекләре белән уртаклашты Әминә апа. – Берсе – Галимҗан абыйда, икенчесе Вәли абыйда. Аларны сугышның беренче көннәрендә үк техникалары белән фронтка озаттык. Аннан колхозның яхшы атларын да алдылар. 1941 елның көзе бик яңгырлы килде. Басуларда игенне дә җыеп алып бетереп булмады. Уңыш мул, эшләргә кеше юк, туктаусыз яңгыр коя. Шуңа 1941 елның кышын бик авыр кичердек. Иген булмау бер хәл, бәрәңге дә нык череде. Аны кайбер кешеләр бакчадан алып та тормады. Без исә казып булса да чыктык: бәрәңге төбе белән черек иде. «Казып азапланмагыз да», – дигән иде әни, тик минем бакчаны алай калдырасым килмәде. «Өйдә өч кеше яши, шул бәрәңгеләрен дә алмаганнар диярләр», – дидем.

Авыл фронттан хат көткәндә, Әминә апа да, башкалар шикелле үк, көн саен абыйсыннан хат көтә. Хатлар килә тора. Рәхим абыйсы, яраланып, ике тапкыр госпитальдә ята. Туган авылына ул 1945 елның ноябрь аенда кайта. Һәм, иң беренче эш итеп, сеңлесе Әминәне кочаклап: «Әни белән энекәшне ачлыктан коткардың», – ди.

СӘҮДӘГӘРЛЕК

– Сугыш вакытында мин сәүдә эшенә керештем, – ди Әминә апа. – Авылда берничә үткен хатын-кыз бар иде. Алар Яльчик базарыннан иген алып кайтып сату белән шөгыльләнделәр. Ничектер мине дә үзләренең артиленә алдылар. Олы апаларга ияреп барам, бер пот игенне тартып кайтам. Кыш көне – чана, җәен арба белән йөрибез. Әни, җаныкаем, каршы алырга килә торган иде. Авылдан ерак түгел Бабай тавы бар, ул шул тауда мине көтеп тора да арбага утыртып алып төшә. «Кызым, аякларың ял итсен, сузып утыр», – ди торган иде. Авылга иген төяп кайтып керәсең – и рәхәт! Берлинны алган диярсең! Чөнки беләсең – ай буена җитәрлек ризык бар. Әни белән сөйләшә-сөйләшә тәмләп чәй эчәбез. «Кызым, син әллә нинди акыллы сүзләр сөйлисең, каян белеп бетерәсең», – ди ул миңа. «Күп йөргән таш шомара ул», – дим, сер бирмичә. Икенче көнне игенне Норлат базарына алып барасың. Яльчик базарында бер пот иген 800 сум торса, без 1200 сумнан сатабыз. Эшләгән акчага өйгә төяп ризык алып кайтасың. Әни башымнан сыйпап елый иде. Әле менә шуңа аптырыйм: ничек ул үткен апалар мине дә үзләренә иярттеләр икән? Күрәсең, кызганганнардыр. Әти дә юк, абый сугышта, өйдә авырый торган әни дә энем. Хәер, үзем дә җебегән түгел. Зурлардан калышмадым, йөгереп кенә йөрдем.

Сөйкемле сөягә булган кыз, товар поездына утырып, Казанга да йөри. Авылдан 300 тавык йомыркасы алып китә дә дә шәһәр базарында сата.

– 350 йомырка алсаң, күтәрергә авыр була иде, – ди Әминә апа. – Шуңа аерым бер нормасы бар. Казаннан кайтканда да кул буш булмый – түгәрәк клиндер, батон алам. Аны кыйммәткәрәк Норлат базарында сатам.

– Товар поездларына шулай утырта иделәрме? – дим Әминә апага.

– Утырталар. Гел йөргәч, танып бетерәләр. Товар поезды булса да, аның агач урындыклары бар иде.

Фото: Лилиана Вәлитова

Шунда менеп кунаклыйсың да кел-тер-келтер барасың. Поезддан төшкәндә машина йөртүче белән сөйләшәсең: «Станциягә җиткәндә акрынрак барыгыз әле». Ул исә үзенең киңәшен бирә: «Башта капчык белән ипиеңне ат, аннан үзең алга сикер. Артка сикерә күрмә, поезд астына төшәсең». Ул поезд йөртүчеләрнең дә рухларына дога кылам, бик мәрхәмәтле кешеләр булганнар.

Әминә апа, Казанда гел бер кибеттән батон ала торгач, кибетче белән дә дуслаша. Сатучы ханым үсмер кызга чәйләр эчертә, чиратсыз ипи бирә.

– Берсендә, миңа шул кибетче апа, авылга алып кайтып сатарга дип, зур кәгазь тартма белән шырпы бирде, – ди Әминә апа. – Шуны өйгә күтәреп кайттым. Әле бит бер капчык ипи дә бар. Кәгазь тартма өстенә капчыкны куйдым. Күтәрешергә кешеләр дә булышты инде. Икенче көнне Норлат базарына киттем. Шырпыны сатып бетереп кайттым. Аннан әле тагын теге дус кибетче бер зур тартма белән сабын да бирде, аны да саттым. Акчасын урталай бүлдек.

Менә шулай үсмер кызның үткенлеге, тырышлыгы аркасында, гаилә сугыш вакытында ачлыктан интекми.

«ХӘЗЕР ИРЛӘР БҮТӘН»

Әминә апа сугыштан соң колхоз эшендә эшли, урман кисә, торф чыгара.

– Торф чыгарырга Мәскәү янына кадәр бардык, – ди Әминә апа. – 1950 нче еллар. Тормышлар авыр. Ипилек булса да акча эшләргә кирәк. Нинди хезмәт бар, шуңа ризалашасың. Торф чыгарырга баргач, безне рус авылы клубына керттеләр. Салкын, ашарга пешерергә урын юк. Бригадир белән киңәшләштем дә мич чыгарырга булдым. Кызлар кирпеч биреп торды, мин өйдем. Мичне махсус ашарга пешерә торган итеп ясадым – чүлмәк куяр өчен тимер куеп калдырдым. Аннан кызлар белән аш пешереп рәхәтләндек инде.

– Ә мич чыгарырга каян өйрәндегез? – дим Әминә апага.

– Авылдагы миччеләрнең эшләгәнен карап торганым бар иде. Аның әллә ни авырлыгы юк инде...

Тырыш кыз кияүгә шактый соң – утыздан соң гына чыга. Әнисен ялгызы калдырып китәсе килми.

– Дөресен генә әйткәндә, ирем Рафаэльне яратып чыкмадым, – дип, сере белән уртаклашты Әминә апа. – Аларның гаиләләре шактый хәлле иде. Рафаэль яучы җибәргәч, балалар табарга кирәк, тормышлар да җайланмасмы дип ризалаштым. Бер-бер артлы – дүрт елга өч бала таптым. Ике кызым да, улым да сау-сәламәт, бик акыллы балалар булды, моның өчен иремә зур рәхмәтлемен.

Баксаң, Әминә апаның тормыш иптәше белән тормышы бик рәхәтләрдән булмаган икән. Дөрес, язмабызның герое ул турыда ачыктан-ачык сөйләми. Ә сүз арасында, бүгенге яшьләр белән чагыштырып кына, әйтеп куя:

– Хәзерге хатыннар бик бәхетле. Үзләре шуны аңлыймы икән, белмим дә. Әле беркөнне гаиләсе белән олы кызымның кызы Гөлназ кайткан иде. Өстәл артында утырабыз. Ике яшьлек уллары астын юешләткән. Оныгым иренә: «Баланың астын алыштыр әле», – ди. Ире, һич авырсынмыйча, урыныннан торды да, кечкенә малаен кулына күтәреп, икенче якка кереп китте. Безнең вакытта ирләр булсамы... Бер-бер артлы балалар тугач, йокы әлләкми иде. Ирем өч баланың берсен бер тапкыр юатып йоклатсын, астын алыштыру турында әйтмим дә. Төнлә бала уянгач, чеметеп уята торган иде. И, хәзер уйласаң, әллә ниләр искә төшә...

– Ә хәзерге ирләрнең шулай бала каравына ничек карыйсыз? – дим күпне күргән әбигә.

– Бик яхшы карыйм. Хатын-кызларга карата ихтирам, хөрмәт бар хәзер. Бала бит ананыкы гына түгел, ата кеше дә карашсын. Шулай күңеллерәк тә, тәмлерәк тә ул.

«НЕРВЫ – НИНДИ ЧИР УЛ?»

Әминә апа Камалиева бүген Биеш авылында улы Фирдүс, килене Фирдәүсә тәрбиясендә яши. Авылның остабикәсе ул. Аннан башка бер мәҗлес үтми, башка дини йолалар да узмый. Күпме өлкән кешеләр белән аралашып та, моның кадәр хәер-догалы, тәмле итеп сөйләшүчене күргәнем юк иде. Һәр җөмләсендә зур мәгънә ята, ул һәркемгә изге теләк тели.

– Соңгы бер-ике елда әниемнең йөрәге үзен сиздерә, – дип сөйләде әбинең олы кызы Кадрия апа. – Аңа кадәр дару эчкән кеше түгел иде. Мунча чабынып чыккач, кышын карга чыгып, тәнен ышкымаганга да әле өч-дүрт кенә ел. Аллага шөкер, әниебез нык булган. Ә анардагы сабырлык... Бүтән андый кеше юктыр. Нинди генә хәлдә дә бирешмәс, зарланмас. Еш кына бер очракны искә алып көлешәбез: әни янына күрше хатыны кергән. Чагыштырмача яшь әле ул. «Ай, Әминә апа, бик нервыланам, түзеп булмый», – ди икән. Әни, бик гаҗәпләнеп: «Ул нервы дигәне тагын нинди чир соң?» – дигән.

Әминә апа бердәнбер улын да үзе өйләндергән. Хәл болайрак булган. Яшел Үзәннең Танай авылында яшәгәндә, Апас районының Биеш авылында «Сельхозтезника» ачылган, эшчеләргә йорт та бирәләр, дигәч, ана кеше, берәүгә дә әйтмичә, шунда юнәлгән. Биеш кешеләре белән аралашып, «Сельхозтехника»га кереп чыккан. Улына урын белешкән шулай. Шуннан Танайга кайтып, Фирдүсен Биешкә җибәргән. «Белешеп кайт әле, эш булса, урнашып та кайт»,- дип. Шулай итеп Әминә апаның армиядән кайткан улы «Сельхозтехника»да эшли башлый. Яшь белгечкә йорт та бирәләр. «Ашарга пешереп торырга булса да ярармын», – дип, улы артыннан Әминә апа да килә. Шуннан ана кеше килен эзләү хәстәренә керешә: күз уңында олы кодагыеның кызы – Фирдәүсә бар. Акыллы, уңган кыз. «Фирдүс белән икесен ничек тә кушарга иде», – ди беркөн кодагыена ул. Кодагый исә каршы килми: «Үзләре ярашсалар...» – дип куя. Әминә апа җае чыккан саен улына Фирдәүсәне мактый. Әллә шул сүзләр килешә, әллә язмыш кушкан булып чыга, яшьләр кавыша. Әминә апа ялгышмый: килене Фирдәүсә дә ул уйлаганча сабыр да, тырыш та икән.

– Улым, киленем белән бергә егерме тугыз ел яшибез, Аллага шөкер, – ди Әминә апа. – Матур сүз өчен генә әйтмим, барысы да күреп тора: тату торабыз. Хәлемнән килгәнчә, әле дә йорт эшләрендә ярдәм итәм. Токмач та кисеп куям, камыр ризыгы да пешерәм. Авырып ятып, балаларны гына газапларга язмасын, Аллаһы Тәгаләдән бары шуны сорыйм...

Саубуллашыр алдыннан Әминә апа үзе бәйләгән йон башмак бүләк итте. Бер көнгә бер башмак бәйли икән. Аннан аларны балаларына, оныкларына тарата. Әбинең йөрәк җылысы, хәер-догасы кушылып бәйләнгән башмаклар барысын да җылытып, саклап тора. Шул исәптән хәзер – мине дә...

DOLINA ОТЕЧЕСТВЕННЫЕ СТАНКИ ПО МЕТАЛЛУ

СОВРЕМЕННОЕ
ВЫСОКОПРОИЗВОДИТЕЛЬНОЕ
ОБОРУДОВАНИЕ

ПАО «Кувандыкский завод кузнечно-прессового оборудования «Долина»
РФ, Оренбургская область, г. Кувандык, ул. Школьная, 5; Тел.: 8-800-333-81-63
E-mail: oaodolina@mail.ru, http:// www.ao-dolina.com

Реклама

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+

МАХСУС ПРОЕКТ

— 32нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Җәүдәт Фәйзрахманов,
Казан дәүләт аграр университеты ректоры, июнь аенда 70 яшьлеген билгеләп үтә.

Фотолар КДАУ тарафыннан бирелде

ТУГАН ҖИР АКАДЕМИГЫ

Казан дәүләт аграр университетында эшләү дәверендә ул бу уку йорты белән тәмам туганлашып бетә, тормышның төрле этапларында, alma materның үзе кебек үк, яңа һөнәр, яңа юнәлешләр үзләштереп, аның белән бергә «үсә». «Университеттагы хезмәтем, – ди КДАУ ректоры Җәүдәт Фәйзрахманов, – бар гомеремә сузылган озын юл ул: ассистенттан башлап, профессорлыкка, икътисад фәннәре докторы дәрәҗәсенә, ректорлыкка кадәр».



«СУКАДАН» ЧЫККАН ДОКТОР

Арча районы Носы авылында күп балалы крестьян гаиләсендә туган Җәүдәт Фәйзрахманов, иң өлкән ир бала буларак, олыларга булышыр өчен, биш яшьтән үк чыпта үрү станы артына баса. Крестьян хуҗалыгындагы бар эшләрне өйрәнә. 1966 елда Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, Арча районындагы «Беренче май» колхозында икътисадчы вазыйфасында рәсми хезмәт юлын башлый. Русча бер авыз сүз дә диярлек белмәгән малайга шәһәрдә укуы никадәр тырышлык таләп иткәнен чамаларга гына кала.

Ә инде ике елдан аның тормышына Казан авыл хуҗалыгы институты килеп керә. Икътисад факультетын һәм аспирантураны тәмамлап, Җәүдәт Фәйзрахманов 1978 елда «Яхшы үсештәге сөт терлекчелеге хуҗалыкларында рациональ азык базасын оештыру һәм планлаштыру мәсьәләләре» темасына кандидатлык диссертациясе яклый.

1977–1990 нчы елларда Җәүдәт Ибраһимович КАХИның икътисадый кибернетика кафедрасында ассистент, өлкән укытучы, доцент, мөдир вазыйфаларын башкара. Аннары алты ел дәвамында Казан дәүләт ветеринария академиясендә хезмәт куя: башта авыл хуҗалыгы икътисады һәм ветеринария эшен оештыру кафедрасы доценты, соңрак – авыл хуҗалыгында икътисад һәм маркетинг кафедрасы мөдире.

1991 елда Җәүдәт Фәйзрахманов К.А.Тимирязев исемендәге Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясендә терлекчелек һәм азык җитештерүдә икътисадый нәтиҗәлелекне күтәрү проблемаларына багышланган докторлык диссертациясен яклый, тиздән аңа профессор дәрәҗәсе бирелә.

Республика өчен катлаулы 1996 елда хөкүмәт Җәүдәт Ибраһимовичка моннан бер ел элек дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе итеп үзгәртелгән КАХИне җитәкләргә тәкъдим итәләр. 1996 елның августында ул бертавыштан ректор итеп сайлана.

Югары уку йортының финанс хәле бик катлаулы була – коммуналь хезмәтләр өчен генә дә ике миллиард сумнан артык бурыч җыела. Инкыйлабка кадәр үк төзелгән биналар аяныч хәлдә кала, йорт җиһазлары җитешми. Студентлар өчен тулай торак та – ярымҗимерек.

Яңа җитәкче коллективны вуз өчен яңа керем чыганаклары эзләүгә юнәлтә, һәм инде 2002 елда ук бюджеттан тыш акчалар хисабына укытучылар һәм хезмәткәрләрнең эш хакына саллы өстәмәләр түләү гамәлгә кертелә. Укытучылар өчен 1993 елда ук нигез салынган торак йорт төзелешен, өлешләп катнашу ысулын кулланып, төгәлләүгә ирешәләр. Студентлар тулай торагын һәм төп уку корпусын да төзекләндерәләр.

Шул ук вакытта ректор фән турында да онытмый: 2001 елда ул Россиянең күренекле галимнәре өчен РФА тарафыннан билгеләнгән дәүләт стипендиясенә лаек дип табыла.

Ректор үзе белдергәнчә, иң авыры коллективны бер йодрык итеп туплау була. Кемнедер «тәрбияләргә», хәтта эштән җибәрергә туры килә, ә кемдер, киресенчә, югарырак вазыйфага билгеләнә. Шул рәвешле нык, бердәм команда формалаша. 2002 елда Җәүдәт Фәйзрахмановның «Мәгариф сферасы» номинациясендә «Елның иң яхшы менеджеры» исеменә лаек булуы, ә 2005 елда «Ел ректоры» номинациясендә «Россиядә ел кешесе» милли премиясе лауреаты дип танылуы һич тә юкка түгел.

Ул җитәкчелек иткән еллар – вузның динамик үсеш, белем бирү эшчәнлеге тармагының киңәю, фәнни потенциалы үсеше һәм матди-техник базаның ныгуы чорына әйләнде. 2006 елда академия иң югары дәрәҗәне – университет статусын алды.

ШӘХСИ ҮРНӘК МИСАЛЫНДА

«Совет белем бирү системасыннан нәрсәне кайтарыр идегез?» дигән сорауга Җәүдәт Ибраһимович горурлык белән искә алып китә: советлар чорының белем бирү системасы, халыкара оешмаларның һәм галимнәрнең әйтүенчә, дөньяда иң яхшылардан санала.

– Иң элек, – ди ул, – белемнең бушлай һәм һәркемнең хәленнән килерлек булуын, яшьтән үк һөнәри юнәлеш бирелүен, уку йортын тәмамлаучыларны юллама белән таратылуын кайтарырга теләр идем. Совет системасында практикага йөз тоткан инженер-техник һәм фәнни әзерлек бик куәтле иде. Галимнәрнең һәм укытучыларның дәрәҗәсе югары булды. Менә шуларны кайтарыр идем дә, тик бер агымсуга ике тапкыр кереп булмый, диләр бит. XX гасырның 90 нчы елларында күп нәрсә югалды, нәтиҗәдә, сәнәгать җитештерүенең һәм кеше капиталы сыйфатының дәрәҗәсе түбәнәйде. Әлбәттә, бу – авыл хуҗалыгына да, аграр белем бирү өлкәсенә дә йогынты ясады.

Ләкин хәзер мәгариф системасында да, матди-техник базаны ныгытуда да җитди реформалар бара, дип саный ул, болар исә университетка инде бүген үк яңа, лаеклы үрләргә күтәрелергә мөмкинлек бирде.

Шунысын да телгә алу урынлы: бу үрләр күбесенчә ректорның үз фәнни эшчәнлеге бәрабәренә дә яуланды. Аның хезмәтләренең шактый өлеше нәкъ менә агросәнәгать комплексын үзгәртеп кору һәм аның икътисадый нәтиҗәлелеген арттыруның актуаль мәсьәләләренә багышланган. Аның эшләре киштәләрдә тузан җыеп ятмый, Җәүдәт Ибраһимовичның бер төркем тәкъдимнәре инде гамәли кулланышта.

Соңгы берничә елда ул агросәнәгать комплексын үзгәртеп кору һәм тотрыклы үстерү, инновацияле менеджмент, авыл хуҗалыгы җитештерүе белән идарә итү һәм аны оештыру өлкәсендә куәтле фәнни мәктәп булдырды. Аның кул астында гына да 18 икътисад фәннәре кандидаты һәм 6 фән докторы әзерләнде. Ректорның гыйльми эшчәнлек нәтиҗәләре авыл хуҗалыгы фәне үсешенә бик зур йогынты ясады. Аграр тармак предприятиеләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең югары бәясен алып, бу фәнни эшләр Казан икътисадчылары мәктәбе хезмәтләре буларак ил күләмендә һәм чит илләрдә танылды. Җәүдәт Фәйзрахманов үз авторлыгында һәм шәкертләре, хезмәттәшләре белән автордашлыкта 250дән артык фәнни хезмәтне дөньяга чыгарган, шулардан 20 монография аграр секторның икътисадый нәтиҗәлелеген арттыру һәм агросәнәгать комплексына реформа ясауның көнүзәк мәсьәләләренә һәм Татарстан Республикасының игенчелек системасына багышланган. Бу хезмәтләр галимнәр һәм авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен генә түгел, илебезнең авыл хуҗалыгы белән дәүләткүләм идарә итү системасы өчен дә гамәли кулланмага әйләнде. Мәскәү нәшриятларында басылып чыккан «Инновацияле менеджмент» һәм «Агросәнәгать комплексында инновацияле менеджмент» гыйльми хезмәтләре аеруча хөрмәт яулады.

Казан дәүләт аграр университетының Татарстан Республикасы Агротехнопаркын булдыру буенча Җәүдәт Фәйзрахманов фәнни җитәкчелегендәге инновацияле

проект күптән түгел «Татарстан Республикасының иң яхшы 50 инновацияле идеясе» конкурсында җиңү яулады һәм Россия авыл хуҗалыгы министрлыгы белән ТР Президенты тарафыннан хупланды. Әлеге проектны тормышка ашыру, һичшиксез, республикада авыл хуҗалыгының югары технологияле тармакларын үстерүгә инвестицияләр җәлеп итүгә булышачак. Бу проект Татарстанның эре агрохолдинглары – «Агросила групп», «Ак Барс Холдинг», «Кызыл Шәрык» һ.б. тарафыннан яклау тапты.

Татарстан Республикасында һөнәри белем бирү һәм фән үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә керткән шәхси өлеше өчен Җәүдәт Фәйзрахманов төрле дәрәҗәле бүләкләргә лаек булды, алар арасында II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале (2011), РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Россия агросәнәгать комплексын үстерүгә керткән өлеше өчен» алтын медале (2007) һәм башкалар бар.

ТР Фәннәр академиясенең авыл хуҗалыгы фәннәре бүлекчәсендә академик-секретарь, Югары мәктәпнең Халыкара фәннәр академиясе әгъзасы һәм Аграр белем бирү академиясенең мөхбир-әгъзасы буларак, Җәүдәт Ибраһимович фәнни-оештыру эшләрен дә актив алып бара. Ул ТР Фәннәр академиясенең авыл хуҗалыгы фәннәре бүлеге каршындагы агросәнәгать комплексын реформалауның икътисадый проблемалары буенча Гыйльми советы рәисе булып тора. Әлеге совет Җәүдәт әфәнденең үз тәкъдиме белән оештырыла. Аның максаты – аграр җитештерүнең икътисады, мондый җитештерүне оештыру һәм аның белән идарә итү өлкәсендә фәнни тикшеренүләрне үзара көйләү һәм бу юнәлештә көч-куәтне берләштерү.

ӨЗЛЕКСЕЗ ҮСЕШ ХИМИЯСЕ

Пестицидлар җитештерүдә илебезнең әйдәп баручы ширкәте – «Август» компаниясе авыл хуҗалыгы тармагындагы катлаулы вазгыятькә җавап итеп, берничә зур проектны тормышка ашыра. Шуларның икесе – Татарстан территориясендә.

КЫРЛАРДА – ИМПОРТКА АЛМАШ

Бу ел ахырында «Алабуга» махсус икътисадый зонасында яңа предприятие эшләтеп җибәрергә ниятлиләр. Үсемлекләрне химик ысул белән саклау өчен кирәкле матдәләрне елына 40 млн литр эшләп чыгарачак бу завод «Август»ның җитештерү объектлары арасында иң зурысы булачак.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, төзелешне башлап җибәрү тантанасында катнашканда: «Бу вакыйга – үсемлекләрне химик ысул белән саклау чаралары тармагында импортны алыштыруга зур адым», – дип белдерде һәм республика тарафыннан «Алабуга»ның яңа резидентына бар кирәкле ярдәм күрсәтеләчәген ассызыклады.

«Август» «Алабуга» махсус икътисадый зонасын яңа җитештерү мәйданчыгы итеп берничә сәбәп буенча сайлаган. Компаниянең беренче предприятиесе Вурнарда (Чувашия) урнашкан, ләкин аның якын-тирәсендә җитештерү куәтләрен арттыру өчен территория юк. Беларусь Республикасындагы «Август-Бел» заманча җитештерү комплексы да якын елларда үз мөмкинлекләренең иң югары чигенә ирешәчәк. Моннан тыш, МИЗ тәкъдим иткән инфраструктура һәм шартлар җитештерү объектлары төзү өчен идеаль туры килә. Ниһаять, әлеге мәйданчык логистика ягыннан да бик уңайлы урнашкан. Татарстан, Башкортостан, Удмуртия, Оренбург, Киров, Саратов өлкәләре – барысы да авыл хуҗалыгы белән актив шөгыльләнә.

Предприятие 2019 елның беренче кварталында ук проектта билгеләнгән куәтенә ирешеп, елына 40 млн литр пестицид җитештерә башларга тиеш. «Август» компаниясенең генераль директоры Александр Усков ватаныбызда җитештерелгән препаратларның Россия базарында 40 процентлык кына өлеш алып торуын белдерде, ләкин яңа заводны эшләтеп җибәрү әлеге санны тамырдан үзгәртәчәк. Өстәвенә, компания продукциясенең сыйфаты чит илләрнекеннән һич калышмый.

КЕШЕЛӘРНЕ ҖИРГӘ КАЙТАРЫРГА

«Август» ширкәтенең Татарстан территориясендә үсеш планнары «Алабуга» зонасында завод төзү белән генә чикләнми. Күптән түгел компания Мөслим районында 30 мең гектар авыл хуҗалыгы җирләре сатып ала. Бу басу-кырларга төрле елларда төрле ширкәт-оешмалар хуҗа булган. «Август» аларны «Татагролизинг» җәмгыяте аша сатып алган чагында, әлеге җирләрнең дә, аны эшкәртергә тырышкан хуҗалыкның да хәле күз яшьләрсез карарлык түгел иде.

Компаниягә чәчүлек фондын, техника паркын, технологик ысулларны тулысынча яңартырга туры киләчәк. Мөслим районында бөртекле культураларның бөтен төрләрен, кукуруз, көнбагыш, рапс, җитен, соя һәм ногыт үстерү планлаштырыла. Хәзер җирле климат шартларына чыдам сортларны сайлау эше бара. Эшче көчләр туплау белән дә билгеле бер кыенлыклар юк түгел, чөнки күчеш чорында районнан шактый белгеч, шул исәптән авыл хуҗалыгы белгечләре дә китеп барган. Ләкин соңгы дүрт елда җирле

Реклама
Фотолар «Август-Мөслим» ҖЧҖ алынды

хакимият һәм республика җитәкчелеге тырышлыгы белән тормыш дәрәҗәсе күтәрелде, предприятиеләр, социаль инфраструктура үсешкә йөз тотты. «Август-Мөслим» кебек зур, бюджетны тәэмин итүче компания барлыкка килү авылда тотрыклы, яхшы хезмәт хакы түләнә торган эш эзләүче кадрларны районга җәлеп итәчәк.

Яңа предприятиенең төп бурычлары – уңыш алу, аны эшкәртү, районны һәм республиканы югары сыйфатлы продукция белән тәэмин итү. Җирле базарда сатудан калган товарлар исә республикадан читкә озатылачак.

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК АША – ҖИҢҮЛӘРГӘ

«Август» компаниясенең үсемлек саклау чаралары Россия төбәкләре һәм элеккеге БДБ дәүләтләренә генә түгел, чит илләргә дә җибәрелә. Көньяк Америка, Азия, Африка, Якын Көнчыгыш базарларының потенциалы бик зур. Ләкин Bayer (Байер), BASF (БАСФ), Monsanto (Монсанто), Syngenta (Синджента) кебек химия һәм биохимия сәнәгате гигантлары белән көндәшлек итү, аларның лобби көченә каршы тору өчен тиешле җитештерү куәтләре кирәк.

Шул рәвешле «Август» тагын бер искиткеч зур проектка юл сала – Кытайның Хубэй провинциясендә актив матдәләр җитештерү буенча уртак предприятие төзергә ниятли. Элек компания бу компонентларны чит җитештерүчеләрдән сатып ала һәм аларны, әзер препарат формасына (эмульсия концентратлары, сулы-суспензияле концентратлар, сулы-эмульгацияләнә торган гранулалар һ. б.) китерү өчен, ярдәмче матдәләр һәм катлаулы технологик процесслар кулланып, өстәмә рәвештә эшкәртә. Шундый вакыт җитте ки, үз җитештерү мәйданчыгыңны булдыру икътисадый яктан гына үз-үзен аклап калмый, дөньядагы тотрыксыз шартлар да шуны таләп итә. Заводның урыны өчен берничә вариантны өйрәнеп, Кытайга тукталалар, чөнки нәкъ менә шунда зур тотрыклы базар формалашкан, ләкин андагы җитештерүчеләр саны соңгы елларда шактый кимегән: кече, урта предприятиеләр, идән асты заводлары керемсезгә әйләнә яки җирле экологик канунннарның кырыслануы нәтиҗәсендә закон тарафыннан тыела. Россия-Кытай уртак предприятиесе «Август» һәм аның партнерларының заводларын гына тәэмин итеп калмыйча, продукцияне экспортка да озатачак.

МИЛЛИАРДЛАР ӨЧЕН КӨРӘШ

«Август» үз алдына яңа, күләмле бурычлар куюдан курыкмый. Компаниянең көндәшлеккә сәләтлелеге куәтле заманча җитештерүгә, клиентларга даими технологик ярдәм күрсәтүгә, үсешне тәэмин итү өчен аерым фәнни-тикшерену департаменты хезмәт куя торган фәнни-тикшерену базасына һәм, әлбәттә, компания белән бергә үсү, алга бару теләге белән янып торган тәҗрибәле белгечләргә нигезләнә.

«Август» ширкәтенең Татарстандагы вәкиллеге аның кырыктан артык филиаллары арасында гадәттәгечә алдынгы унлыкка керә. Авыл хуҗалыгы базарындагы катлаулы вазгыятькә карамастан, 2017 елда вәкиллекнең товар әйләнеше 560 млн сумнан арта. Чит илләрдәге көндәшләр демпинг ысулы кулланып, республиканы арзанлы агу-химикатларга күмеп ташласа да, быел Татарстандагы «Август» республика авыл хуҗалыгы тармагына ким дигәндә 700 млн сумлык продукция кертергә ниятли.

– Республиканың пестицидлар базары күләме 2 млрд сум чамасы тәшкил итә. Без шуның яртысын яулау максаты куябыз. Моның өчен бөтен мөмкинлекләребез дә бар: сыйфатлы продукт, эш тәҗрибәсе, ныклы команда, – дип сөйли Казанда урнашкан вәкиллек җитәкчесе Константин Березин.

Сүз уңаеннан, Татарстандагы «Август» ширкәте хезмәткәрләренең яртысы Казан аграр университетын тәмамлаган. Алар – бик югары дәрәҗәдәге профессионаллар. Андыйлар миллиардлык базарны да яуларга сәләтле.

Константин Березин,
«Август» компаниясенең Татарстандагы вәкиллеге җитәкчесе:

– Бүген хезмәт базарында тәҗрибәле агроном табу бик авыр. Яшьләр арасында әлеге һөнәр белән кызыксыну түбән дәрәҗәдә, бу – гаять борчулы хәл. Беренчедән, табыныбызда икмәк булырмы-юкмы икәне нәкъ менә агрономнар һәм, гомумән, авыл хуҗалыгы тармагы белгечләренә бәйле. Аларга һәрвакыт ихтыяҗ булачак. Икенчедән, бүген әле элеккеге буын профессорлары һәм академиклары укыта. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә дә гамәли тәҗрибәле белгечләр калды әле. Алардан күп нәрсәгә өйрәнергә була. Ул белемнәр интернетта юк. Һәм бу яктан Казандагы аграр университет – белем хәзинәсе саклаган урын ул.

Ольга Горшкова, «Август» компаниясенең Татарстандагы вәкиллегендә менеджер-технолог, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, доцент:

– Казан авыл хуҗалыгы институтын бетереп, аспирантура тәмамлагач, шунда укытырга калдым. Ун елдан соң коммерциягә киттем, берничә шәхси компаниядә эшләдем. Инде берничә ел мин «Август»та менеджер булып эшлим. Үз тәҗрибәмә таянып шуны әйтә алам: бүгенге яшьләр, уңны-сулны карамыйча, бизнеска омтыла, ләкин сату эшенә тотынырга яки үз эшен ачарга планлаштыручылар өчен дә база белемнәр, сайлап алынган өлкәдә белгечлек кирәк. Бу сүзләр авыл хуҗалыгы тармагына аеруча туры килә. Практик тәҗрибә булмыйча, фермерлар, хуҗалык җитәкчеләре, районнардагы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыклары белән уртак тел табу мөмкин түгел. Казан аграр университетының бүгенге студентлары бәхетле – алар бәяләп бетергесез белемнәрне турыдан-туры белгечләрдән ала. Университетта үсемлекләрне саклау юнәлешендә Радик Сафин, селекция өлкәсендә Фәнүзә Кадыйрова һәм башка бик күпләр кебек тәҗрибәле белгечләр укыта. Шәкертләренең саны елдан-ел артсын иде, дип теләргә кала. Шул вакытта республика хуҗалыкларының киләчәге дә ышанычлы кулларда булачак.



Алмаз Хәйруллин, «Август» компаниясенең Татарстандагы вәкиллегендә менеджер-технолог:

– Мин, Казан авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлап, туган ягым – Питрәч районындагы хуҗалыкта 10 ел чамасы баш агроном булып эшләдем. Шунысы сөенечле: әлеге дистә елда мин үз белемнәремне тапшырып калдыра алган белгечләр бүген дә авыл хуҗалыгында хезмәт куя. «Август» үз практик тәҗрибәмне шактый киңәйтергә мөмкинлек тудырды. Мин безнең продукцияне кулланучы клиентларга ярдәм күрсәтү, киңәш бирү белән шөгыльләнәм. Бу иң мавыктыргыч һөнәрләрнең берседер дип уйлыйм. Ул һәрвакыт яңа мәсьәләләр чыгарып тора, ә аларны чишәр өчен авыл хуҗалыгының төрле тармакларында белемнәр кирәк. Тормыш тәҗрибәм шуны раслый: кадрлар һәм аларның әзерлегендә күп нәрсә хуҗалык җитәкчесеннән тора. Ул эш процессын дөрес оештыра, кешеләрне кызыксындыра ала, идарә эшендә дөрес карар кабул итәргә сәләтле. Ләкин андый җитәкче булырга телисең икән, укырга кирәк. Казан дәүләт аграр университеты моның өчен бар мөмкинлекләрне дә бирә.

ТАТАРСТАННАН ЕРАКЛАРДА ДА ТАНЫЛГАН БРЕНД

Казан дәүләт аграр университеты республиканың агросәнәгать комплексы предприятиеләре белән аерылгысыз бәйләнештә тора. Аны тәмамлаучыларның меңләгән отряды бихисап авыл хуҗалыгы компанияләрен җитәкли. Хәзерге агросәнәгать кластерын әлеге уку йорты әзерли торган югары квалификацияле авыл хуҗалыгы белгечләреннән, идарәчеләрдән, икътисадчылар һәм топ-менеджерлардан башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Аларның белемнәре хәзерге заманның катлаулы технологияләрен үзләштерергә, инновацияле алымнарны гамәли рәвештә кулланырга, авыл хуҗалыгы продукциясен көндәшлеккә сәләтле һәм сыйфатлы итәргә булыша.

Илшат Ганиев, «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ директоры

Шундыйларның берсе – Казан дәүләт аграр университетының агрономия факультетын тәмамлаган Илшат Ганиев 40 елдан артык «Майский» теплица комбинаты» җаваплыгы чикләнгән җәмгыятендә хезмәт куя, шуның соңгы 30 елында әлеге предприятиене җитәкли.

– «Майский» теплица комбинаты – бөтен нәрсә дә иң югары дәрәҗәдә оештырылган тиндәшсез комплекс ул. Моны бүген ышаныч белән расларга мөмкин. Үсемлекләрнең үсүе өчен шартлар тудырудан башлап, предприятиенең лаеклы социаль сәясәтенә кадәр – бу хак. Россиядә генә түгел, Европада да югары бәяләнгән, экологик яктан йөз процентка куркынычсыз продукция җитештергән хәлдә, без эшчеләребезгә хезмәтен башкару һәм тормыш алып бару өчен дә бик яхшы шартлар булдыруыбыз белән горурлана алабыз.

«Майский» комбинатының томатлары, кыяр, баклажан, татлы борычлары, яшел тәмләткечләре, җиләге һәм чәчәкләре Татарстанда гына түгел, ә Мәскәү, Санкт-Петербург, Киров, Екатеринбург, Чиләбе, Пермьдә һәм хәтта Ерак Себердә дә сатыла.

«Майский» продукциясенең сыйфаты һәм экологик күрсәткечләре халыкара күргәзмәләрдә һәм конкурсларда даими рәвештә танылып килә, алар «Экологик сыйфат сертификаты» белән раслана һәм балалар туклануы өчен ярый торган таләпләргә җавап бирә. Без җитештергән продукция экологик күзлектән куркынычсыз гына түгел, анда хәтта агулы химикатларның молекулалары да юк. Бик куәтле биолабораториябезнең тырышлыгы бәрабәренә без алардан котыла алдык. Ел саен бу биолабораторияләрдә үсемлекләрне корткычлардан саклый торган 800 млннан артык этномофаг бөҗәк җитештерелә.

Үз энергетик инфраструктурасы комбинатка технологияләрне сизелерлек яңартырга һәм оптимальләштерергә, яшелчәләрне хәтта сезоннан тыш чорда да җитештереп, аларны көндәшлеккә сәләтле бәядән сатуны оештырырга мөмкинлек бирде.

«Майский» комбинатында җитештерү базасын төзү һәм аны киңәйтү белән бергә социаль юнәлеш тә актив үсештә тора. Хезмәткәрләр өчен өч тулай торак, биш катлы ике торак йорт төзелгән, эшчеләрнең балалары ясле-бакчаларда урын белән тәэмин ителә, спорт комплексы эшләп килә, яшь гаиләләргә һәм пенсионерларга ярдәм күрсәтелә.

Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович! Сез илебездәге әйдәп баручы аграр вузларның берсе белән җитәкчелек итәсез, без Сезне иң югары дәрәҗәдәге профессионал һәм җитди галим генә түгел, искиткеч көчле тормыш энергиясенә ия кеше буларак та беләбез. Безнең хезмәттәшлегебез киләчәктә дә шундый игелекле һәм нәтиҗәле юнәлештә барыр, дип ышанабыз. Юбилей көнегездә «Майский» теплица комбинатының бар коллективы Сезгә алга таба да һөнәри һәм шәхси үсеш, камилләшү, корычтай ныклы сәламәтлек һәм алга куйган бөтен максатларга да ирешүегезне тели!

Фото «Майский» теплица комбинаты» архивыннан алынды

Реклама

BIONOVATIC – УҢЫШ ГОРУРЛАНЫРЛЫК!

Эшчәнлеген 2013 елда кечкенә лабораториядән башлап җибәргән Bionovatic (Бионоватик) компанияләр төркеме бүген Россиянең авыл хуҗалыгы тармагында үсемлекләрне тукландыру һәм саклау өчен макро һәм микробиологик препаратлар уйлап чыгару, җитештерү һәм кулланышка кертү өлкәсендә үзен иркен хис итүче инновацияле предприятие.

Рөстәм Рамазанов, Bionovatic компанияләр төркеме генераль директоры

– Эшчәнлегебезнең төп юнәлеше – үсемлекләрне тукландыру һәм саклаудан башлап, аларның үсешен көйләү, камыл деструкторы, туфрак халәтен яхшыртуга кадәр барлык этапларда кулланыла торган микробиологик препаратлар җитештерү. Израильнең авыл хуҗалыгында файдалы бөҗәкләр чыгару буенча алдынгы BioBee компаниясе белән берлектә энтомофаглар һәм төкләтуралар үрчетү заводы эшләтеп җибәрелде. Макро һәм микробиологик препаратларның шундый күптөрлелелеге ачык һәм ябык туфрак, бакчалар, урман-парк зоналары, органик җир эшкәртү өчен чаралар тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә.

Bionovatic компанияләр төркеменең микробиологик препаратлары Россия Федерациясенең 26 төбәгендә, БДБ илләрендә 2 млн гектардан зуррак мәйданда уңышлы кулланыла.

Казандагы микробиологик лаборатория белән Краснодардагы инсектицидлар уйлап чыгару лабораториясен үз эченә алган инновацияле фәнни-тикшеренү үзәге, заманча җитештерү базасы, сәләтле идарә итүчеләр, оештыручылар һәм галимнәрдән гыйбарәт көчле команда компаниянең әзлекле һәм уңышлы үсешенә булыша.

Бирегә Россиянең һәм чит илләрнең шушы өлкәдәге фәнни-тикшеренү институтлары һәм югары уку йортлары белән үзара хезмәттәшлеккә зур игътибар бирелә, уртак предприятиеләргә нигез салына. Аерым алганда, Казан дәүләт аграр университеты белән берлектә без үсемлекләрне биотик, абиотик һәм антропоген стресслардан саклау өчен яңа биологик чаралар ясау юнәлешендәге зур фәнни проектны тормышка ашырабыз. Әлеге тикшеренүләрнең нәтиҗәләре авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең чыгымнарын сизелерлек киметергә һәм үсемлекчелек тармагының керем дәрәҗәсен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Без үз алдыбызга искиткеч күләмле, ләкин шул ук вакытта чынга ашырырдай максатлар куябыз – Татарстан Республикасында һәм Россиядә агробиотехнологик чаралар базарын үстерергә, БДБ илләрендә алдынгы урыннар яуларга, продукциябезне чит илләргә чыгарырга. Bionovatic компанияләр төркеменең югары сыйфатлы продуктлары һәм системалы ачышлары заказчы кертемнәренең мөмкин кадәр күбрәк табыш китерүенә ирешергә мөмкинлек бирә, Җир шары ресурсларын саклауга, планетабыздагы халыкны сәламәт ризык һәм азыктөлек белән тәэмин итүгә, тормыш сыйфатын яхшыртуга өлеш кертә.

Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович!

Сез Татарстанның агросәнәгать кластеры өчен кадрлар әзерләү эшенә бөтен көчегезне, тәҗрибә һәм энергиягезне биреп, республикабызга күп еллар дәвамында намус белән лаеклы хезмәт итәсез. Татарстанда авыл хуҗалыгының киләчәге Казан дәүләт аграр университеты ректоры һәм галиме буларак, күп очракларда Сезнең профессионализмга һәм һөнәри җаваплылыкка бәйле. Сез юбилеегызны көчегез ташып, яңа уй-ниятләр белән янып торган хәлдә каршылыйсыз. Ул уй-хыялларыгызның һәрберсен тормышка ашырырга да насыйп булсын!

Фотолар «Бионоватик» ЖЧҖнән алынды
Реклама

КӨНДӘШЛЕККӘ СӘЛӘТЛЕЛЕККӘ ЙӨЗ ТОТЫП

Казан дәүләт аграр университетын тәмамлаган Фәрит Хөснуллин бүген Сарман муниципаль районын җитәкли, ә бу районда нәкъ менә аграр сектор хуҗалыкның төп нигезен тәшкил итә.

Фәрит Хөснуллин,
Сарман муниципаль районы башлыгы

Тормышыңны авыл хуҗалыгына, җирдә икмәк үстерүгә, республика халкын табигый ризыклар белән тәэмин итүгә багышлау – җаваплы һәм мактаулы эш. Эре терлекчелек комплексларыннан тыш, районыбызда гаилә фермалары, шәхси хуҗалыклар да актив үсештә. Шуңа күрә дә Казан дәүләт аграр университетында алынган һәм аны тәмамлаучылар тарафыннан Сарман җирендә бүген гамәли кулланылган белемнәрнең әһәмиятен бәяләп бетергесез.

Агросәнәгать комплексы өчен белгечләр хәзерләүдә республиканың тәүге ресурс үзәкләренең берсе саналган Сарман аграр көллияте белән Казан дәүләт аграр университетын күптәнге партнерлык элемтәләре бәйли. Көллиятне тәмамлаган 150 белгеч фәнни-белем бирү кластеры программасы буенча укуын аграр университетта дәвам итә. Үз белгечлекләре һәм һөнәрләре буенча эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсе – 100%. Быел аграр университетның 12 студенты, укуын тәмамлагач, туган районына кайта.

Казан дәүләт аграр университетында белем алу мактаулы да, перспективалы да. Ул хәзерге заманда уңышка ирешү мөмкинлеге тудырган лаеклы белемнәр бирә. Казан дәүләт аграр университетының уңышлы үсеше күп яктан әлеге югары уку йорты ректорына – Җәүдәт Фәйзрахмановка шәхсән бәйле. Фәнни-педагогик эшчәнлекнең барлык этапларын узып, республиканың авыл хуҗалыгы тармагы көндәшлеккә сәләтле булсын өчен, ул университетка яңа уку-укыту программалары, идеяләр һәм проектлар кертүдә чып-чын локомотивка әйләнде. Һәм бу – иң мөһиме. Сайлап алган эше белән кече яшьләрдән үк шөгыльләнеп, Җәүдәт Ибраһимович камиллеккә омтылышын, яңа белемнәр үзләштерүен һәм фәнни эшчәнлеген өзлексез дәвам итә. Уйлавыбызча, илебездәге иң яхшы аграр вузларның берсен җитәкләгән ректорга тәкъдир шулай язгандыр – гомер буе үсештә булырга, тулы куәткә эшләргә, студентларың, хезмәттәшләрең, туган җирең турында кайгыртырга.

Хөрмәтле Җәүдәт әфәнде! Барлык сарманлылар һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм. Студентларыгыз арасында сәләтле һәм кызыксынучан егетләр-кызлар елдан-ел күбрәк булсын, ә университетны тәмамлаучылар укудан соң авылларга кайтсын! Һәр үткән көнегез гаилә җылысына, мәхәббәткә, хөрмәткә төрелсен, якыннар, хезмәттәшләр һәм дусларыгыз ярдәменнән ташламасын. Сезгә озын-озак елларга нык сәламәтлек, бәхет, байлык-муллык телибез!

Фото: Александр Ефремов, Сарман районы хакимияте архивыннан

Реклама

Фото «Татагрохим» ААЖнән алынды

Наил Гобәйдуллин,
«Татагрохим» ААҖ
генераль директоры

Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович!

Юбилей туган көнегез белән «Татагрохим« ачык акционерлык җәмгыяте коллективы исеменнән һәм шәхсән үзем, Сезгә карата булган җылы хисләремне юллап, ихлас күңелемнән тәбрик итәм.

Туган көнегезне халкыбызның ихтирам казанган улы, күренекле шәхес буларак каршылыйсыз. Чөнки фидакарь хезмәт һәм намуслы тормыш юлыгыз күпләргә үрнәк булырлык. Озак еллар дәвамында чал тарихлы Казан аграр университетының ректоры сыйфатында югары белемле авыл хуҗалыгы белгечләрен әзерләүдә күләмле эшләр башкаруыгыз моны ачык исбатлый.

Үтә җаваплы һәм таләпчән, башлаган иҗади хезмәтләрегезне җиренә җиткереп башкара торган олпат шәхес, Татарстан авыл хуҗалыгы тарихында дәрәҗәле фәннәр академигы, абруйлы икътисадчы буларак лаеклы урын алып торасыз. Бу уңайдан Сезнең 60 тан артык фәнни хезмәтләрегез авыл хуҗалыгы белгечләренә белемнәрен баетырга ярдәм итә, иҗади үсешкә зур этәргеч булып тора. Зур дәрәҗәдәге хөкүмәт бүләкләренә ия булуыгыз гомер юлыгыздагы изге эшләрегезнең матур нәтиҗәсе.

Без, Татарстандагы күпсанлы тармак җитәкчеләре һәм белгечләр, Сез җитәкләгән университетны төрле вакытларда тәмамлап чыккан булсак та, һәрвакыт педагогик коллективның төпле ярдәмен тоеп яшибез. Күркәм гомер бәйрәмегез уңаеннан, югары белемле белгечләр әзерләүгә багышланган күпьеллык хезмәтегезне югары бәяләп, Сезгә олы рәхмәтемне белдерәм.

Сезгә исәнлек-саулык, иминлек, якыннарыгыз белән бергә озын гомер телим. Алдагы көннәрегездә тормышка сөенеп, башкарган изге эшләрегезнең куанычын күреп, дусларыгызның хөрмәтен тоеп яшәргә насыйп булсын.

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН
TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:

тел: (843) 222-06-05

Реклама 16+

Университеттагы үзгәрешләр инициаторы

Илшат Нуриев,
Татарстан Республикасының Арча муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович!

Сезнең тормыш юлыгыз – укырга, эшләргә, мөһим проектларны тормышка ашырырга теләгән кешенең чыннан да теләгенә ирешә алуына яхшы үрнәк. Академик, фән докторы, илебезнең иң абруйлы уку йортларының берсендә ректор... Ерак авылда туып-үскән гап-гади бер егетнең искиткеч уңышлы карьерасы аның гаҗәеп хезмәт сөючәнлеге, тормышка уңай карашы, белемгә омтылышы, дәрт-дәрман белән һәм тәвәккәлләп эш итә белүе бәрабәренә мөмкин булды.

Казан дәүләт аграр университеты – зур ихтыяҗ булган, абруйлы югары уку йорты. Аны тәмамлаучыларның күбесе вуздагы уку елларын бик җылы итеп искә ала һәм нәкъ менә КДАУда югары белем алу бәхетенә тиендергән өчен язмышына рәхмәт белдерә. Университет – агросәнәгать комплексы белгечләрен әзерләүдә инновацияле алымнар куллану тарафдары. Монда уртак лабораторияләр, бизнес-структуралар, тәҗрибә-җитештерү хуҗалыклары, уртак кафедралар булдыру аша җитештерү тармагы белән фәнни-техник хезмәттәшлекнең яңа ысулларын уңышлы үстерәләр. Университетның партнерлары арасында Арча районы предприятиеләре дә булуына без бик шат.

Уку йортының уңышлы үсеше күп очракта Сезгә һәм Сезнең шәхси сыйфатларыгызга, харизмагызга бәйле. Сез университеттагы вакыйга-хәлләрдән һәрвакыт хәбәрдар, укытучылар коллективын, студентларны ни борчыганын бик шәп беләсез. Сезнең инициатива белән университетта тормышка ашырылган үзгәртеп коруларның күбесе аның өчен файдалы һәм бик вакытлы булды. Сез бүген дә, холкыгызга тугры калып, яңаны булдыруга йөз тотып, актив эшчәнлек алып барасыз.

Кадерле якташыбыз, хөрмәтле Җәүдәт әфәнде! Тормышыгыздагы күркәм бәйрәм белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә сәламәтлек, бәрәкәт, бәхет һәм яңадан-яңа иҗади уңышлар телибез. Һәр көнегез иҗади энергия, якыннарыгызның һәм туганнарыгызның җылысы белән мөлдерәп тулып торсын!

Реклама Фото Арча муниципаль районыннан алынды





2013–2017 елларда Смәел авылында малларны аркансыз йөртү технологиясе буенча савым залы да булган 1100 башны сыйдыра алырлык сөт комплексы төзелде.

Фото «Смәел» ҖЧҖнән алынды

Реклама

МАКСАТЫБЫЗ – АВЫЛДА ТОРМЫШ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮ

Илһам Шакиров республиканың Балтач районындагы иң нәтиҗәле хуҗалыкларыннан берсе – «Смәел» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен 2005 елдан бирле җитәкли. «Авыл җирендә эш алып баруның иң мөһим, беренчел проблемасы – авыл хуҗалыгын кадрлар белән тәэмин итү, – дип саный ул. – Аграр предприятие тотрыклы үсештә, керем китерсен өчен, хезмәткәрләренең лаеклы белем базасы, үсү, югары күтәрелү теләге булу мөһим. Чөнки икътисадның нәкъ менә аграр секторы республиканың һәм илнең иминлеген тотып тора».

Бүген «Смәел» хуҗалыгы җирләренең мәйданы 2648 гектарны тәшкил итә, шуларның 2503 гектары – сөрүлек басулар. 2455 баш мөгезле эре терлекләре, шул исәптән 750 савым сыеры бар. Төп эш тармагы – ит һәм сөт җитештерү. Хуҗалыкта җитештерү күләме һәм авыл хуҗалыгы продукциясен сату елдан-ел арта бара. Үз чиратында, керемнәр дә, хуҗалыктагы хезмәткәрләрнең – ә алар 106 кеше – эш хакы да үсә.

Хәер, авыл хуҗалыгы тармагында, аерым алганда, терлекчелектә Балтач предприятиесенең уңышлары шартларның уңай килүе белән генә аңлатылмый. Хуҗалыкка ачысын да, төчесен дә татырга туры килә, монда эшләр шома гына барган, дип әйтеп булмый, ләкин иң мөһиме – ул аякта басып кала. Бүген исә «Смәел»дә хезмәт куючы кешеләрнең аеруча бердәмлеген, максатчанлыгын, авылның муллыгы, иминлеге өчен җаваплылык хисен тоеп, үзара аңлашып эшләвен күрергә мөмкин.

Илһам Мансурович икътисади яктан нықлы хуҗалык белән идарә итүнең бар нечкәлекләрен дә яхшы белә. Уңышлы үсеш өчен җитештерүнең алдынгы алымнарын кулланышка кертү генә түгел, авыл хуҗалыгы продукциясен сата торган базарны планлы рәвештә өйрәнү һәм анализлау да кирәклегенә ышана ул:

– Җитештерү һәм икътисади эшчәнлекне бергә уйлап, үлчәп алып барганда гына аграр хуҗалык уңышка ирешә ала.

Шуңа күрә предприятие ел саен капитал кертемнәр күләмен сизелерлек арттыра, яңа техника сатып ала, терлекчелек биналарын яхшырта, яңаларын төзи. Күләмле селекция эше алып бара, нықлы азык базасын булдыра.

Илһам Шакиров,
«Смәел» авыл хуҗалыгы предприятиесе» ҖЧҖ җитәкчесе

«Смәел»нең хуҗалык эшчәнлеге белән бәйле күрсәткечләрен арттыра барып, аның җитәкчелеге авыл халкының шәхси хуҗалыкларын саклау һәм үстерү турында да кайгырта. Чөнки бу да – керемнең өстәмә чыганагы. «Смәел»дә шуңа инанганнар: җирдә хезмәт куючы кешеләр хөрмәт һәм мактауга гына түгел, югары тормыш дәрәҗәсенә дә лаек. Һичшиксез, мондый предприятиенең бүгенгесе һәм киләчәге бар.

– Халыкның тормыш сыйфатын күтәрү турында сөйләгәндә, хәзерге дөньяда сыйфатлы белемнең никадәр зур мәгънәгә ия икәнен аңлау мөһим, – ди Илһам Шакиров. – Коллективыбыз 70 яшьлек гомер бәйрәме белән Җәүдәт Ибраһимовичны ихластан котлый. Без аның үз кул астындагы уку йорты белән генә чикләнмәгән ректор икәнен яхшы беләбез. Әнә шуның бәрабәренә Казан дәүләт аграр университеты республика агросәнәгать комплексының бик күп компанияләре һәм предприятиеләре белән тыгыз бәйләнештә тора. Күркәм бәйрәм көннәрендә ректорга иң төп теләкләребез – аларга заман белән бергә атларга насыйп булсын, яңа иҗади уңышлар, нықлы сәламәтлек һәм мул тормыш!

Вәгыйзь Минһаҗев,
«Россельхозцентр» ФДБУнең Татарстан буенча филиалы җитәкчесе

Уку йортына бар күңелен салган ректор

– Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович! Юбилей көнегездә иң ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз. Без бик күп еллар таныш, шуңа күрә милләтпәрвәрлекнең һәм Татарстан җиренә мәхәббәтнең якты үрнәге, авыл хезмәтен чын-чынлап пропагандалаучы булуыгыз турында ышанып әйтә алам. Шактый авыр хәлдәге вузны катлаулы 1996 елда җитәкли башлап, Сез аны республиканың агросәнәгать комплексы тармагында алдынгы фәнни-белем бирү кластерына, Россиянең иң яхшы аграр уку йортларыннан берсе дәрәҗәсенә күтәрүгә ирештегез.

Белем бирү процессында уку йорты, аның укытучылар составы, студентлары һәм фәнни тикшеренүләре өчен ректорның бар күңелен салып эшләве бик мөһим. Нәкъ менә аның яңа идеяләр һәм проектлар тәкъдим итүе, традицияләрне саклаган хәлдә алга бару өчен ни кирәклеген анык белүе һәм аңлавы әһәмиятле. Күбесенчә Сезнең энергиягез һәм максатчанлыгыгыз бәрабәренә бүген аграр университет белем бирүнең тагын да югарырак дәрәҗәсенә күтәрелде һәм киләчәккә ышаныч белән карый. Монда уку бик мактаулы, чөнки университеттан киләчәк өчен авыл хуҗалыгы белгечләре генә түгел, ә республика халкының азык-төлек муллыгы нигездә нәкъ менә шуларга бәйле булачак кешеләр белем алып чыга.

Сезгә, Җәүдәт әфәнде, иң элек сәламәтлек телибез. Ул иң якты идеяләрне һәм яңа проектларны чынга ашыру өчен җитәрлек булсын. Хезмәт нәтиҗәләре һәрвакыт канәгатьлек китерсен, ә Сезнең һөнәри уңышларыгыз дусларыгыз, көрәштәшләр һәм фикердәшләрегез ярдәме белән тулылансын! Җылылык һәм кайгыртучанлык белән аерылып торган бәхетле көннәрегез күбрәк булсын!

Фото «Россельхозцентр» ФДБУ тарафыннан бирелде
Реклама

Рөстәм Сөнгатуллин,
«Татмелиорация» ААҖ генераль директоры

Кадрлар – төп байлыгыбыз

Авыл хуҗалыгы тармагы Татарстан икътисады өчен иң әһәмиятле секторларның берсе дисәк, һич арттыру булмас. Авыл өчен кадрлар мәсьәләсе һәрвакыт актуаль булды, бүген исә бигрәк тә. Аграр сегментның күп кенә хуҗалыкларында хәзер югары технологияле, механикалаштырылган җитештерү күз уңында тотыла. Үзебез дә җирдә хезмәт куйгач, моны яхшы беләбез. Республиканың мелиорация бүлекчәләрендә бүген ике меңгә якын тәҗрибәле белгеч һәм хезмәткәр эшли. Аларның күбесе Сез 20 елдан артык җитәкләгән Казан дәүләт аграр университетын тәмамлаган.

Татарстан – Россиядә мелиорация буенча күләмле максатчан программалар тормышка ашырылып, яңа мелиоратив техника җитештерү җайга салына торган сирәк төбәкләрнең берсе. Һәм республикада мелиорациянең шундый өметле үсешендә Сезнең хезмәтегез бик зур. Нәкъ менә Сезнең кул астында КДАУ лаеклы матди-техник базага ия уку йортына әйләнде, югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә бай тәҗрибә туплады. Бүген университет – авыл өчен кадрлар әзерләүдә бәхәссез лидер. Нәкъ менә кадрлар байлыгы бүген «Татмелиорация» җәмгыятенә Татарстанның агросәнәгать комплексының, авыл хуҗалыгы җитештерү тармагының керемлелеге һәм тотрыклылыгы өчен ныклы нигез салырга мөмкинлек бирә. Димәк, республикабызда һәркемнең табынында икмәк һәм азык-төлек булачак.

Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһим улы! 70 яшьлек бәйрәмегездә Сезне Татарстанның барлык мелиораторлары исеменнән котлап, даими уңышлар, ныклы сәламәтлек, һәрчак күтәренке кәеф, ышанычлы фикердәшләр командасы теләргә рөхсәт итегез! Ошбу юбилей көнегез тормышыгызда яңа сәхифә ачып җибәреп, ул сәхифә бары тик игелекле вакыйгалар белән генә тулып торсын!

Фото «Татмелиорация» ААҖ тарафыннан бирелде
Реклама

Фото: Ната Смирнова

Генадий Миңнуллин,
крестьян-фермер
хуҗалыгы башлыгы

Реклама

Чын профессионал

Генадий Миңнуллин крестьян-фермер хуҗалыгы – Татарстан Республикасы Баулы районындагы иң эре, иң нык хуҗалыкларның берсе. Бүген Генадий Сәмигулла улының хуҗалыгы республиканың әйдәп баручы аграр предприятиеләре белән бер рәттә тора. Хуҗалыкның төп эшчәнлек юнәлеше – терлекчелек. Монда ике мең өч йөз баш мөгезле эре терлек бар, шуларның 680е – савым сыерлар. Алардан көн саен 12 тонна чамасы югары сыйфатлы сөт алына.

Хуҗалыкның тотрыклылык күрсәткече буларак шушы нефть төбәгендә авыл халкының бәхет эзләп шәһәргә ашкынмавын да телгә алырга мөмкиндер. Хәтта, киресенчә, бу хуҗалыкка Оренбург төбәгенең һәм Башкортостанның күрше-тирә районнарыннан ук бирегә эшкә алуны сорап киләләр. Күп кенә зона һәм республика семинарларының нәкъ менә шушы КФХ базасында уздырылуы да очраклы түгел. Предприятиенең үсешендә һәм алга баруында бик төпле, тырыш, эш сөючән коллективның һәм аның җитәкчесенең өлеше зур. Генадий Сәмигуллович кандидатлык диссертациясен Казан дәүләт аграр университетында яклаган, аннары авыл хуҗалыгы фәннәре докторы дәрәҗәсенә дә ирешкән. Аграр университет белән тыгыз хезмәттәшлекне ул бүген дә туктатмый, мөгаллимлек эшен алып бара, диссертация советы әгъзасы булып тора.

– Казан дәүләт аграр университеты бүген тиңдәшсез уңышлардан гыйбарәт саллы багажы булган, үзенең файдалы тәҗрибәсен актив тарату белән шөгыльләнгән киләчәге анык югары уку йорты. Аның галимнәренең фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләре, ачышлары республикадагы аграр фәннең үсешенә шактый өлеш кертте. Һәм без аларны тормышта бик уңышлы кулланырга тырышабыз. Монда әлеге уку йортының ректоры Җәүдәт Ибраһимович Фәйзрахмановның олы хезмәтен билгеләп үтми мөмкин түгел, – ди Генадий Сәмигуллович. – Сезнең хезмәтегез, хөрмәтле ректор, республиканың авыл хуҗалыгын алга алып бара, һәм крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе буларак, эшегездәге искиткеч профессионализм өчен Сезгә рәхмәт белдерү бигрәк тә күңелле. Ошбу юбилей көнендә без, Сезне котлап, талантлы, тәвәккәл студентларның күбәйгәннән-күбәя баруын, сәламәтлек һәм иминлек телибез!

Фото: Ната Смирнова

Радик Вафин,
«Хәерби» ҖЧҖ
генераль директоры

Реклама

«Ректорың ваемсыз кеше булмаса, бу бик шәп!»

Казан дәүләт аграр университеты – авыл өчен кадрлар әзерләү остаханәсе. Татарстанның агросәнәгать комплексы тармагында фәнни-белем бирү кластерының лидеры. Республиканың аграр җитештерү секторында әлеге уку йорты галимнәренең ачышлары киң кулланышка кертелә, аны тәмамлап чыгучылар бүген бик күп заманча һәм югары нәтиҗәле хуҗалыкларны җитәкли. Радик Вафин – «Хәерби» ҖЧҖ генераль директоры – шундыйларның берсе. Нигездә чәчүлек орлыкчылык белән шөгыльләнә торган хуҗалыкның сөрүлек җирләр мәйданы дүрт мең гектардан артып китә. Элиталы орлык әзерләүдән тыш, «Хәерби» хезмәтчәннәре яшелчә дә үстерә, терлекчелек белән дә шөгыльләнә. Хуҗалыкның күрсәткечләре һәр юнәлештә диярлек елдан-ел үсә бара. Радик Вафин сүзләренчә, боларның барысына да Казан дәүләт аграр университетында алынган белемнәр, әлеге уку йортының укытучылары һәм ректоры белән җылы мөнәсәбәтләр ярдәмендә ирешелгән:

– Җәүдәт Ибраһимович белән әле дә аралашып-сөйләшеп торабыз. Бер-бер сорау туганда, ул һичкайчан киңәшеннән, ярдәменнән калдырмый. Ректорың ваемсыз кеше булмаса, бу бик шәп! Ул оешма структурасын һәм университет эшчәнлеген һәрдаим камилләштерә бара, партнер булган авыл хуҗалыгы предприятиеләре белән актив элемтәләр тота. Татарстанлыларны табигый һәм сыйфатлы азык-төлек белән тәэмин итү бурычыбызның уртак булуын бик яхшы аңлый.

Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович, без, Сезнең элеккеге студентларыгыз, университетыбызның үзгәрүенә, үсүенә, киләчәккә ышаныч белән каравына бик шатланабыз. Монда Сезнең хезмәтегез бик зур! Сезгә ныклы сәламәтлек, иҗади планнарыгызны чынга ашырганда уңышлар юлдаш булуын телибез! Йортыгызда бәхет һәм бәрәкәт яшәсен!

Фото: Александр Эшкинин, Ната Смирнова

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ФӘНЕ АВАНГАРДЫНДА

Хәзерге заман шартларында аграр белем бирү экосистемасы агросәнәгать комплексындагы факторларның нәтиҗәле эшләве өчен таләп ителгән статик белемнәрне генә түгел, хезмәт базары белән тотрыклы бәйләнешне һәм авыл хуҗалыгы тармагында фәнни-тикшеренү багланышларын тормышка ашыруны тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүмат чыганакларын да үз эченә алырга тиеш.

Фото Казан дәүләт аграр университетыннан алынды

Виктория Галәветдинова,
КДАУ аспиранты

Авыл хуҗалыгы вузларының төп уку-укыту программалары уку йортын тәмамлаучыларның:

– агросәнәгать комплексындагы барлык тармакларның структурасын;

– җитештерү процессының тулы циклын;

– халыкны азык-төлек белән тәэмин итү системаларының (food systems) тулырак контекстын киңрәк аңлавын һәм күрүен тәэмин итә торган компонентларны үз эченә ала.

Укыту форматы акрынлап агросәнәгать комплексы чикләрен үтеп чыга һәм югары уку йортын тәмамлаучыларда азык-төлек белән тәэмин итү системалары өлкәсендә белемнәр булдыра: боларга логистика, маркетинг, кап-савытларга тутыру, азык калдыкларын эшкәртү, туңдыру һәм саклау технологияләре дә керә.

Аграр бизнесны инновацияле рәвештә үстерү – илебезнең заманча икътисадый алгарышы һәм авыл хуҗалыгы тармагындагы алга китеше шартларында да иң мөһим бурычларның берсе. Моны исәптә тотып, 2009 елда Казан дәүләт аграр университеты базасында Европа берлегенең алдынгы югары фәнни-укыту учреждениесе – Вагенинген университеты (Нидерланд корольлеге) белән берлектә MBA стандартлары буенча «Агробизнес» халыкара уку-укыту программасы булдырылды. Программаның төп максаты – үз аграр бизнесыңны һәм гомумән ил икътисадын инновацияле үстерү мәнфәгатьләрен кайгырткан төрле идеяләрне һәм җитәкчелек карарларын уйлап чыгару һәм чынга ашыру сәләте барлыкка китерү.

Университет базасында уздырылып килгән халыкара агрономия симпозиумнары глобаль куркынычлар янаган заманда авыл хуҗалыгын тотрыклы үстерү мәсьәләләренә (үсемлекчелекнең генетик ресурслары һәм «яшел» революция, җир эшкәртү системаларын климатның глобаль үзгәрешенә җайлаштыру, мелиорациядәге яңа алымнар һәм тенденцияләргә йөз тоту) багышланган.

Мәсәлән, бөртекле ашлык игү белән шөгыльләнүче фермерлар, климат үзгәрешенә чыдамлылыкны көчәйтү һәм керемнәрне күбәйтү максатында, культураларны төрләндерәләр һәм үзләренең җитештерү системаларына терлекчелек һәм урманчылык кебек элементларны да кушып җибәрәләр. Бөтен дөньяда бодай игү аның уңышлылыгын арттыруга булышлык итә торган азот чыганагы – кузаклы культуралар белән бергә алып барыла. Бодайлы-кузаклы ротациянең өстенлекләрен тулы күләмдә файдалану өчен җир эшкәртүнең ресурсларны саклауга юнәлтелгән ысуллары кулланыла. Төрле үсеп килүче илләрдә кукуруз басуларында каянус, вигна, соя кебек үсемлекләрне очрату – гадәти күренеш. «Кукуруз һәм кузаклылар» системасының югары җитештерүчәнлеге аны кече предприятиеләр, фермерлар өчен аеруча кулай ысулга әйләндерә.

Авыл хуҗалыгы культураларын үстерүдә төп игътибар бирелгән юнәлешләрнең алышынуы уку-укыту программаларын дөньякүләм тенденцияләрне исәпкә алып үзгәртүдә дә чагылыш таба.

Бүгенге көн шартларында аграр тармакның җитештерүчәнлеге процессында шик уятмый торган этәргечләр – җитештеру эше белән берләштерелгән авыл хуҗалыгы фәне, инновацияле идеяләр һәм кадрлар әзерләү.

Реклама

Хөрмәтле Җәүдәт Ибраһимович, Сезне юбилеегыз белән ихлас котлыйм! Тормышыгыз якты хис-тойгылар белән тулы булсын, ә хезмәтегез тагын да кызыклырак тарафлары белән ачылып торсын. Сез башкарган бу мөһим эшләрдә уңыш даими юлдашыгызга әйләнсен! Фәнни эзләнүләрдә иҗади ачышларга ирешергә, аграр белем бирү системасында новаторлык алымнарын кулланып эш итәргә насыйп булсын!

Роберт Гыйлаҗиев, «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларының рациональ файдаланылуын һәм сыйфатын тәэмин итү идарәсе» ДБУ башлыгы, июльдә 80 яшьлеген билгеләп үтә.

Югары җаваплылык тармагында

Вячеслав Чичков,
«Татнефть-АЗС Үзәк» ҖЧҖ директоры

Хөрмәтле Роберт Фәйзиевич!

Сезне һәм якыннарыгызны чын күңелдән әлеге истәлекле бәйрәм – туган көнегез белән котлыйбыз! Сезгә бетмәс-төкәнмәс энергия, ныклы сәламәтлек, һөнәри эшчәнлектә яңа үрләргә ирешүегезне, гаилә бәхете теләргә рөхсәт итегез.

Сез башкарганны дәүләт эшендәге хезмәттәшләрегез дә, һәр көн юл йөрүче гап-гади автомобильчеләр дә хөрмәт белән искә ала. Сезгә бу өлкәдә бик җаваплы участок ышанып тапшырылган – республикада ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү. Сездәге игътибарлы җитәкчелек сыйфаты һәм искиткеч оештыру сәләте бәрабәренә генә әлеге катлаулы һәм җаваплы секторда тулы гармония һәм үзара аңлашуга ирешеп була.

Компаниябезгә күрсәткән игътибарыгыз өчен Сезгә тагын бер тапкыр рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез. «Татнефть» сату челтәренең үсешендә катнашуыгызны югары бәяләп, бергә эшләү дәверендә урнашкан үзара ихтирамга корылган ышанычлы мөнәсәбәтләр өчен рәхмәт белдерәбез.

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Роберт Гыйлаҗиев

ТАССРның Биектау районы Ташлы Кавал авылында туган. Казан химия-технология институтын тәмамлагач, кырык елга якын КПССның XXII съезды исемендәге Уфа нефть эшкәртү заводында (хәзер – «Уфанефтехим» АҖ) эшли. Анда эшкәртү җайланмасы механигыннан предприятиенең генераль директоры дәрәҗәсенә кадәр хезмәт юлы уза. 1999–2000 елларда – «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ генераль директоры урынбасары, 2000 елдан 2002 елга кадәр – Нефть һәм нефть продуктларын рациональ куллануны күзәтү һәм контрольдә тоту буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе (ТР Дәүләт нефть инспекциясе), аннары – «Татгосэнергонадзор» ФДУ башлыгы.

2005 елдан – «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларының рациональ файдаланылуын һәм сыйфатын тәэмин итү идарәсе» ДБУ башлыгы. Роберт Гыйлаҗиев – Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре, күпләгән медальләр белән бүләкләнгән.

Реклама   Фото «Татнефть-АЗС Үзәк» ҖЧҖ тарафыннан бирелде; «Татар-Информ»

ТАТАРСТАНЛЫЛАРНЫҢ ТОРМЫШ СЫЙФАТЫН КҮТӘРҮ ӨЧЕН

Әгъзам Гобәйдуллин, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе, июль аенда үзенең 65 яшьлеген билгеләп үтә.

Әгъзам Гобәйдуллинның хезмәт биографиясе тулысынча республикабыз белән бәйле. Ул Яшел Үзән районында төрле җитәкче вазыйфаларында эшли, Мамадыш районында администрациягә һәм район советына җитәкчелек итә, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе була, РФ Федераль Җыенының Федерация Советында – республика вәкиле, Татарстан Үзәк сайлау комитетында – рәис, ә узган елның декабрь аеннан башлап ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе вазыйфасын үти.

Советның көйгә салынган эшенең күзгә күренеп торган нәтиҗәләреннән берсе – муниципаль берәмлекләрне интенсив үстерүгә юнәлтелгән республика программалары комплексын тормышка ашыру. Әгъзам Гобәйдуллинның җитәкчелек таланты республикада бүгенге көндә дә элеккечә үк кирәк. Ул ТР Муниципаль берәмлекләре Советының территорияләрне үстерүгә һәм республика халкының тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлтелгән миссиясен бер кимчелексез башкару өчен барысын да эшли.

Үсеш хакына хезмәттәшлек

Фаил Камаев,
Тукай районы башкарма комитеты җитәкчесе

– Хөрмәтле Әгъзам Саматович! Тукай районында яшәүчеләр һәм үз исемемнән 65 яшьлек гомер бәйрәмегез белән чын күңелдән котлыйбыз!

Тормыш юлыгыз Татарстан белән аерылгысыз рәвештә бәйләнгән, әлеге факт Сезнең шәхесегезне чын мәгънәсендә ихлас хөрмәткә лаек итә. Сез рәис булган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советының эшчәнлеге асылда республикадагы һәр кешегә кагыла. Әлбәттә, бу Сезгә гражданнар алдында бик зур җаваплылык йөкли.

Һәр кеше – чылбырдагы бер буын, һәм ахыргы нәтиҗә барыбызның да бердәм хезмәтенә бәйле. Сездәге тәвәккәллек һәм профессионализм бәрабәренә без, республиканың муниципаль берәмлекләрендә хезмәт куючылар да, «үз эчебезгә бикләнеп» яшәмибез, киресенчә, бер урында гына таптанмыйча, үсештә булу, үзара хезмәттәшлек итү өчен бик шәп мөмкинлекләр табабыз. Һәр районга һәм андагы халыкка карата игътибарлы, иҗади мөнәсәбәтегез өчен зур рәхмәт Сезгә! ТР Муниципаль берәмлекләре Советындагы хезмәтегездә идарә эшенең камиллек дәрәҗәсен күтәрергә һәм үсешкә булган туктаусыз омтылыш республика халкы бәхете өчен яңа уңышлы эшләр һәм проектларның гарантына әверелсен.

Сезгә чын күңелдән уңышлар, барлык ниятләрегезнең тормышка ашуын, ныклы сәламәтлек, ышанычлы фикердәшләр һәм көрәштәшләр командасы телибез!

Фото Тукай районы башкарма комитетыннан алынды

Фото Лениногорск муниципаль районыннан алынды

Рәгать Хөсәенов,
«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры

Ярдәмегез өчен мең рәхмәт!

– Хөрмәтле Әгъзам Саматович! Барлык Лениногорск халкы исеменнән тормышыгызның истәлекле вакыйгасы – 65 яшьлек гомер бәйрәмегез белән ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз. Сез күп еллар дәвамында бар көчегез, тәҗрибә, белемнәрегезне һәм һөнәри осталыгыгызны республика халкын бәхетле итүгә юнәлттегез, хәзер дә аңа намус белән хезмәт итәсез. Сезнең актив тормыш позициягез һәм җаваплыгыгыз һәр районның һәм бөтен Татарстанның үсеше, чәчәк атуы өчен мөһим социаль-икътисадый һәм сәяси мәсьәләләрне чишүдә үрнәккә әверелде.

Бергә эшләгән вакыт эчендә без Сезне һичнәрсәгә битараф калмый торган җитди җитәкче буларак танып белдек. Сез муниципаль берәмлекләрнең барлык мәсьәләләренә карата да игътибарлы мөнәсәбәттә каласыз һәм аларны чишүдә практик ярдәм күрсәтәсез, моның өчен рәхмәт хисләребезне белдерәбез. Лениногорск районы халкы һәм шәхсән үзем дә киләчәктә хезмәттәшлегебез шулай ук нәтиҗәле һәм файдалы булыр, дип өметләнәбез. Татарстан Республикасының уңышы хакына куйган хезмәтегезнең алга таба да иҗади нигезле, әһәмиятле һәм кирәкле булачагына ышанабыз. Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, күңел җылысы һәм муллык телибез!

Фото Мамадыш муниципаль районыннан алынды

Анатолий Иванов,
«Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы

Сүзендә торучы, әйткәнен эшләүче кеше

– Хөрмәтле Әгъзам Саматович, Сезне тормышыгыздагы истәлекле көн белән котлыйбыз! Әлеге матур юбилей көнендә мамадышлылар, бик шатланып, Сезгә бәхет, ныклы сәламәтлек һәм күтәренке рух тели. Гомерегезнең берничә елы Мамадыш белән тыгыз бәйләнгән. Туксанынчы еллар ахырында, шактый четерекле чорда, Сез район хакимиятен һәм район советын җитәкләдегез. Бу хезмәтнең никадәр авыр һәм җаваплы икәнен ишетеп кенә белеп калмыйсыз. Ә бүген Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе вазыйфасында Сез, республика районнарын нәтиҗәле, вакытлы ярдәм белән тәэмин итү өчен, бар мөмкинлекләрне эшкә җигәсез. Районның көнүзәк мәсьәләләрен хәл итүдә без һәрвакыт Сезнең ярдәмне тоябыз. Сезгә әлеге булышлык өчен ихлас рәхмәтлебез һәм киләчәктә дә хезмәттәшлегебезнең дәвам итәчәгенә өметләнәбез.

Сезне эшлекле җитәкче, сәләтле оештыручы һәм, иң мөһиме, республиканың чын патриоты буларак беләбез. Сезнең уңышларыгызга чын күңелдән сөенәбез һәм 65 яшьлек юбилей көнегездә иҗади дәрт, һәрнәрсәдә уңышлар телибез. Татарстанның муниципаль берәмлекләрен үстерү өчен актуаль проектларны тормышка ашырганда бай тәҗрибәгезне һәм белемнәрегезне киләчәктә дә файдаланырсыз дигән өметтә калабыз. Сезгә барлык башлангычларыгызда алга таба да уңышлар, гаилә бәхете, иминлек, тынычлык һәм игелек юлдаш булсын!

Реклама

ХИКМӘТЛЕ ИСКЕ ЧАЛЛЫ

«Минем турында язма, югыйсә хәзер урыныңда катырып калдырам!» Дистә елдан артык газета-журналларда эшләү дәверендә әле берәүнең дә алай янаганы юк иде. Судка бирәм, дигәнрәк сүзләргә ияләнәсең инде. Ә монда: «Бер урында катырып калдырам!» – ди бит! Сүзем Әлки районының Иске Чаллы авылында күргәннәр турында. «Катырып» ук калдырмадылар үзе, тик шулай да гаҗәп хәлләр булды.

Автор:
Руфия Фазылова

ЗАМАНГА ЯРАКЛАШЫП...

Башта без Әлки районының үзәге – Базарлы Матак буйлап сәяхәт кылдык. Яңа төзелгән бассейн, спорт сараен карап чыктык. Узган ел ремонтланган бала тудыру йортында булдык. Заманча җиһазландырылган ул, хатын-кызлар өчен тудырылган барлык уңайлыкларны күреп сокландык та, гаҗәпләндек тә. Бала тудыру йортында дин әһелләре белән сөйләшү өчен аерым бүлмә булуы да игътибарны җәлеп итте. Абортка килүче хатын-кызлар башта мулла, атакай белән әңгәмә кора икән. «Узган ел, дин әһелләре белән сөйләшкәннән соң, биш хатын-кыз баласын төшертү ниятеннән кире кайтты», – диделәр.

Әлки районы башлыгы урынбасары Рәшит Билалов язар өчен үзенчәлекле исемле, бай тарихлы, уңган кешеләре белән дан казанган берничә авылны тәкъдим итте. Мисал өчен, Мулла авылында эшләре гөрләп барган өч фермер бар икән. Әхмәт авылында исә нәселле атлар үрчетәләр. Районның тагын бер саласында сыек май ясау белән шөгыльләнәләр.

Иске Чаллы авылы да бар. Анда берничә хатын-кыз бозым чыгару, өшкерү белән шөгыльләнә. Авылның туфрагы шундыймы... – диде Рәшит Билалов. Соңгы тәкъдим аеруча кызык тоелды. Гайре табигый көчкә ия кешеләр белән танышасы, күрешәсе килде. Шулай итеп, Иске Чаллыга юл тоттык.

«АВЫЛНЫҢ ЙӨЗЕК КАШЫ»

Әлки районында Татарстанның «КАМАЗ» машиналары белән дан тоткан каласы исеменә аваздаш авыллар өчәү: Иске Чаллы, Яңа Чаллы, Бибай Чаллысы. Шуларның иң борынгысы – Иске Чаллы. Сугышка кадәр Яңа Чаллы зуррак булган. Әле аннан соң да авыл гөрләп яшәгән. Тик менә үзгәртеп кору җилләре башлангач, 1990 нчы еллардан соң, Яңа Чаллыдан халык күпләп читкә китә башлаган. Нәтиҗәдә бүген Яңа Чаллы белән Иске Чаллыда халык саны бер чама – 240 кеше тирәсе. Икесендә дә йөзләп хуҗалык бар. Тик тугызъеллык мәктәп, балалар бакчасы Иске Чаллыда гына калган. Балалар өч авылдан йөреп укый икән.

Иске Чаллының тарихы турында Флера апа Вафинадан сораштык. Утыз ел авыл җирлеге башлыгы булып эшләгән, хәзерге вакытта лаеклы ялда булган бу сөйкемле апаны «авылның йөзек кашы» дип таныштырдылар. Зәвыклы өс-башы, матур сөйләме өчен генә түгел, ул Иске Чаллы өчен янып яшәүчеләрнең берсе дә икән. «Казанның 1000 еллыгы» һәм «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре иясе.

– Иске Чаллының якынча 400 еллык тарихы бар, – дип сөйләде Флера апа. – Авылга беренче нигез салучы Мөрәс бабай булган. Ул бирәдәге елга буена килеп утыра, аңа «Чаллы» дип исем куша. «Чаллы» – елга башы дигәнне аңлата. Чаллы елгасы Базарлы Матак аша агучы Актай елгасына кушыла. Актай исә – Камага. Мөрәс бабай, бу җирне урыны яхшы дип сайлаган булырга тиеш. Чынлап та, безнең авыл Болгар белән Биләр

Фото: Александр Ефремов

Флера апа Вафина – Иске Чаллы өчен янып яшәүчеләрнең берсе.

арасында урнашкан. Элек халык урман арасыннан Биләргә җәяү йөри иде. Тора-бара Чаллы зурайган. Урын җитми башлагач, кешеләр үзләренә яңа уңайлы урын эзләп, ике чакрым ераклытагы яңа мәйданга күчеп утырганнар. Анысына инде «Яңа Чаллы» дип исем кушканнар. Ә Мөрәс бабай нигез салган авыл Иске Чаллы булып калган.

Иске Чаллының тарихы җентекләп өйрәнелмәгән. Флера апа да әлеге тарихны авыл картлары сөйләп калдырган буенча гына бәян итте. Югыйсә биредә археологлар өчен бик күп чимал бар. Язгы ташу вакытында кеше сөякләре калдыклары килеп чыга икән.

– Элек Иске Чаллыдан ерак түгел зур шәһәр булган дип тә сөйлиләр, – диде Флера апа. – Моның булуы бик мөмкин, әйткәнемчә, Болгар, Биләр орынып тора бит. Сәүдә итү өчен дә отышлы урын. Киләчәктә безнең җирләр яхшылап өйрәнелер, дип ышанам.

Иске Чаллы халкы элек-электән атаклы гармунчылары белән дан тоткан. Хәер, бүген дә авылда гармунчылар бар икән. Мәдәният йортында узган кичәләрдә сәхнәне ду китерәләр.

– Авылда яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр бар, – диде Флера апа. – 2005–2006 елларда ук «Чиста су» программасы кысаларында йортларга су керде, мәчеткә кадәр асфальт юл килде, урамнар якты. Ни кызганыч, яшьләр бик калмый.

– Эш юкмы, ни өчен яшьләр калмый? – дим.

– Эш юк, дип... Эшләсәң, бар инде. Бездә инвестор «Кызыл Шәрык» җәмгыяте. 3800 баш савым сыеры гына бар иде. Ике ел элек, чир чыгып, малларны бетерделәр. Зур-зур биналар бушап калды. Дөрес, хуҗалар яңадан сыерлар кайтартылачак, ди. Өметләник инде. Эше булса, авыл бетми ул.

Иске Чаллыда заманында кыз урлау гадәте булган. Тик бүген яшьләр алай өйләнешми икән.

– Хәзерге кызларны урлап кара! Утыртырлар! – дип тә шаяртты авылның бер агае.

Авылның киң, яшел чирәм үскән матур урамнары буйлап йөрибез. Флера апа белән һәркем исәнләшеп, хәл белешеп китә:

– Эштән киткәнгә өч ел булса да, берәр нәрсә килеп чыкса, хәзер дә миңа шалтыраталар, – ди юлдашыбыз. – Башта мәктәптә укытучы булып эшләдем. Авылда бит гомергә укытучыларга карата хөрмәт булды. Әллә шуңа, авылдашлар миңа беркайчан кыек сүз әйтмәде, бик аңлашып эшләдек. Хәзер дә аралашып, матур яшибез.

Флера апа безне Иске Чаллының атаклы өшкерүчесе Фәрдия апа Харисова янына да алып барырга ризалык белдерде:

– Бүген җомга көн, кешеләрне кабул итми ул. Үзем сөйләшермен, – диде.

«СЕЗДӘ БОЗЫМ ЮК...»

Фәрдия әбине районда гына түгел, республикада да беләләр икән. Заманында республиканың кайбер җитәкчеләре дә килгән. Бүген дә кеше өзелми.

Әбинең капкасы бикле иде. Флера апа:

– «Разведка» ясыйм әле, кәефе ничек икән, – дип, арткы яктан кереп китте. Ул да түгел, ишектән ак яулыгын бөркәнгән, шактый тере бер әби күренде. Исәнләшергә дә өлгермәдек, килә-килешкә югары тон белән:

– Язмагыз, язма минем турында. Фотога да төшермәгез! Колдун, диләр. Кеше котыртып йөрмим әле. Хәзер язсагыз, күче белән халык килә башлый. Җитте инде, күп өшкердем...

Дөресен әйтим, әбине күргәч, шикләнеп калдым. Шактый дуамал

Фәрдия апаның бер нигездә ике йорты бар.

Җаен ул халыкны ишегалдында дәвалый.

– Илле бер яшемдә ике улымны, иремне югалттым, – ди Фәрдия апа Харисова.

кешегә охшап тора. Кычкырып, каты итеп сөйләшә. Әңгәмәне яздырырга дип диктофонымны чыгарган идем:

– Яздырма! Югыйсә хәзер үзеңне бер урында катырып калдырам! – димәсенме. Ышанырга да, ышанмаска да белмичә, басып тик торабыз. Флера апаның гына әлеге күренешкә исе китмәде:

– Фәрдия апа, кеше куркытма. Әйдә, өеңә кереп сөйләшик әле, кызлар туңа, – диде.

Әби тынычлангандай итте. Үзе артыннан ияртеп, иске йортына алып керде. Фәрдия апаның бер нигездә ике йорты бар. Искесендә ул яшәми, кешеләр кабул итә, яңасы матур, заманча итеп эшләнгән.

– Әлеге иске йортымда рәхәт, монда энергия дә яхшы, – диде әби. – Буй-буй булып дүрт җирдән нур килә. Яңа йортка ияләнә алмыйча аптырап беттем. Хәзер ярый инде, тынычрак йоклый башладым.

Фәрдия апага 85 яшь тулган. Сыер асрамый башлаганына биш кенә ел икән. Сарыкларын узган ел бетергән.

– Тавыктан кала, башка җан иясе юк, – диде.

Сөйләшә-сөйләшә әби ачылып китте. Колхозда эшләгән вакытларын, ире белән яшәгән чакларын да искә алды. Үзе әйткәнчә, «нур иңү» турында аеруча яратып, тәмләп сөйләде:

– Илле бер яшемдә ике улымны, иремне югалттым, – диде Фәрдия апа. – Бер-бер артлы вафат булдылар. Кече улым кечкенәдән гарип иде, чирдән үлде. Ә менә уртанчысын кыйнап харап иттеләр. Иремне дә югалткач, акылдан язар хәлгә җиттем. Бер-бер артлы бит. Бүгенгедәй хәтерлим: түзәр чама калмагач, кулга бау алдым да караλтыга чыгып киттем. Кулым калтырый, үз-үземне белештермәс дәрәҗәгә килдем. Шулвакыт кемдер башымнан сыйпаган кебек булды. Тынычланып калдым. Аяклар үзеннән-үзе өйгә алып керде. Диванга утырдым. Карасам, миңа таба өермә булып нур килә. Башымны бер якка борам, икенче якка... Качып котылып булмады, теге нур китереп бәрде дә, тәмам күмеп китте. Шуннан ни булганны хәтерләмим, аңымны югалттым.

Фәрдия апа шул көннән бирле үзендә гайре бер көч тоя икән. Бозымны күрә, киләчәкне дә юрый. Башта ул якыннарын, танышларын өшкергән. Тора-бара аның даны тирә-як авылларга, районнарга таралган. Көненә йөзәр кеше килгән вакытлар да булган. Хәзер ул кадәр үк түгел икән инде.

– Ә ничек өшкерәсез? – дигән идем, әби безне тиз генә агач эскәмияләргә утыртты. (Йорт эчендә дүрт кеше идек). Шуннан, һәрберебез янына килеп, озак кына дога укыды. «Ихлас» белән «Фатиха» сүрәсен аерымачык ишеттем, калган сүрәләр минем өчен таныш түгел иде. Ярты сәгатьләп шулай укыганнан соң:

– Дүртегез дә чиста, сездә бозым юк, – дип куйды.

– Ә сез бозым барын шунда ук күрәсезме? – дим.

– Әлбәттә, күрәм дә, әйтәм дә.

– Бозымны чыгарып бетерә аласызмы? – дим.

– Чыгарам. Кемгә өч, кемгә җидесегез тапкыр өшкерү кирәк. Бозымни дәрәҗәдә каты инде, шуннан тора.

Шулай итеп бер сәгатьләп утырдык әби янында. Соңга таба бөтенләй ачылып китте, кочаклап ук алды. Ә аның өшкерүләренә килгәндә... һәрхәлдә, зыян булмады. Дога ишеткәч, җанга бер төрле рәхәтлек иңә бит. Фәрдия апа яныннан чыкканда арыганлык беткән кебек тоелды. Дога файдасыны, бүтәнме, өздереп әйтү кыен...

Ә урамга чыккач, бер кызык хәл булды. Безне Әлки район башлыгы урынбасары Рәшит Билалов Иске Чаллыга үз машинасында алып килде. Ни хикмәт, җирле җитәкченең Toyota Land Cruiserы кабынмады.

– Мондый хәлнең беркайчан да булганы юк иде, тик торганнан бит, – дип аптырады Рәшит Әбрәрович.

Әби исә моңа үзенчә аңлатма бирде:

– Машинаны дөрес урынга куймагансыз, бераздан кабына, – диде.

Шуннан безнең арттан икенче машина килеп җитте. Ә Рәшит Әбрәровичның машинасы нәкъ ярты сәгатьтән кабынган. Берәү дә бер җиренә кагылмаган. Баксаң, Иске Чаллыда моннан да сәеррәк хәлләр булгалый икән. Биредә яшәүчеләр машина кабынмауга гына әллә ни гаҗәпләнми.

КЕЧКЕНӘ КОЛХОЗ

Иске Чаллының башка өшкерүчеләре янына барып тормадык. Көнгә бер «сеанс» җитәр дидек. Аннан Фәрдия апа авылда иң стажлы «караучы әби» булып санала, калганнары аңа иярүчеләр икән.

Иске Чаллыда халык өшкерү белән генә шөгыльләнми, әлбәттә. Мал-туар асрый, яшелчә, җиләк-җимеш үстерә. Без авылның иң уңган гаиләләренең берсенә – Хәйдәровларга тукталдык. Гаилә башлыгы Гали абый тормыш иптәше Гөлгенә апа белән өч бала – ике кыз, бер ул тәрбияләп үстергән. Кызлары – Казанда, ә менә уллары Рамазан үзләре янында яши. Гали абый әйткәнчә, этисенең уң кулы.

Хәйдәровлар хуҗалыгында 26 баш мөгезле эре терлек бар, шуларның 11е – савым сыеры. Сөтне савып алып, урнаштыру – фәкать ир-атлар җилкәсендә.

– Хатыным Иске Чаллы төп белем бирү мәктәбендә укыта, аның маллар янында йөрергә вакыты калмый, – диде Гали абый. – Гөлгенәнең төп эше – мәктәп. Ә хуҗалык Рамазан белән минеке. Кечкенә бер колхоз безнең, тик җитәкче, эшчеләргә генә бүленмәгән.

Хәйдәровларның 35 гектар җирләре бар. Дүртесе үзләренең пай җире, икесен күршеләреннән сатып алганнар. Җир эшкәртер өчен барлык техникалары да бар, трактор, комбайн, чәчкеч, печән җыю җайланмалары. Әле сезон вакытында авылдашларына да ярдәм итәләр.

– Кечкенә бер колхоз безнең, тик җитәкче, эшчеләргә генә бүленмәгән, – ди Гали абый Хәйдәров.

– Рамазан җәй көне өйгә кайтмый да, – диде ата кеше. – 23 яшендә генә булса да, бар эшне булдыра, бик тырыш. Кечкенәдән кул арасында булды. Бөтен ышаныч, өмет аңарда. Шәһәргә җибәрәсем килмәде. Анда да эшләп ашарга кирәк. Монда, ичмасам, үз-үзенә хуҗа, эш җайланган. Безгә хәзер әллә ни кирәкми инде, балалар дип тырышабыз.

Хәйдәровларлар авыл башында мини-ферма төзеп ята. Дәүләттән акча алмаганнар. Үз көчләре белән эшлиләр икән.

– Рамазанны фермер итеп теркәп, бер миллион грант аласы килгән иде, – ди Гали абый. – Әлегә булмады. Фермер булыр өчен авыл хуҗалыгы белгечлегенә укырга кирәк. Ә Рамазан Казан кооператив институтының икътисад бүлегендә читтән торып белем ала. Аны тәмамлагач, авыл хуҗалыгы юнәлешендә укырга керер инде. Бер карасаң, улыбызның югары белеме дә була, икътисад белгечлеге авыл хуҗалыгыннан әллә ни ерак та түгел кебек. Тик законга каршы барып булмый шул...

Авылларга баргач, фермерлар белән сөйләшкәндә, еш кына бер сорауга җавап эзлибез: терлек асрауның файдасы бармы?

– Бар, – диде Гали абый. – Малларга печәнне, игенне сатып алмыйбыз. 35 гектар җирнең бер яртысында печән, икенчесендә иген үсә. Шул ел әйләнәсе ашатырга җитә. Сөтне, күрше авылдагы бер фермер белән кушылып, район үзәгенә илтеп тапшырабыз. Авылдагы сөт җыючы литрын 11 сумнан ала, ә без 13 сумнан тапшырабыз. Әлбәттә, бер генә сыер асраган кеше, район үзәгенә кадәр сөт тапшырып йөри алмый, файдасы калмый. Ә безгә барыбер отышлырак әле.

Хәйдәровлар кыш көннәрендә сөттән генә аена 70–80 мең акча керткән. Хәзер исә, сөткә бәяләр төшкәч, керем 50 мең сумга гына калган.

– Ун баш сыер көтүдә йөри, – диде Гали абый. – Чиратлап көтәбез. Иң күбе без чыгабыз, көтүдәге 55 сыерның 10сы безнеке бит. Әле менә авылдашлар белән «электропастух» алып куярга җыенабыз. Күрше авыллар сатып алган, җайлы, диләр.

Тагын бу хуҗалыкта дүрт ат бар. Эш өчен дә файдаланалар, иткә дип тә суялар. Ат итеннән күпләп казылык ясыйлар икән.

– Бу минем төп нигезем, – диде Гали абый. – Без сигез туган. Аллага шөкер, туганнар бик дус-тату яшибез. Әти-әни юк, дип тормыйлар, бик еш кайталар. Ат итеннән ел саен казылык ясап, туганнарга күчтәнәч итеп таратабыз. Бергәбергә яшәгәч күңелле. Әле менә авыз ачтырдык, туганнар җыелышып кайтты. Әти-әниебезнең дә рухы шат булгандыр, дип уйлыйм.

...Әлки якларында менә шулай яшәп яталар. Уен-көлкене аңлый торган, тырыш, кунакчыл халык гомер итә бирәдә. Тагын бер сыйфатлары бар: акны ак диләр, караны – кара. Кыскасы, мишәр туганнар булдыра!

Хәйдәровлар авыл башында мини-ферма төзеп ята.

Язылｈәм телевизор от!

1
Язып
25.06.2018 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына язып *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2
Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3
От
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!

Акцияне үткәрү вакыты: 16.05.2018-20.09.2018

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама



НОМЕР КӘЕФЕ: **ЯҢА ЕЛДАГЫЧА**

Ната Смирнова фотолары

Кышны сагынганнарга тиз арада Кощаковога барырга кирәк. Юк-юк, кар өчен түгел, Яңа ел кәефе өчен. Нәкъ менә анда, өр-яңа карусельләр, җәяүлеләр өчен сукмаклар һәм спорт мәйданчыклары арасында төрледән-төрле шарлар эленгән гүзәл чыршы басып тора. Кощаково халкының кышкы бәйрәм яме булган чыршының җәйге яшеллек һәм чәчәкләр арасында ничек балкып торуын күрәселәре килгән, һәм нәтиҗәсе аларга бик тә ошаган. Хәзер авыл скверын аннан башка күз алдына да китереп булмастыр кебек. Шулай ук – хәрби бурычларын үтәгәндә, 1942 елның 3 мартында Кощаково өстендә бәрелешеп һәлакәткә юлыккан ике самолётның батыр очучылары хөрмәтенә куелган самолёттан башка да.

Кощаковода яшәүчеләр үзләренә тыныч күк йөзен мирас итеп калдырган ул очучыларны хәтерендә саклый, а самолёт монда чын-чынлап истәлекле урынга әверелгән. Ул бөек сугышларның тарихын да искә төшерә, шул ук вакытта хәрби самолёт һәм яңа ел чыршысы тирәсендә бер кайгысыз кайнап торган тыныч тормышны да саклап тора.

Бәхетле

СУПЕРМАРКЕТ ДОМАШНЕЙ ЕДЫ

Попробуйте по-домашнему вкусные блюда татарской кухни, приготовленные по традиционным рецептам – эчпочмак, элеш, кыстыбый, чак-чак, талкыш калеве, казылык.

www.bahetle.com